www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 44 (1460) 10 ноябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

5

Әлмәт театры артисткасы Роза Салихованың уйнаган рольләре дистәләгән, ләкин һәр яңа рольгә алынган саен аның күзләре яшьләрнеке кебек яна, ялкынлана, ул һаман да гел сәхнәдә яши.

14-15

Сиксәненче еллар азагында «Камгэсэнергострой» берләшмәсен тотучы төп экономистларның берсе генә түгел, ә Чаллы каласында милли хәрәкәт оештыручы әйдәман да иде ул – Габдулла Сәрвәретдинов.

16-17

Минзәлә районының Тауасты Байлар атлы гап-гади татар авылында туып, 13 яшьлек малай көенчә Казан музыка училищесына кереп, соңрак музыка профессоры дәрәҗәсенә күтәрелгән Әзһәр Абдуллинның гомере сокланырлык.

Баллы-татлы миләш тәлгәшләре... Көзге учак кузы гүяки!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан «Иң күп укый торган төбәк» Бөтенроссия конкурсында «Россиянең әдәби флагманы» исеменә лаек булды.
- 9 айда Татарстанда кулланучылар кәрзине 3,7 процентка кыйммәтләнде.
- Айрат Фәррахов 2024 елда социаль түләүләрнең 7,5 процентка артачагын раслады.
- Миңнеханов Мәһдиевнең Чаллыга 400 ел тулуны бәйрәм итү турындагы мөрәҗәгатен хуплады.
- Интертат «Интеррекорд» халыкара рекордлар китабына һәм Россия рекордлары реестрына керде.
- Мисыр Президенты Каһирәдә Казан федераль университеты филиалын ачу карарын имзалады.
- Якутск шәһәрендә «Казан» скверы һәм Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды.
- Санкт-Петербургтагы Россия Милли китапханәсендә татар теологы, күнчыгыш белгече Х.Фәизхановның 200 еллыгына багышланган «Хөсәен Фәизханов. Тормыш юлы» күргәзмәсе ачылды.
- Төмән өлкәсендә Тубыл губерниясендә мәчет кенәгәләренә багышланган китап тәкъдим ителде.
- Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты чыгара торган «Золотоордынское обозрение» фәнни журналының 10 еллыгына багышланган утырыш узды.
- Непалның көнбатышында күпсанлы корбаннарга китергән җир тетрәү булды.
- Газа секторында Якын Көнчыгыш конфликты кискенләшү башланганнан бирле 10 меңнән артык кеше һәлак булды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

12 ноябрь – Татарстан Республикасының халык артисты Идрис Мөдәррис улы Мәсгутовның тууына 75 ел (1948-2008);

– Татарстан Республикасының халык артисты Галина Александровна Казанцевага 70 яшь (1953).

13 ноябрь – актриса, ТАССРның халык артисты Мөнирә Габдулла кызы Шаһидуллинаның тууына 100 ел (1923-2001).

15 ноябрь – рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Канәфи Афзалетдин улы Нәфыйковка 85 яшь (1938).

СЫНАМЫШЛАР

● 14 ноябрьдә кар яуса, язгы ташу мул була ● Әтәч бер аягында басып торса, тавык һәм казлар башларын канат астына яшерсә – суыта ● Таң алдыннан йолдызлар бик каты җемелдәсә, якын арада көн бозыла ● Каргалар көтүләре белән бер сәбәпсез каркылдашса, тиздән суыта ● Күз ахырында түгәрәк-түгәрәк вак кына боз яуса, кыш суык була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 08 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 48 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 40 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **27 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **17 ноябрьдә 8 сәгать 13 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 10 ноябрь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(13-20 ноябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигүл ахир аеның 26 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Индус ТАҺИРОВ, академик

ТАТАР ФАКТОРЫ

Совет фәнендә татарлар ярымкыргый, ә дәүләтләре артта калган, мәдәниятләре, мәгарифләре юк дәрәҗәсендә тасвирлана килде. Казан ханлыгы турында бер аморф ил рәвешендәге күзаллау хөкем сөрде. Әмма, күренекле тарихчы М.Худяков бу ялганны фаш итеп, болай дип язган: «Ил далалар белән түгел, урманнар белән капланган. Борын-борыннан утрак халык олысларда һәм авылларда яшәгән. Бу турыда сөйләгәндә бу илдә күчеп йөри торган урыннар, киез юрталар турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Барлык халык, татарлар да, читтән килгәннәре дә биредә игенчелек, шәһәрләрдә сәүдә һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнгән».

Татарларны рус дошманы булган, дигән сүзләр дә тик уйдырма гына. Болгар чорыннан башлап, алар руслар белән ныклы, ике як өчен дә файдалы мөнәсәбәтләр урнаштырып яшәгән. Болгарлар рус кенәзләрен икмәк белән тәэмин итеп торган.

Казан ханлыгы чорында да шушы рәвештәге мөнәсәбәтләр сакланган. Худяковның түбәндәге сүзләре игътибарга лаек: «Татарлар рус дәүләтенә дә, аларның сәяси автономиясенә дә, рус кенәзләре хакимиятенә дә, аларның хәрби оешмаларына да, диннәренә һәм телләренә дә беркайчан да каршы килмәгән. Казан хөкүмәте беркайчан да рус дәүләтен яулап алырга омтылмаган; ул бары тик Мәскәү һәм Казан арасында үзара мөнәсәбәтләрне ныгытырга гына тырышкан». Гомумән, татар дәүләтләрендә вөҗдан иреклеге хөкем сөргән. Православие өчен махсус ташламалар ясалган, аңа тел тидерү катгый рәвештә тыелган.

Без татарлар тарихына дан җырлау фактларын бөтенләй белмибез диярлек. Казан егылганнан соң татарлар Россиядә һәрвакыт үзләре турында каһәрләү сүзләрен ишетеп яшәде. Чөнки хәтта Россиянең артта калу сәбәбен дә «татар золымы» белән аңлата килделәр. Уку дәреслекләре татарга яла ягулардан тора иде. Мәҗит Гафури язганча, татарлар һәрвакыт Россиянең каһәрләнгән үги балалары булды. Чыннан да, татарлар мактау-макталуга күнекмәгән халык.

Кайбер язмаларда, гәрчә хакыйкать киресенчә булса да, 1410 елгы Грюнвальд сугышында татарлар хурлыклы рәвештә куркып качты, дигән бәя дәвам итте. Ә поляклар исә шушы сугыштагы җиңүгә татарлар керткән өлешне югары бәяли. Бу сугышта Туктамыш ханның улы Җәлаләтдин җитәкчелегендәге гаскәрнең хәлиткеч ролен тану хөрмәтенә Данциг шәһәрендә татар сугышчысына һәйкәл ачылды. Анда ил президенты Станислав Комаровский татарга дан җырлады. Аның һәрбер сүзе чын йөрәктән чыккан хисләр белән сугарылган. Президент Польша татарларының 600 ел дәверендә илгә турылыклы хезмәт итүләрен, аның бәйсезлеге өчен үз-үзләрен аямыйча сугышуын ассызыклады. Аларны курку белмәс, дошманнарның котын алучан батырлар, дип бәяләде. Моңа кадәр Польшада яшәгән милләттәшләребезгә карата мондый югары бәяне ишеткәнебез юк иде. Татарлар бу нотыкта чын мәгънәсендәге әкияти батыр, дусны кайнар хис белән ярата торган, аңа турылыклы, ә ил дошманнарына карата ачы нәфрәтле халык рәвешендә тасвирланды.

Поляклар татарларны ярата. Бервакыт Варшава урамында бер поляк ханым белән сөйләшергә туры килде. Татар икәнемне белгәч, ул кочаклап алды һәм 1939 елның сентябрендә Польшага немецлар бәреп кергәч, Варшаваның татар полкы солдатлары башкаланың соңгы сакчылары булганлыгы, аларның батырларча һәлак булуы хакында елый-елый сөйләде.

Шушы уңайдан үзебез белән булган бер вакыйганы да искә төшереп китәм. 1987 елның октябрендә мин, Миркасыйм Усманов һәм хатыным Люция, поездга утырып, Варшавадан Люблин шәһәренә фәнни конференциягә барабыз. Каршыбызда безгә ничектер усалрак караган полякларның, татарлар икәнебезне белгәч, йөзләре ачылып китте. «Башта без сезне грузиннар дип белдек», дип яныбызга күчеп утырдылар һәм юл буе татарларны мактап бардылар. Люблинга килеп җиткәч, «Не дадим татарам сгинуть на польской земле», диеп безне университетка кадәр озаттылар. Икенче көнне конференциягә килеп, безгә бүләкләр тапшырдылар. Университет галимнәре безгә сүзлекләр күрсәтеп, үз телләренә кергән йөзләгән татар сүзе бар икәнен әйтте. Ул сүзләр рус сүзлекләрендә дә бар, ләкин аларның килеп чыгышы хакында тиешле аңлатма юк.

Мәгълүм ки, Белоруссия татарлары да – шул ук токымнан. Алар – Речь Посполитая дәүләтен саклап, Грюнвальд сугышындагы батырларның дәвамчылары. Анда да татарларга карата җылы хисләр саклана. Беларусь президенты А.Лукашенко татарларның тарихтагы рольләренә 1993 елгы очрашуыбыз вакытында югары бәя бирде. Ул татарларның Бөек Ватан сугышы вакытындагы партизан хәрәкәтендә катнашуларын да ассызыклады. Алар сугыш батырлары гына түгел, хезмәт үрнәген дә тудыра белүчеләр, яз көне иң беренчеләрдән булып базарга яшелчә китерүчеләр дә татарлар, диде.

Очрашу вакытында ул, шаярып кына, янда басып торган Урал Латыйповка ишарәләп, мине тәнкыйтьләргә җыенасыз икән, башта әнә үзегезнең милләттәшегезне тәнкыйтьләгез, мин аның киңәшләренә таянып эшлим, диде. Чыннан да, ул вакыт Урал Латыйпов аның киңәшчесе иде.

Бүген Урал Латыйпов та аның киңәшчесе түгел. Үзе дә мин язган көннәрдәге Лукашенко түгел. Ләкин тарих – ул үткәнге чынбарлык. Без аны бүгенге көнгә яраклаштырып түгел, ә ничек булган шулай кабул итәргә тиеш.

Чын-чынлап бөек, һәммә татар кешесендә горурлык уятырдай тарихыбыз бар. Бөеклек чорыбыз да, коллык упкынына төшкән гасырлар да, барысы да безнеке. Ул тарихтан качып булмый. Аны ныклап өйрәнеп, тиешле сабаклар ала белергә кирәк. Бөеклегебезгә кайтуыбызның мөмкинлеге тик шул гына.

Шушы мөмкинлек киләчәгебезгә юл ача күрсен иде. Ләкин, ни кызганыч, киләчәгебез бүген төтен белән тутырылган пакетны хәтерләтә. Украинадагы яуда көн саен меңләгән кешеләрнең гомерләре өзелә. Ул кыска вакытлы операция дип башланса да, инде икенче ел дәвам итә. Алай гына да түгел, экспертлар аны 2025 елга кадәр, бәлки аннан озаграк булыр, дип фаразлый.

Чыннан да, бу дөреслеккә якын күзаллау. Чөнки ике якның берсе дә, АКШ җитәкчелегендәге Көнбатыш та, Россия дә һич кенә чигенергә җыенмый, хәрби операцияне дәвам итү өчен миллиардлаган акча түгәләр, яу техникасын Украина кырларына эшелонлап ташып торалар.

Көнбатышның Россиягә карата кертелә бара торган шартларның берсе – ул аңа карата төрле рәвештәге санкцияләр. Шулар нәтиҗәсендә Россия халыкара изоляциядә калды. Аның янәшәсенә басарга теләгәннәрнең саны кимегәннән-кими. Грузия, Әрмәнстан кебек элек союздаш булган илләр дә дошман ягына күчте. Казахстан, Кыргызстан кебек республикалар да Россиядән читләшә, Көнбатышка якыная, Россиягә ышанычлары кими бара. Шушы шартларда Татарстан Россияне халыкара изоляциядән чыгару гамәлләрен арттыра. Мөселман илләрендә, гомумән Көнчыгышта, безгә ышаныч зур. Татарстанның алар белән төрле рәвештәге килешүләре күбәя.

Татарстанның икътисадта Россиягә зур уңышлары белән үрнәк булып тора. Ул үзендә чыгарыла торган нефтьнең 80 процентлан артыгын үзе эшкәртеп, аның продукциясе белән сәүдә итә. Республика күп илләр белән төрле рәвештәге мөнәсәбәтләр урнаштырып яши. Аның элемтәләре бигрәк тә Ислам илләре белән зур тыгызлыкта.

Республиканың «Вакуммаш», компрессор заводы, «Данафлекс», Татхимфарм-препараты», «Палп-индекс» предприятиеләре яңадан-яңа уңышларга ирешә тора. Машиналар, техник җиһазлар, дарулар, кәгазь, резина, пластмасса эшләнмәләре арта. Авиация заводында ТУ-214 самолетларын җыю бара, вертолет заводы «Ансат» өчен кирәк детальләрне үзе булдыра башлады. Һәм шунысы да әһәмиятле: республикада азык-төлек җитештерү сизелерлек арта. Бу уңышларның сәбәбе – республикадагы халыкларның эш нәтиҗәләре. Республикада 173 милләтнең дуслыгы тантана итә. Аларның үзләрен, телләрен, гореф-гадәтләрен саклау дәвам итә. Динара мөнәсәбәтләр, бигрәк тә Ислам һәм Православие аралашулары үзара аңлашу рәвешендә алып барыла. Халыклар дуслыгы нык барган шартларда безнең өчен иң беренче урында татар-башкорт мөнәсәбәтләре тора. Шушы нисбәттән 2004 елны «Кызыл таң» газетасында басылып чыккан вакыйганы искә төшерәсем килә. Ул «Бәйрәмебез дә уртак» дип аталган. Менә аның тексты:

«Башкортостанның мөстәкыйльлек бәйрәме – Республика көне тантаналарында катнашу өчен төрле төбәкләрдән кунаклар килә. Кичә Татарстаннан КДУ кафедрасы мөдире, танылган дәүләт эшлеклесе Индус Таһиров җитәкчелегендәге делегация Уфага килде. Аның составында ТР Дәүләт Советы депутаты, күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Нурмөхәммәт Хисамов, ТР Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Казан педагогика университеты ректоры Җәмил Нигъмәтов һәм Бөтендөнья татар конгрессы рәисенең беренче урынбасары Илсур Һадиуллин бар.

Билгеле булганча, Башкортстан белән Татарстан арасында хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча икеяклы комиссия оештырылган иде. Тантаналар барышында шушы комиссиянең чираттагы утырышы булуы да көтелә».

Ул утырыш уңышлы рәвештә үтте, аннан соң Башкортостан республикасы көненә багышланган төрле рәвештәге кызыклы чаралар үткәрелде.

(Дәвамы 4 нчы биттә).

Тинчурин театры кыйбласын югалтмый

6 ноябрьдә Кәрим Тинчурин исемендәге дәүләт театрының 90 еллык юбилей кичәсе булып узды. «Тинчурин театры үзенең кыйбласын югалтмыйча яши», – диде тәбрикләү чыгышында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов. Ул театр коллективын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исеменнән сәламләде.

«Тинчурин театрының тулы гасырга әз генә җитми калган юбилее. Театр – үзе бер дөнья, гомер буе өйрәнә торган сәфәр. Татар театры булмаса, татар теле – туган теле нишләр иде, дип моңа ихтыяри-мәҗбүри рәвештә инанасың. Безнең телебез – бай, матур, зәвыклы тел. Һичшиксез, театр сәнгате телебезнең бөтен камиллеген күрсәтә. Тинчурин театры артистлары да шушы камиллеккә омтылып эшли, халкыбызга, телебезгә хезмәт итә», – дип билгеләп узды М.Әхмәтов.

Ул Тинчурин театры коллективына нәтиҗәле эше өчен рәхмәтен җиткерде. «Безнең тамашачы үзенчәлекле. Иҗади коллектив тамашачы белән бер язмышта, бер дулкында яши. Үзенең кыйбласын югалтмыйча яши. Татар тамашачысы үз язмышына тиңдәш образ эзләп килә. Атналар буе шушы образ белән сөйләшеп йөрергә мөмкин. Менә нәрсә ул театр!» – дип театрның даһи өлкә булуын ассызыклады.

М.Әхмәтов Тинчурин театры 90 еллык тарихының 60 елын үзәк бинасы булмыйча, илдән илгә, төбәктән төбәккә авылдан авылга күчеп тамаша кылып йөргәнен һәм бүген нинди дәрәҗәле театр булуын искәртте.

«Республикабыз бу яктан бәхетле. Бик күп дәүләт театрларыбыз бар. Безнең мәктәпләрдә балалар театрлары эшләп килә. Халык театрларыбыз бик күп. Киләчәгебезне матур итеп, телебезне, сәнгать, әдәбиятыбызны күрәсебез килә икән, театрыбызны сакларга кирәк. Гасырлык юбилеена тагын да зуррак уңышлар белән килсен. Яшәсен театрыбыз, яшәсен туган телебез. Туган телебез булса, театрыбыз, һичшиксез, яшәр!» – дип тәмамлады ул чыгышын.

Бәйрәм кичәсе дәүләт бүләкләре тапшыру, җырлы концерт номерлары белән дәвам итте. Шулай ук, театрның тарихы, данлыклы артистлары турында мәгълүмат бирелде.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА.

Расих ФӘСХЕТДИНОВ фотосы.

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесен югалту

Озак еллар Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып хезмәт иткән, язучы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дамир Гыйсметдин 5 ноябрь көнне бакыйлыкка күчте. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессы «Конгресс коллективы Дамир Минсәгыйрь улы гаиләсенең, балаларының авыр кайгысын уртаклаша. Мәрхүмнең урыны оҗмахта, авыр туфрагы җиңел булсын. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун», дип хәбәр итте.

Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдинов 1949 елда Чүпрәле районы Татар Тимәше авылында дөньяга килә. 1971 елда ул Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1975-1990 елларда «Чаян» журналында эшли. 2002 елдан ул ТР Язучылар берлеге әгъзасы, 2003 елдан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары вазыйфасын башкара.

10 ел дәвамында Д.Гыйсметдинов «Азатлык» радиосы белән хезмәттәшлек итә, хәбәрче булып эшли. Шул ук вакытта аның язмалары матбугат битләрендә дә дөнья күрә.

Дамир Гыйсметдин укучыларга язучы-сатирик, шагыйрь һәм күпсанлы эстрада җырлары авторы буларак та яхшы таныш.

Әдип белән хушлашу 7 ноябрь көнне «Казан нуры» мәчетендә үткәрелде.

Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Язучылар берлеге, «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе.

Санкт Петербургта мәктәпкә – Муса Җәлил, скверга Гатаулла Баязитов исеме бирелде

Санкт-Петербургның Калинин районындагы 146 мәктәбе Муса Җәлил исемен йөртәчәк. Санкт-Петербургның топономик комиссиясе шул хакта карар кабул иткән. Бу хакта «Татар-информ»га Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Ренат Вәлиуллин хәбәр итте.

«Безнең гомуми тырышлык белән шәһәрдә мәшһүр татарларның исемнәрен йөрткән тагын ике локация барлыкка килә. Җәмигъ мәчете янындагы сквер «Гатаулла (Атаулла) Баязитов исемендәге сквер» дип атала, ә 146 мәктәп Муса Җәлил исемен йөртәчәк. Санкт-Петербург Топонимик комиссиясендә бу карарлар кабул ителде», – диде Ренат Вәлиуллин.

Санкт-Петербург администрациясендә бу карар расланган.

Комиссия № 146 мәктәпкә татар шагыйре, Советлар Союзы герое Муса Җәлил исемен бирүне хуплаган. Бу мәктәптә Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге тырышлыгы белән Муса Җәлил музее ачылды, герой-шагыйрь истәлегенә чаралар уза.

Гатаулла (Атаулла) Баязит улы Баязитов (1846-1911) – җәмәгать эшлеклесе, Санкт-Петербург имамы, Җәмигъ мәчете төзелешенең инициаторы, беренче легаль татар гәзите «Нур»ның оештыручысы һәм 1905-1911 еллардагы баш мөхәррире.

tatar-inform.tatar

1 нче биттә – Карлы миләш.

Җинаятьнең сәбәбе – аракы

Донецк Халык Республикасының Волноваха шәһәрендә контракт буенча хәрби операциягә алынган ике солдат 9 кешелек гаиләне үтергән. Бу хакта «Коммерсантъ» сайты яза.

27 октябрь көнне шәһәрдәге шәхси йортта яшәүче Татьяна Капканец исемле хатынның 51 яшьлек туган көне билгеләп үтәләр. Туганнары белән бергә барлыгы 9 кеше җыела. Бәйрәм итеп бетергәч, алар йокларга ята. Төнлә йорт янына мотоциклда 30 яшьлек ике ир килеп туктый.

Мәетләрнең фотоларыннан чыгып караганда, корбаннар үзләренә һөҗүм булганны белми дә калган. Бу ике кеше башта хатынны, аның 53 яшьлек ирен, аннары икесенең уртак балаларын – Андрей белән Александрны атып үтерә. Андрей исә үзенең хатыны һәм ике баласы – 4 яшьлек улы һәм 9 айлык кызы белән, ә Александр хатыны һәм хатынының 19 яшьлек энесе белән килгән була. Аларны да атып үтерәләр.

«Барысын да башларына атып үтергәннәр. Караватларында яткан килеш. Йортны суга батырганнар – мөгаен, дәлилләрне яшерү өчендер. Үтерүчеләр – хәрбиләр, дип әйтә күршеләре», дип сөйли Капканецның күршесе.

«Коммерсантъ» язуынча, күршеләр бернинди шикле әйбер күрми. Алар бары тик мотоциклдагы ирләрнең хәрби киемдә булуына гына игътибар итә. Әмма нәкъ менә мотоциклны видеокамералардан күзәтеп, үтерүчеләрнең эзләренә төшәләр. Алар Капканецлардан ерак булмаган йортны арендага алып яшәүче контрактниклар булып чыга. Аларны кулга алалар.

Контрактниклар бары тик Эдуард Капканецны һәм аның ике улын гына үтерергә теләүләрен әйтә. Хәрбиләр әйтүенчә, алар арасында конфликт булган. Алар, имеш, караңгыда бутаганнар, шуңа балаларны да үтергәннәр. Соңыннан алар шаһитлар калдырмау өчен үтерүләрен таный.

«Коммерсантъ» язуынча, үтерүнең сәбәбе – аракы. Капканец бу хәрбиләр белән шул көнне көндез конфликтка керергә өлгерә. Исерек контрактниклар кибеткә аракы алырга килгән була, Капканец кибеттә аларга кисәтү ясый.

Тагын бер версия – Капканецлар, имеш, аракы саткан. Менә шуның бәясе аркасында алар арасында конфликт чыккан, янәсе. Контрактниклар: «Безгә хәмер сатмадылар, без хуҗаны гына үтермәкче идек, әмма караңгыда балаларны да үтердек», дигән, имеш.

Аларның мәетләрен 28 октябрьдә табалар. Тикшерү комитеты ачыклаганча, хәрбиләр Ерак Көнчыгыштан килгән була. «Ике һәм аннан күбрәк кеше үтерү» маддәсе буенча җинаять эше ачылган. Бу маддә буенча 20 елга яки гомерлеккә иректән мәхрүм итү каралган.

Татьяна, Эдуард Капканец, аларның уллары Андрей һәм Александр, Андрейның хатыны Наталья, аларның 4 яшьлек уллары Никита һәм башлангычта укыган Настя, Александрның хатыны Екатерина һәм аның 19 яшьлек энесе Дмитрий бер зиратта җирләнә.

Волновахада 9 кешелек гаиләне үтерүдә шикләнелеп кулга алынучылар «Вал» яки «Винторез» дип аталган махсус автоматлар кулланган.

Эшне хәрби тикшерүгә тапшырганнар. Үтерүдә шикләнелгән хәрбиләрне 1 айга кулга алганнар, моның өчен суд карары кирәк булмаган – Тикшерү комитеты хәрби хәл шартларында моны мөстәкыйль эшләргә хокуклы. Октябрь аеннан 4 яңа төбәктә – Луганск һәм Донецк халык республикаларында, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә хәрби хәл кертелгән иде.

Үтерүдә шикләнеп кулга алынучылар – 21 яшьлек Антон Сопов һәм 28 яшьлек Станислав Рау. Алар икесе дә Уссурийск шәһәреннән.

intertat.tatar/news. 2 ноябрь, 2023.

Азат Абзалов Тинчурин театры турында: «Тамашачылар спектакльләрне шатланып каршылый»

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов Кәрим Тинчурин исемендәге дәүләт театрын 90 еллык юбилее белән котларга килгән иде.

«Тинчурин театры коллективын бәйрәм белән котлыйм. Тамашачылар спектакльләрне шатланып каршылый, иҗатыгызга, һичшиксез, гаҗәпләнә, соклана. Көчле энергиягез, ташып торган дәртегез – республиканың чын горурлыгы, милли байлыгы. Барлык казанлылар һәм шәхсән үз исемемнән Россия театры үсешенә өлеш кертүегез өчен рәхмәтемне җиткерәм. Иҗатыгызда уңышлар юлдаш булсын!» – дип мөрәҗәгать итте Азат Абзалов.

Ул театр артистларына Казан шәһәре мэры Рәхмәте, Казан шәһәре хакимияте мактау грамоталарын тапшырды.

tatar-inform.tatar

Шагыйрь белән очрашу

Муса Җәлилнең музей-фатирында шагыйрь Рамис Аймәт белән «Һәр шагыйрь – бер дәрья» дип исемләнгән күркәм очрашу үткәрелде. Анда шигырь сөючеләр, Казан театр училищесының актерлык бүлегендә укучы беренче курс студентлары җыелды. Шагыйрь очрашу барышында башта үзенең тормышы һәм әдәбиятка килү юллары хакында сөйләде, әсәрләрен укыды. Тамашачылар шагыйрьнең иҗтимагый темаларга язылган шигырьләрен дә, лирикасын да рәхәтләнеп тыңлады. Соңыннан Аймәтне сорауларга күмделәр. Кичә ахырында актив сорау бирүчеләргә шагыйрь үзенең китапларын һәм әсәрләре яздырылган дискларны бүләк итте. Ике сәгатьлек шигырь кичәсе бер тында үтте. Шәкертләргә чын шагыйрь белән очрашу бик ошады – тәэсирләнгән йөзләре, янып торган күзләре шул хакта сөйли иде.

Э.СИРАҖИ.

ТАТАР ФАКТОРЫ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Бүген дә республикаларыбыз, халыкларыбыз уртак рухи дөньяда яши. Татарстанда милләтара мөнәсәбәтләргә махсус урын бирелә. Республика Рәисе янында Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге комиссия моның белән махсус шөгыльләнә, шушы юнәлештәге чараларны арттыра тора.

Камил хәзрәт Самигуллин җитәкчелегендәге Диния нәзарәте шушы изге эшкә үз өлешен кертә тора. Мөфтиебез мәчетләребездәге вәгазьләр тик татар телендә генә алып барылырга тиеш, дигән карар кабул итте. Республиканың төрле районнарындагы 100 дән артык мәчетләрендә татар телен өйрәнү курслары эшли. Аларны күренекле укытучыларыбыз җитәкли. Болар барысы да безнең күз алдыбызда һәм хәтеребезгә сеңә тора.

Хәтер – ул онытылмастай кичерешләр саклагычы. Аларның төрлесе була. Шәхси хәтер адәм баласының һәммәсендә дә бар һәм киләчәктә дә булачак. Алар арасында онытылганнары да, бик озак саклана торганнары да була. Тик алар ниндидер рәвештә кеше хәтерендә теркәлеп калмаса, аның үзе белән юкка чыга. Ләкин халык хәтере – мәңгелек. Аңа моң-зар да, кайгы-хәсрәтләр дә уелып бара. Сугышлар, революцияләр шундыйлардан.

Аларның берсе, татарлар өчен иң кайгылысы – 1552 ел, Казанның егылуы, татарларның коллык упкынына төшүе. Бу көн руслар өчен дә онытылмастай хәтерләрендә. Ләкин ул аларда, татарныкыннан аермалы буларак, бәйрәм булып саклана. Әмма бүген татарлар һәм руслар арасында аңлашу – бер-берсенә ышанычлы рәвештә.

Ышаныч – иң зур тойгыларның берсе. Ул тантана итсә, тынычлык урнаша. Ул исә гаиләдән башлана. Адәм баласының юл башы гаиләдә. Анда аның Ходай Тагәлә биргән теле ачыла, аңа изге хисләр, җыр-моң, халкыбызның гореф гадәтләре, яшәү көче иңдерелә. Гаилә кешене үз-үзенә ышанып яшәүгә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә. Монысы бигрәк тә әһәмияткә ия. Чөнки аны алда киң җәмәгатьчелек белән аралашып яшәү һәм үзенең гаилә тормышын кору көтә.

Ә гаиләдә иң беренче урында ата-ана. Алар балаларында халкыбызга, туганнарына, күрше-күләннәренә, гореф-гадәтләребезгә турылыклы булып яшәү хисләрен тәрбияли. Юкка гына оясында ни күрсә, очканында шул була, дип әйтелми. Чөнки бала уртак оясыннан очканда үзе белән киләчәккә шул хисләр белән оча һәм, шуңа охшаш гаилә корып, яши башлый.

Кешенең иң якын юлдашлары – бер бишектә тибрәнгән имчәктәш туганнары. Алар – аның гомерлек юлдашлары, авырлыкларны җиңеп чыгардай көч-куәт биреп торучылар. Бу ышаныч шулай ук гаиләдә иңдерелә. Аларның мөнәсәбәтләренең төрле вакытлары, ачуланышкан үпкәләшкән чаклары да була. Ләкин, халкыбыз әйтмешли, ачы булса да – туган, төче булса да – туган. Туганлык хисләре кешедә актык көненә кадәр саклана.

Шушы сыйфатлар буыннан-буынга күчеп, киләчәккә илтә. Бәхетле гаилә кешегә эшендә уңышларга ирешеп яшәрдәй мөмкинлекләр тудыра, аны алга этәрә. Аңарда үз-үзенә ышаныч тудыра һәм аны ныгыта. Ә үзенә ышанмаган кеше күпвакыт башкаларга да ышанмый. Ләкин, ничек кенә булмасын, адәм баласының үз яшәве аның үзегендә була. Аның үзеге ныклы булса, ышаныч аның үзенә һәм башкаларга карата да кимеми. Аралардагы дуслык хисләре арта. Монысы дошмани көчләрнең ныклап хәрәкәткә килгән көннәрдә бигрәк тә әһәмиятле.

Дус-дошманнар. Халкыбыз бу ике сүзне юкка гына бердәм итеп кулланмый. Чөнки шактый очракларда кичәге дус дошманга әверелә, ә кайчак кичәге дошман дус булып китә.

Дошмани хиснең төп чыганагы – көнчелек. Кайберәүләр көнчелекнең агы да карасы да була, ди. Чынлыкта, ул баштан ук аклы-каралы була. Агы тантана иткәндә адәм баласы уңышларга ирешеп яши, башкалардан көнләшми. Ә инде үз эшләре аксый башласа, ул күршеләреннән көнләшә. Шагыйрь Ләбиб Лерон дөрес язган: «Кеме генә юк татарның, Мәкерлесе, явызы: Сине йотам, диеп тора Кайберсенең авызы». Ни кызганыч, бүген дә шулай. Арада кичә дуслашып йөргән дустын йотарга торган мәкерлеләре дә юк түгел.

Әйе, заманалар үзгәрә. Әмма замананың башка вакытлары да булган. Андый вакытлар авыр, бигрәк тә сугыш елларына туры килә. Безнең заман – тормышның иң авыр вакытлары, 1941-1945 еллардагы Ватан сугышы. Бу халыкның тормыш хәлләре авырайган еллар. Ашау-эчүгә генә түгел, хәтта шырпыга да кытлык. Күршеләр соскыларын кулларына тотып, бер-берсенә күмер алырга керә. Ут күрше дигән әйтем нәкъ шул шартларда барлыкка килде. Бу – кешеләрнең бер-берсенә ярдәм, терәк хисләре тантана иткән заман.

Еллар яхшы якка үзгәрә башлагач, аларның берәүләре ярлы-ябагай булып, аеруча аталары сугыштан әйләнеп кайтмаганнарының тормышы бөлә, ә исән кайтканнарының тормышлары көрәя. Нәкъ шул шартларда көнчелек хисләре юлга чыга.

Моның бүгенге иң зур сәбәпләренең берсе – Россия һәм Украина арасында купкан канлы бәрелеш. Ике якның берсе дә чигенергә теләмәве, аларны котыртып торучы Көнбатыш илләренең үзара аңлашуга юл бикләве киләчәккә ышанычны кимәтә. Иртәгә ниләр булачагын берәү дә әйтә алмый. Моның өстәвенә Хамас белән Израиль арасында башланган канлы сугыш та йогынты ясый.

Безне халкыбызның шушы шартлардагы язмышы борчый. Татарлар бүген ике ут арасында. Аларның шактые Донбасс-Украинада, бер өлеше Израильдә, күпчелеге Россиядә яши. Шунлыктан алар бүгенге шартларда арадашлар булып, якларны бер-берсенә аңлашуга өлешләрен кертә алучылар булып тора. Җиңел түгел бу эш. Ләкин татар татарлыгын итә, шушы изге эшне дәвам итә. Аның үзәгендә Татарстан. Ул Россиягә каршы кертелгән санкцияләренә дә карамастан, уңышлар яулый тора. Ул башкалар өчен яшәү үрнәкләре тудыра.

Киләчәгебезне кайгырту беренче урынга чыга. Моның бер якты күренеше – балаларны, хәтта 5-6 яшьләреннән намазга өйрәтә башлау. Моңа үрнәкне Чуашстанның Тукай авылында күреп була. Монда милли хисләр, балаларны гаиләдән башлап мөстәкыйль тормышка чыгару яшәү рәвешенә әверелгән. Мәктәп укытучылары үзләре дә милли һәм дини хисләр белән сугарылган. Алар балаларга белем бирү белән бергә, догалар да өйрәтә. Мәктәп һәм мәдрәсә ышанычлы дуслыкта яши. Мәдрәсәнең интернет һ.б. җиһазлар тупланган классында бала үзен көчле хис итә. Гомумән, бу авылда тормыш кайный. Шәһәрдән күчеп килүчеләрнең саны арта. Шушы республиканың Шыгырдан кебек башка авылларда да мул тормышта яшәү тантана итә.

Мондый үрнәкләр күп. Пенза өлкәсенең 11 мәчетле Урта Әләзән, Татарстанның Шәле, Кирлегәч, Керкәле кебек авылларында да тормыш кешеләрнең бер-берсенә ышаныч белән сугарылып кайный. Балаларга милли һәм дини тәрбия бирү, аларга телебезне ныклап сеңдерү Себер һәм Уралда да яшәү рәвешенә әверелеп бара. Татарларның бер-берсенә таянып, ярдәмләшеп яшәве гадәти хәлгә әверелеп бара.

Соңгы көннәрдәге тагын бер мисал. Сүз 2022 елның ноябрендә Чебаксадагы «Шәриф» мәчетен төзегән профессор Марс Алиев, мәчетнең имамы Рөстәм хәзрәт үткәргән чара турында. Алар 5-12 яшьтәге балалар өчен Ильяс хәзрәт Җиһаншин мәчетендәге мәдрәсә шәкертләреннән торган жюри җитәкчелегендә конкурс оештырды. Чара ир балалар өчен аерым, кызлар өчен аерым үткәрелде. 50 дән артык бала катнашты. Җиңүчеләр билгеләнде. Балаларның барысына да бүләкләр тапшырылды. Шунысы да әһәмияткә ия: балаларның күбесе янында ата-аналары да бар иде. Шик юк, бу башлангыч дәвамлы булачак. Ә бу исә динебезнең ныгуы, аның яшәү терәге булуына якты юл. Ислам дине халкыбызның иң авыр чорларында да юкка чыгудан саклап калган. Бүген дә динебез шушы вазыйфаны үти.

Татар факторы, аның шушы һәм башка рәвештәге күренешләре Россиягә иминлек көче бирә, киләчәккә ышану хисләрен уята.

● Финанс министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елда россиялеләр 75 тонна инвестицион алтын коелмасы сатып алган. 2020-2021 елларда исә әлеге күрсәткеч 5 тоннадан артмаган. Ихтыяҗның мондый зур булуы сәбәпләре берничә: икътисади билгесезлек, геосәяси проблемалар, сумның зәгыйфьләнүеннән курку, дус булмаган илләр валюталарына ышаныч кимү. Моннан тыш, былтыр яз Россиядә банктан алтын коелмасы сатып алганда 20 процентлы өстәмә кыйммәт салымының гамәлдән чыгарылуы да куәтле этәргеч булып чыккан. Хәзер алтынның бәясе троя унциясе (31,103 грамм) өчен 1,9 мең доллардан арта. Быел аналитиклар бер унция алтын бәясе 2,1-2,2 мең долларга җитәр, дип фаразлый.

● Планетабыздагы тормыш сыйфаты турындагы глобаль Numbeo мәгълүмат базасы еллык Current Crime Index – «Шәһәрләр буенча җинаятьчелек индексы»н бастырган. Рейтингка кертелгән 416 шәһәргә криминаль куркынычлык дәрәҗәсенә карап 11 дән 83 кә кадәр балл бирелгән. Яшәү өчен иң куркыныч калалар дип Каракас (83,5 балл) (Венесуэла), Претория (81,9 балл), Дурбан (81 балл) һәм Йоханнесбург (80,8 балл) (КАР), Сан-Педро-Сула (80,7 балл) (Гондурас), Порт-Морсби (80,4 балл) (Папуа-Яңа Гвинея), Кабул (80,1 балл) (Әфганстан), Рио-де-Жанейро (77,6 балл) һәм Форталеза (77,1 балл) (Бразилия), шулай ук Элис Спрингс (77,3 балл) (Австралия) табылган.

Күңел рәхәтлеге

Роза Гавис кызы Салихованың театр дигән сәнгать дөньясында үзенең затлы, дәрәҗәле урыны бар. Тормыштан канәгать, яшь артистларның уенына мөкиббән китеп ихластан куана, аларның иҗатын ярата. Ул – бәхетле артист.

БЕЛЕШМӘ:
Роза Гавис кызы Салихова 1948 елның 20 сентябрендә Татарстанның Актаныш районы Усы авылында туа. Әлмәт театрына 1969 елда килә. Татарстанның атказанган артисты (1992), Башкортстанның атказанган артисты (1997), Татарстанның халык артисты (1998).
Уйнаган рольләре: *«Эх, Уфа кызлары»нда – Гөлчәчәк, «Шәмсекамәр»дә – Шәмсекамәр, «Трактирчы кыз»да – Мирандолина, «Өченче булмәдә эт яши»дә – Гөлия, «Җилкәнсезләр»дә – Дилбәр, «Ай тотылган төндә»дә – Тәңкәбикә, «Сөясеңме, сөймисеңме?»дә – Фатыйма, «Банкрот»та – Туганым һ.б.*

Аның белән сөйләшү, аралашу – үзе бер мәктәп. Кем өчендер тормыш – яшәү мәктәбе, кемгәдер – сәнгать юлында үз урыныңны табарга өйрәнү, ә кем өчендер – бөтен бер дөнья. Чөнки ул яшәүне, кешеләрне ярата, яшьлеккә, матурлыкка соклана, изгелеккә, өлкәннәргә, иманга хөрмәт белән карый, дуслыкның, туганлыкның кадерен белә, кичерә, көрәшә, җиңә.

Җыр-моңга гашыйк Актаныш кызы Әлмәт музыка училищесына укырга керергә дип китә дә, театрга килеп сарыла. 1969 елда кергән чибәр, сылу гәүдәле, көр тавышлы, янып торган кыз, инде зур дәрәҗәләргә ия, затлы, саллы актриса – бүген дә театрда. Аны таныйлар, аңа елмаялар, сокланалар.

Рольләрем түшкә тагылган медаль кебек

Ул ярты гасырдан артык сәхнәдә. Шул гомер эчендә нинди генә язмышларны үз җаны аша уздырмаган да, кемнәр генә булып көлмәгән, еламагандыр. Мәгърур буй-сын, затлы тавыш, нык холык һәм бик тирәндә, күпләрнең маңгай күзе түгел, күңел күзе дә төшеп җитмәстәй тирәнлектә бик нечкә, йомшак, илаһи җан.

Тамашачы алдына чыгып, аларга җан рәхәте, күңел тынычлыгы биргән артистның үзенә кем бирә икән аларны? Өйдә, гаиләдә, сәхнәдә рампа утлары да, тамашачы да, алкышлар да юк бит... Тик ул сайлаган язмышыннан һичкайчан зарлана белми торган ханым. Сер бирми торган, көрәшче, җиңүче, табигый сәләткә, иман ныклыгына ия артист. Ул тудырган образлар да шундый. Чөнки ул табигатьнең үзеннән көч алып яши.

– Артист өчен сәхнә ул – «наркотик». Әллә нинди авыр хәлдән дә айнытып, дөньяларын оныттырып җибәрә диләр. Сезнең өчен дә шулаймы?

– Шул-ла-ай. Сәхнәгә чыгуга, дөньяң түгәрәкләнә. Чир дә, мәшәкатьләр дә онытыла. Бер спектакльдә миңа таяк белән йөргән җирдән биек урындыкка артым белән сикереп менеп утырам. Болай гына йөргәндә мәңге утырып булмый.

– Чаллы театры өлкән артистларны эштән җибәрә, дип дөнья шаулады. Сез бу хакта ни уйлыйсыз?

– Юлда да уйлап киләм. Сиңа бит зарланырга урын юк, дим. Бәхетле артист булдым. Үзвакытында «Трактирчы кыз»да – Мирандолинаны, «Ай тотылган төндә» – Тәңкәбикә, «Җилкәнсезләр»дә – Дилбәр, «Шәмсекамәр»дә – Шәмсекамәр, «Җырчы сандугачым»да Мөнирәне уйнадым. Болар бит барысы да асыл рольләр, болар җан рәхәте. Болар бит түшкә тагылган медаль кебек. Әле хәзер чакыралар икән, елга һичьюгы бер роль эләгә икән – рәхмәт кенә. Китсәк тә, кемгәдер үпкәләрлек, рәнҗерлек түгел. Зарлану урынсыз. Минем бит хәзер партнерлар да юк. Кайсы кая киткән, кемдер бакыйлыкта. Без хәзер өчәү: Камил, Луиза, мин. Ходай безгә шулкадәр сәхнә гомере биргән икән – шатланырга кирәк.

– Роза ханым, туган көнегез уңаеннан Актанышка спектакль белән кайтырга җыенасыз икән...

– Ай, апаем, күңелемнең рәхәтлеге. Әлмәттә уйнавы бер хәл, ә менә үзеңнең «туган йортыңда»... Туган йортны бар кеше дә минемчә аңлыйдыр дип уйлыйм. Кайтып төшәргә

● Д.Салихов. Сәер кеше. Режиссер И. Гәрәев. 2008 ел. Наилә әби.

туган нигезең бар икән, моннан да олырак нинди бәхет булырга мөмкин?! Төп нигездә төпчек энекәшем яши. Алпавыт утары кадәр йорт. Кочак җәеп каршы алалар. Анда уйнау гел икенче, ул җаваплылыкны аңлата торган да түгел.

Әйе, Роза сөйләве буенча, Усыдан да матур җир дөнья йөзендә юк. Ул су буенда утырган туган нигез, аннан сузылып киткән тау итәге, тау башындагы каенлык, андагы җиләклек... Ул шундый итеп сөйли, мин хәтта Роза ханымның ауный-тәгәри тау итәгендә җиләк җыйганын да күз алдына китердем.

Күзләре яна, йөзендә елмаю. Роза ханым коллегалары турында сүзгә керешә. Аларның экранда күренүләренә дә, киенү, басып торуларына да сокла-

на. Чордашларының һаман да затлылыкларын югалтмауларына сөенә. Гомумән, башкалар өчен сөенә белү бүгенге көндә музейга элеп куйган, ак җитеннән тукыган кызыл башлы сөлге кебегрәк. Бар – тик ул бөтенесендә түгел.

– Әле менә шәһәр бәйрәмендә Камилгә (Камил Вәлиев) медаль тапшырганнарын күрдем. Интернетта. Ул басып торулар – мәһабәт, костюм, йөзкыяфәт. Искиткеч инде менә. Сөбханалла... Шул яшьтә бит ул. Чит кешенең, коллегаңның бәхетенә сөенә белү зур бәхет дип саныйм. Шатлыгымнан Луизага шалтыраттым, – ди ул. Партнеры, дублеры булган Дамира Кузаева, режиссер Зәкия Туишева исемнәрен дә сагынып, җан җылысы белән искә алды.

Сүзебез бүгенге сәхнәне тоткан яшьләргә күчте. Алар турында сүз чыгуга, Роза ханым үзе дә шул яшькә төште кебек, күзләре очкынланып китте.

– Бүген Әлмәт театрында гомер булмаганча яшьләр күп. Аларның бармаган шәһәре, катнашмаган фестивале, конкурслары юк. Әлмәт театрын бөтен Рәсәй белә. Алар сез уйнаганча уйнамый. Бүгенге яшь коллегаларыгыз турында ни әйтерсез?

– Бүген безнең яшьләр бөтен театр дөньясын дер селкетеп, кайнатып тора, апаем. Ә мин менә, чукынчык, яшьләрнең күбесеннән канәгать. Өлкәннәр уйнаганны яшьләр хәрәкәт белән эшли. Шул миңа ошый, шул рәхәтлек бирә. Бүгенге көн нәрсә таләп итә, алар шуны җиткерә белә. Аларның шул хәрәкәтләре, әйтәләр бит әле «соңгы штрих» дип, менә шул бер штрих белән биреп җибәрүләре күңелгә сары май булып ята. Яшьләрнең күбесе соклангыч итеп эшли. Үзләренең урыннарын чын мәгънәсендә аклыйлар. Театрга килеп керүгә алар сине кочаклап ала. Рәхәт инде. Элек без яшь чакта өлкән артистлар белән ике арада нindидер ара калдыру бар иде. Хәзер башкача.

Ул шатлана-шатлана сөйли. Чын күңелдән яшьләрнең уңышларына сөенә. Шаян елмаеп, алар булып сөйләп, үзләренең остазларын, партнерларын җылы хисләр белән искә ала. «Монысы үзеңә генә, газета өчен түгел» дип сөйләгәннәрендә дә берәүдән дә зарлану, кимсетү, гайбәтенә керү юк. Әйе, ул бик көчле актриса гына түгел, ул шәхес буларак та бик көчле. Үзгә нык аның. Шундый шәхесләр генә кеше бәхетенә сөенә, үч сакламый, кенә кумый, вакланмый.

Әйтсә – ике сөйләргә урын калдырмаслык итеп әйтә, үзен якларга көч таба, сүзгә кесәгә керми, җебеп, агып утырмый. Көчле шәхес, көчле актриса. Үзе дә көчлеләрне ярата. Үзе дә, йөрәге, эше дә зур. Ваклар белән вакланып тора торганнардан түгел.

Сөйләшеп сүз бетә торган түгел. Ләкин, ләкин... Һәрнәрсәнең дә үз тәртибе, үз җае бар. Без киләсе күрешкәнгә кадәр саубуллаштык. Затлы эшләпәсен килешле генә итеп төзәтеп куйды да, үз дәрәҗәсен, кадерен белеп, горур башын югары күтәреп, төз генә атлап кайтырга кузгалды. Урамда сентябрь җылысына куанып, берән-сәрән генә алтын яфраклар биешә. Ә алда туган якка кайтасы спектакль көне күңелен илаһиләндереп, рәхәтлек биреп тора иде.

РәфкатьШАҺИЕВ.
Әлмәт.

● С.Белов. Булмас димә дөнья бу (Мамуля). Режиссер И.Хәйруллин. 2006 ел. Әни.

● А.Несин. Ал җанымны, әфәнде. (Кто там). Режиссер А.Гаффаров. 2012 ел. Дорлижинан.

Казандагы Г.Тукай исемендәге әдәбият музеенда, атаклы язучыбыз Нурихан ага Фәттах тууга 95 ел тулу хөрмәтенә, аны искә алу кичәсе булып узды. Кунакларның байтагын Нурихан абыйның тормыш иптәше Руфинә ханым чакырса да, кичә Мәдәният министрлыгы, республиканың Милли музее, Язучылар берлеге, Казан театр училищесы һәм, билгеле ки, Г.Тукай исемендәге әдәбият музее хезмәткәрләре тырышлыгы белән оештырылды. Нурихан абый халык күңелендә һич тә онытылмый, аны сагыналар, моны тамашачыларның музей бинасын тутырып килүе дә раслады. Шул ук вакытта һәркемне «Мондый күренекле язучыны искә алу кичәсен зуррак залда уздырырга ярамый иде микәнни соң?» – дигән сорау да газаплады.



Галимнәр галиме Нурихан ага

Кичә Нурихан аганың «Сызгыра торган уклар» романы буенча эшләнгән рәсемнәр күргәзмәсенә сәяхәттән башланды. Монда да сер ачылды: музей диварларына эленгән рәсемнәрне Фәттаховлар гаиләсенең кияве, Нурихан ага кызы Зөләйханың тормыш иптәше Руслан Ибраһимов әзерләгән икән.

Кичәне «Нурихан Фәттах Казаны» дип аталган музыкаль пластик композиция ачып җибәрде. Казан театр училищесының 3 татар курсы студентлары (остазлары – Татарстанның атказанган артистлары Лилия һәм Илнар Низамиевлар) һәм К.Тинчурин, Г.Кариев исемнәрендәге театр артистлары катнашында авторның әсәрләреннән өзекләр уйнап күрсәтте. Кунаклар әдипнең автобиографик нигездә язылган «Кичү» романы буенча куелган күренешләрдә яшь Нуриханның үзен күргән кебек булды, шәкертләре аның буйсынмас һәм ихтилал тулы холкын чагылдыра алды. Бу уңайдан кичәнең режиссеры Александр Далматов белән хореограф – Г.Камал театры актеры Артур Шәйдуллинга рәхмәт хисләре белдермичә булмый. Шулай ук Актаныштан ук килеп җиткән һәм Нурихан аганың «Әтил суы ака торур» романы буенча тарихи өзек күрсәткән халык театры артистларына да рәхмәт.

Кичәдә Казан шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, халык язучысы Рабит Батулла, күренекле язучы Вахит Имамов, «Сәхнә» журналының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр, шагыйрьләрдән Рүзәл Мөхәммәтшин һәм Нурихан аганың райондашы Нәҗибә Сафина, яраткан артистыбыз Равил Шәрәфиев, Г.Тукай исемендәге әдәбият музее мөдире Гүзәл Төхбәтова һ.б. чыгыш ясады. Резидә Төхфәтуллина, Муса Камалов халык җырларын башкарды. Искә алу чарасын К.Тинчурин театры актрисасы Резидә Сәлахова алып барды. Һәммәсе дә Нурихан аганың татар халкын тарихи яктан агартучы булуын ассызыклап үтте.

Милләтебездә элгәрәк тә тарихи теманы кузгаткан Афзал Таһиров, Газиз Гобәйдуллин кебек язучылар булган-булуын. Ләкин алар «Ямәлкә тавы» атлы хикәя һәм «Татар тарихыннан сәхифәләр» дигән очерк тудырудан ары китә алмаган. Ә татар әдәбиятында тарихи роман жанрына, иң беренче булып, Нурихан ага Фәттах нигез салды. Ул үзенең «Сызгыра торган уклар» романында татар милләтенең ерак бабалары моннан ике мең еллар элек Азия кыйтгасы киңлегендә яшәве, әле шул вакытта ук кытай, монгол, найманнарга каршы көрәш алып баруы, арадагы кайбер әйдәман нәселнең чин императорлары булып торуын да ярып салды. Тарих фәне докторлары әлеге хакыйкатьне дистәдән артык еллар узганнан соң гына таныды, тарихи чишмәне асылда Нурихан абый ерып җибәрде.

«Әтил суы ака торур» романында да без ерак бабаларыбызның VIII-IX гасырларда Идел-Чулман буенда искил (эчке ил), барсил, казаяк, сувар кебек ыру-кабиләләргә бүленеп яшәве һәм ислам диненең кабул иткәннән соң гына Бөек Болгар дәүләте булып оешуы белән таныштык. Әдипнең тарихи һәм әдәби фантазиясе ул елларда йөз меңләгән татар укучысын аның романыннан аерылмыйча яшәргә мәҗбүр итте.

Ләкин бер мең, ике мең ел элеккеге тарихка чумсаң да, әдип яшәгән чор аны үз заманының вакыйгалар тырнагыннан ычкындыра алмый. Нурихан ага да татар балаларын «ил токтасы булган өлкән агай дәрәҗәсенә мендерәбез», дигән мәкерле әләм астында инкубатор чебешләре төсле умырткасыз шәкертләр, ә дөресе – эш атлары әзерли торган карагруһчыл урыс мәктәпләренә куып кертүләргә дә, Мәскәү мөтәгалимнәре язып биргән уйдырма тарих дәреслекләренә дә, ахыр чиктә коммунистлар фиркасе һәм ул билгеләгән хөкүмәт каршында тез чүгеп яшәүләргә дә каршы чыкты. Үзе Башкортстанның Яңавыл районында туып-үскән әдип булганга күрә, анда коточкыч басым астында алып барылган «башкортлаштыру» сәясәтенә дә үз нәфрәтен белдерүдән тартынып тормады.

Тик аянычы шул: андый мәкерле сәясәт Нурихан абый заманында ук колач җәйгән иде, хәзер тагын да яманрак котыра. «Биналары искерде, ремонт таләп итә» дигән сылтау астында, әнә, Мишкә районындагы быел барча татар мәктәпләрен ябып бетерделәр. Татар телендә укытудан башкортча укытуга күчмәгән өчен, Кушнаренко районындагы Байталлы урта мәктәбен бөтенләйгә ябып юк иттеләр. 2002 һәм 2010 елгы җанисәпләр арасында гына да Башкортстанда яшәүче татар халкының саны өч йөз меңгә кимеде. Кушнаренко, Яңавыл, Борай, Илеш, Чакмагыш, Балтач, Авыргазы, Тәтешле, Чишмә, Кырмыскалы, Туймазы, Бакалы, Ярмәкәй, Краснокама, Калтасы районнарында, әнә, сыңар гына башкорт авылы да юк, Бүздәктә берәү, Нуриманда икәү, ләкин шуңа карамастан отчет кәгазьләрендә андагы башкортлар санын 55-80 процент дип шәрран ярудан һич тә туктамыйлар.

Башкортстанда «тарих» хәзер гел башка төрле, яңача языла. Галимнәр элгәрәк тулысынча татар белән мишәр халкы яши торган Чишмә районнарындагы Түрәхан һәм Хөсәен бәк кәшәнә-мавзолейларының XIV-XV гасырларда ук Болгар карьерыннан алынган ак ташлардан салынган булуын исбат иткән иде, ә башкорт мөтәгалимнәре бүген аларын да тарихта бөтенләй булмаган һәм була да алмаган «башкорт ханнарыныкы» дип бугаз ярa. Мәскәү белән Уфа мөтәгалимнәре «башкорт полклары» дип күкрәк суккан гаскәрләрнең яртысын да татар белән мишәр яугирләре тәшкил иткән. 1757 елда Пруссиягә ясалган походта яртысыннан күбрәген татар сугышчылары тәшкил иткән полкларны – бүгенге Актаныш районыннан чыккан Тимер Мутин, ә 1771 елгы Польша походында Башкортстандагы Балтач районы мишәре Кулый Балтачев атлы старшина җитәкләгән. «Мәдәни җомга» газетасы элек Актаныш районы җирләрендә урнашкан Гәрәй, Йәнәй, Буләр волостьларыннан Пруссия походына барган 100 гә татар сугышчысының, 1812 елгы Ватан сугышы чорында Минзәлә өязеннән тупланып, чит илләргә барган һәм Парижны яулауда катнашкан 200 гә якын татар җайдагының исемлеген бәян итте инде. 1771 елда Польшага 300 әр кешелек 10 отряд алып барган старшиналарның да күпчелеге татар, соңыннан шулар ук якташлары белән Пугачев «падишаһ» гаскәрендә азатлык даулап йөргән. 1812 елгы Ватан сугышында да Оренбург губернасы буйлап җыелган 20 «башкорт» полкының ким дигәндә 5-6 сын Минзәлә өязендә яшәүче татар һәм типтәрләр төзеп биргән. Ул вакытта Бөре өязендә саналса да, чип-чиста татар районнары булган Балтач, Чишмә, Кушнаренко, Яңавыл, Чакмагыш, Борай, Тәтешле сугышчылары да «башкорт» яки «мишәр» полклары, дигән атаманы йөрткән. Бу рәвешле саный китсәк, шул ук Кырмыскалы, Авыргазы, Нуриман, Ярмәкәй, Туймазы, Шаран районнары да бар бит әле.

Әмма иң аянычы – Татарстанда яшәүче 1300 чамасы фән докторы һәм 11 меңгә якын фән кандидаты арасында 1757 елгы Пруссия, 1771 елгы Польша походлары, 1773 елда кузгалган Пугачев фетнәсе, 1812 елда башланган Ватан сугышы тарихлары буенча сыңар гына да фән кандидаты юк, галимнәр юк. Башкортстандагы Салават Юлаевны 1927 елда аларга беренче бишьеллык планны нигезләү өчен тикшерергә килгән Степан Злобин атлы чит-ят шәхес, әммa «өлкән агай» вәкиле күтәреп чыкты. Моны шәхсән Сталин үзе дә яклагач, Башкортстандагы дистәләгән аспирант шул темага ябырылды, нәтиҗәдә 30 дан артык «галим» – «фән докторы», тагын шул кадәрлесе «кандидат» дәрәҗәсен яклап өлгерде. Ә татарның, нәкъ Салават шикелле үк, Пугачев армиясендә бригадир дәрәҗәсенә ирешкән Бәхтияр Канкаев, Канзафар Усаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов кебек каһарманнары, тагын Салават Юлаев отрядында аның уң кулы булып яу йөргән Габдулла Туктаров, Кукмараның Пычак авылыннан чыккан Мәсәгуть Гомәров, Биектауның Кавал авылы вәкиле Исхак Әхмәтов, Әлмәт районының Иске Абдул авылы үстереп биргән аталы-уллы Әит һәм Габдерәшит Уразмәтовлар, Әгерҗенең Тоба авылыннан чыккан Әбҗәлил Сөләйманов шикелле 40 ка якын полковнигы бар, ләкин Татарстандагы сыңар гына урам яки тыкрык та алар аты белән аталмаган, сыңар бюст куелмаган...

Үзвакытында мондый гаделсезлек һәм сансызлык өчен галимнәр галиме Нурихан аганың җаны бәргәләнә иде, хәзер аның шәкертләре өзгәләнә, яна. Җитәкчеләр милли мәнфәгатьне төпсез кесәләре хакына күптән сатты инде. Ә 15 ел буе – татар тарихы, соңгы 5 ел буе татар әдәбиятыннан читләштерелгән буын бу мәхшәрне аерыр һәм аңлармы?..

И. ВАХИТОВ.

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

Тынлык көен тыңлыйм дисәң, Сиңа әле иртәрәк...

БОРЫЛА ДА КАРЫЙ

Кара көздә,
Арагызда
Бардыр аклык тансыклаган;
Көтмәгәндә, төн эчендә
Сырлан-сырлан
зыкы сарган –
Зыкылаган карамалар!

Аклык тансыклаган карамалар...
Ыкның кара сулы көзгесенә
карамыйлар,
Тарамыйлар
Сырлан-сырлан
зыкы сарган
толымнарын,
Көнозын тарамыйлар...
Җилләр дә юк! –
Зыкы сарган толымнарны
Кызыгып тарамыйлар...

Җәйләр буе
Су кызының
Озын чәчен тарый-тарый,
Тараклары да юкарган! –
Ярамыйлар!
Караманың толымнарын
Сырлан-сырлан зыкы сарган, –
Зыкылаган!
Аклык тансыклаган карамалар
Карасу Ык көзгесенә
көнозын
карамыйлар...

Карамалар, карамалар!..
Шау чәчәктә
килеш корган
Алмагачлар бакчасына
Борыла да карый алар...

Шау чәчәкне
килештергән
Алмагачлар бакчасына
Борыла да карый,
Борыла да карый
Карамалар.

ФӘИЗ ЧИШМӘСЕ

Таллы тауда;
Караталда –
Тамырлар...

Талган булсаң,
Табаныңнан
Танырлар.

Караталда
Абынмаса
Тамырсызлар,

Тамыр сызлар...
Тамыр сызлар...
Тамыр сызлар! –

Таллы тауда
Талымласа
Талымсызлар,

Су тамыры...
Су тамыры
Сыкырап сызар!

ТАМЫРСЫЗЛАР

– Тамырсыз алар ничек яши икән?..
– Алар ничек яши икән...
Тамырсыз?!

Бер-берсенә имәнгеч сорау биргән
Имәннәрне
Шаулавыннан
Танырсыз...

Саргайтмады салкын җил сарылганын
Сабырсыз
Шомлавыннан
Танырсыз...

– Тамырсыз алар... Ничек яши икән?.
– Алар ничек яши икән...
Тамырсыз?!

Агачлар бер-берсеннән сорый төнлә,
Сорый,
Бер-берсенә
Шом салып...
Бу сорауга әгәр җавап эзли калсаң,
Җаның куяр шомланып...
Җаның куяр шомланып...

ИЛ БЕЛӘН СУГЫЛСАҢ

(Мәрсия)

Илдус Гыйләҗевкә

Аягүрә басып
Алкышлады яңгыр!
Соңгы җырымны да
Казанга багышлыйм..

Ничек инде түзсен,
Күңел тулышмасын? –
Яңгыр аягүрә
Арыш булып шаулый!

Игенче токымы –
Иң соңгы могикан,
Җаның моңаешкан... –
Юксыну явадыр.

Ил белән урылсаң...
Ил белән сугылсаң...
Ил белән сөрелсәң!..
Калыр да тамырлар,
яңгырга ялганыр...

Ялгана яңгырга урылган камыллар, –
Арыш булып
Шаулый ул яңгыр!

СИРТМӘ КӨЕ

Куертып кич, кубалый җил.
Ай шәүләсе пошаманда:
Яу узгандай туган нигез, –
Уалмаган таш калмаган!..
Туган нигез ышыгыннан сәлам бирде! –
Балачакның чикерткәсе
Баш салмаган...

Тигезләнгән туган нигез –
Тартылмаган таш калмаган,
Мине дә бит читкә тартты...
Тегермәннәр иткә тартты –
Тартылмаган төш калмаган...

Сиртмә көйле чикерткәләр
Нигеземне ташламаган!
Кичләр генә
төшеп килә,
эңгер көйләп... –
Тибрәнми чикерткә –
Бәллүкәен башламаган...

Чикерткәләр! Чикерткәләр!
Бишек тирбәткән сиртмәләр!
Һаман көйли тирбәнгәләп, –
Тынлык көен тыңлыйм дисәң,
Сиңа әле иртәрәк...
Сиңа әле иртәрәк...

Сабый айны алып алга,
Төн буена тыңлармын.

Чыклар белән бергә төшәр
Күз яшьләрем...
Тынар моң.
Бишегемнең сиртмә көен –
Тынлыкны да...
Тыңлармын.

Сиртмә көйле чикерткәләр!
Җан тибрәткән сиртмәләр!
Көйли әле тирбәнгәләп, –
Тынлык көен тыңлаучылар
Тирәндәрәк...
Тирәндәрәк...

И ГОМЕРКӘЙЛӘР...

I

Вакыт ага
Яктылыктай,
Дулкын-дулкын нурын кагып,
Урын табып саркылырга...
Җиһан түрләреннән
ургый тагын!

Булмаганны бар кылырга...
Булмаганны бар кылырга!

Вакыт ага яктылыктай:
Караңгыдан –
караңгыга...

Сезгә тигән якты вакыт:
Гомеркәйләр –
хәйран гына!..

II

Яктылыктай ага вакыт,
Дулкын-дулкын нурын кагып,
Урын табып укталырга...
Җиһан түрләреннән
ыргый тагын

Бар булганны юк кылырга...
Бар булганны юк кылырга!

Яктылыктай ага вакыт:
Караңгыдан –
караңгыга...
Сезгә тигән якты вакыт –
Бер сирпелеш...
саран гына...

ЧИКСЕЗЛЕК ТАМГАСЫ

Якты алып китсәң иде
Мәңгелек караңгысына.

Тезләр арасына
Якты казлар салып,
Бармак очкайларын
Суга манып-манып,
Каз йолкамы сездә
Килен-сеңелкәшләр?! –
Гомеркәйнең
Соңгы мендәренә
Якты мамык эзлим,
Якты мамык...

Якты алып китсәң иде
Мәңгелек караңгысына.

Тезләр арасына
Якты казлар салып,
Бармак очкайларын
Нурга манып-манып,
Каз йолкамы әле
Килен-сеңелкәшләр?! –

Гомеркәйнең
Сәфәр сүрүенә
Якты мамык эзлим,
Якты мамык.

Якты алып китсәң иде
Мәңгелек караңгысына...

XXI ГАСЫР

(Хәдис)

Галәмчеләр күптән инде
Айкыйлар күкне.
Гайбәтчеләр күптән инде
Чайкыйлар күкне! –
Гыйбадәтләр күктән инде:
– Гыйбрәтләр күпме!
– Гыйбрәтләр күпме!
Үз чигәсен күрмәгәннәр
Ничек күрсен
Чүп тә төшмәс...
Күкне?!

ВАКЫТ АГА

Вакыт сиңа агай түгел,
Хөрмәтләп дәш:
«Вакыт ага!»

Көнне төнгә ялгый-ялгый,
Әзәлдән үк вакыт ага...

Әзәлләрдән агып чыккан
Ул бердәнбер елга ласа:
Таллар булып,
ярларына
Татар токкан еллар баса...



КИРЛЕМАРДА

Чирмешән районында урнашкан бу тау турында берничә ел элек ишеттем, аның фаҗигале тарихы тетрәндерде. Моңа кадәр татар концлагерьлары турында ишеткән юк иде, ә ул моннан 90 ел элек, нәкъ менә Кирлемар тавына, Кармыш белән Әшәлче авыллары арасына урнашкан булып чыкты.

Халык телендә бу шомлы урынны «лишуннар тавы», «кулаклар поселогы» дип тә йөртәләр икән, болар хакында Зөләйха Шәрәпова-Ханова һәм Дамир Таҗиевның 2017 елда Казанда басылып чыккан «Шау чәчәкле болынлыкта – Әшәлчем» дип аталган документаль китабыннан белдем. Әле бу тау итәгендә «таш казаннар» дип аталган бик серле урын да бар икән, анысын да күрәсем килде. Быел, җәйнең челлә вакытында Зөләйха сеңел белән аның туган якларына кузгалдык...

Сәфәребезне тау итәгендәге таш казаннардан башладык. Алар, чыннан да, гадәти түгел, болар без күреп өйрәнгән тимер казаннардан да, хәтта тарихи скиф казаннарыннан да дистәләрчә, йөзләрчә тапкыр зуррак булып чыкты. Аларның кайберләре инде кипкән елга төбендә тәгәрәп ята, кайберләре, тау бите юылып, җир астыннан күренеп кенә тора. Бу сәер ташларның барысы да казан рәвешендә түгел, өстәл төслеләре дә, ташбаканы хәтерләткәннәре дә бар. Аларның өсләрен безнең заман кешеләре үз исемнәрен язып, чуарлап бетергән, әмма бу таш казаннарның серлелеге югалмаган, алар мәгърур, матур һәм шомлы... Галимнәр бу ташларны өйрәнмәгән, ахры, өйрәнсәләр, алар халыкка билгесез калмас иде.

Таш казаннар үзләре үк бик борынгы, таш гасырларга ишарә, ә ул миллион еллар белән исәпләнә, беренче кешеләр дә шул чорларда яшәгән. Шунысы да бар, «мар» сүзе электән каберлек, дигәнне дә аңлаткан, Чиләбе якларында борынгы курганнарны хәзер дә мары, диләр. Әмма бездә аңлашылмаган сүзләрне, бигрәк тә, җир-су атамаларын, тиз генә удмурт-чуашларга биреп куялар, монда да Кирлемарны – чуашныкы, Әшәлчене – удмуртныкы, дип баралар. Югыйсә, бу тирәләр элек-электән Болгар дәүләте составында булган, бу хакта әле дә сакланып калган борынгы урлар, болгар табылдыклары сөйли. Кармыш авылы да Казан ханлыгы чорларында ук яшәгән булырга тиеш, ә Әшәлче исә аннан бары тик совет елларында гына аерылып чыга. Ягъни, узган гасырның утызынчы еллар башында тау астында – совет Әшәлчесе, тау өстендә – «кулаклар»ныкы төзелә. Әмма «Населенные пункты РТ» китабында (Казан, 1997) Яшәүче-Әшәлче авылының тарихын XVIII гасыр белән билгеләгәннәр. 1998 елда галимнәр Әшәлче авылыннан ерак булмаган урында, Шушма елгасы яр буенда, археологик эзләнүләр алып бара һәм болгар чоры савыт-саба калдыкларын таба. Галимнәр монда урта гасырларда ук торак урыны булган, дигән фикергә килә, фәндә аңа «Сальцинское Селище» дигән исем бирелә. Биредән ерак булмаган Новотроицкое авылы янында борынгы курганнар да табылган, алар археологик картага төшерелгән.

Халык телендә таш казаннар яткан бу урынны җенле урын дип тә, изге җир дип тә йөрткәннәр, белгән кешеләр аны әйләнеп үтәргә тырышкан. Әмма интернет заманында серле таш казаннар турында хәбәр дә дөнья буйлап таралган. Хәзер монда килүчеләр хәтсез, кемгәдер хикмәт, кемгәдер тарих кирәк. Бу урыннарны күршедәге чуваш-удмурт халкы да үзенеке итеп күрсәтергә тырыша. Таш казаннар яткан урынны, Биләрдәге кебек, чүпрәк-чапрак бәйләп, мәҗүсиләрнең табыну урыны ясарга да мөмкиннәр, шулай ук Аркаимдагы кебек, хикмәт эзләп җенләнеп йөрүчеләр дә табылыр. Шуңа бу урыннарны, тарихчы галимнәрдән тикшертеп, тыюлык урыны итеп игълан итү һәм әйләндереп алу хәерлерәк...

Кирлемар тавы, таш казаннар, «кулаклар поселогы» турында теләсә нәрсә язучылар да бар. Ярар, таш казаннар турында хәзергә беркем берни белми, әмма Кирлемар тау башында урнашкан «татар концлагеры» турында белүчеләр дә, бу хакта дөресен язучылар да бар бит! Шул ук З.Шәрәпова-Ханова һәм Д.Таҗиевның югарыда телгә алган китабында болар хакында «Кирлемар тавында «Мәхрүмнәр». Әшәлче кулак поселогы» дип аталган тулы бер бүлек бар, анда сөрелгән кайбер кешеләрнең исем-фамилияләре, авыллары, шул концлагерьда исән калганнарның истәлекләре урын алган. «Татарстан» журналында һәм «Ирек мәйданы» газетасында чыккан язмалардан күренгәнчә, имеш, утызынчы елларда бу тауда мулла гаиләләре үз теләкләре белән качып яткан икән, ирләре үз теләкләре белән Себер якларына киткән, аннан гаиләләрен кайтып алган. Бу фаҗигале хәлләр турында бик мәгънәсез аңлату, дөреслекне яшерү, халыкны зур газапларга дучар иткән совет хакимиятен, чекистлар режимын акларга маташу.

Кулаклар поселогы

Менә без дә Кирлемардагы «кулаклар поселогында», «лишуннар чокырында»... Без, дигәнем – шушы урынны күрсәтү өчен Казаннан туган авылына махсус кайткан журналист З.Шәрәпова-Ханова, аның әтисе, биредә колхоз рәисе булып эшләгән 91 яшьлек Шәфигулла абый Шәрәпов, Шәфигулла абыйның Кармыштагы улы Фәрит һәм килене Фәүзия ханым, оныгы, 9 яшьлек Әмирхан... Бик эссе көн, җил иссә дә, тау башында су эчәргә чишмә дә, ышыкланырга агач та юк. Тау дигәне дә әлләни биек түгел, әмма урыны-урыны белән текә, турыдан «иярләү» мөмкин түгел, әйләнеп йөрергә кирәк. Узган гасырның утызынчы елларында нигә шушы урынны концлагерь итеп сайладылар икән? Монда эчәргә су, ашарга ризык та, торырга бина да юк, тау башындагы буш кыр бу. Зәһәр челләләрдә, кышның зәмһәрир суыкларында, кар-яңгырларда нишләсен вә кайда яшәсен бу бичара мәхбүсләр? Бәлки, аларны үләр өчен монда махсус китереп ташлаганнардыр? Ачлыктан, сусызлыктан, катып-өшеп тизрәк үлсеннәр өчен, бер ярдәмсез монда тотканнардыр? Болар бит берсе дә биредә очраклы тоткыннар түгел, тирә-яктагы татар авылларыннан куып китерелгән мулла, хәлле кешеләрнең, укымышлы байларның ишле гаиләләре... Ягъни, совет власте өчен ышанычсыз кешеләр... Аларның бер өлеше шушында ачлыктан һәм салкыннан катып үлә, исән калганнарын, мал вагонарына төяп, сөргенгә сөрәләр, аларның да бер өлеше юлда үлә, бер өлеше, тоткын буларак, Себер-Магниткаларга барып егыла..

Туган авылларыннан сөрелгәннәрне Әшәлче авылы янындагы Кирлемар тау башына китереп ташлау Чирмешәндә, ул вакыттагы Беренче Май районы башкарма комитеты карары белән эшләнгән. Гадәттә, гаилә башлыкларын, кулаклар дип кулга алып, хөкем карары чыкканчы шул тирәдәге төрмәләргә, чиркәүләргә япканнар, ә ишле гаиләләрен, сөргенгә сөрелгәнче, шушы тау башына менгереп ташлаганнар. Хөкем карары чыккач, алар гаиләләре белән Себергә, Магнитка төзелешенә сөрелгән, әгәр гаилә башлыгы атып үтерелсә яки озак вакытка иректән мәхрүм ителсә, ул чагында гаилә әгъзаларының үзләрен генә сөргәннәр. Кирлемар тавында илдән куылганнар өчен вакытлыча барлыкка килгән бу «кулаклар поселогы» 1930-1932 елларда яши, өч ел буе анда конвой белән тоткыннарны китереп ташлыйлар, конвой белән биредән сөргенгә озаталар. Өч ел буе биредә, землянкалар казып, тоткын татарлар яши, халык ачлыктан кырыла, балалар һәм карт-карчыклар, ачлыкка түзә алмыйча, тирә-як авылларда хәер сорашып йөри. Тау астында яшәгән Әшәлче һәм Кармыш авыллары халкы, тормышларын куркыныч астына куеп, кача-поса Кирлемар тавындагы мәхбүсләргә ашарга илтә, кайбер мәетләрне авыл зиратына алып төшеп җирлиләр.

Әшәлче авылында туып-үскән, шушы җан тетрәндергеч хәлләр

ТАРИХ БАР...

турында эзләнүләр алып барган, хәзер Әлмәт шәһәрендә яшәүче Д.Таҗиев һәм З.Шәрәпова-Ханова китабыннан бер өзек китерик:

«1930-1931 елларның җәй, көзкыш айларында биредә бүреләр улап торган урынга кешеләрне йорт-җирләреннән куып китерәләр. Байлардан, дин әһелләреннән тартып алынган мөлкәт яңа күмәк хуҗалыклар төзү өчен бик тә ярап куя. Мәхбүсләр Кирлемарда землянкалар казып өч еллап яши. Су өчен чокып кое ясаганнар, начармы-яхшымы җәмәгать мунчасы да әмәлләп куйганнар. Хәтта шуның өчен дә килеп, налог салып китә торган булганнар... Халык бу тауны «лишуннар тавы», «лишуннар чокыры» дип тә йөрткән. Картлар сөйләвенчә, лишуннар киткәч, күп еллар дәвамында монда бала елаган тавыш ишетелә, имеш, халык бирегә хәтта көтү дә кумаган. Вакытсыз өзелгән кайсы жанның инрәве булды икән бу? Әллә исемсез каберләрдә ятучы сабыйларның дога өмет итүләреме?» (Шау чәчәкле болынлыкта – Әшәлчем. – Казан, 2017, 181 б.)

Халык та бу хәлләрне хәтерли, искә ала. 2009 елның көзендә Кармыш авылында шушы тарихи вакыйгаларга нисбәттән, Хәтер көне уздырылган, мәктәп укучылары «Әшәлче кулак поселогы», дип аталган сәхнә әсәре күрсәткән, аның авторы җирле үзидарә башлыгы Наил Гөлемов булган, ул хәзер инде мәрхүм. Шушы ук шәхес тәкъдиме белән, Кирлемар тау битенә яшь наратлар утыртылган. Авыл активистлары Кирлемар тавына таш манара рәвешендәге истәлек билгесе, ярымайлы төрбә дә куярга тели.

Шәхес культы, репрессияләр турында күп өйрәндек, яздык, әмма үзебезнең Татарстанда да татар кешеләрен шулай кырәләтә үлемгә дучар иткәннәр, карап торып үтергәннәр икән! Суслонгерның татар варианты булган инде бу, анда да бит сугышка китәсе татарларны, бигрәк тә, дин әһелләренең балаларын, репрессиягә эләкмәгән байларны шунда яткырып, ачка үтергәннәр, чөнки алар совет хакимияте өчен ышанычсыз кешеләр булган. Әшәлче тау башындагы «кулаклар поселогына» да дин әһелләрен, байларны, укымышлы татарларны китереп атканнар. Үзем дә шундый бер гаиләнең тарихын өйрәндем, аларның сөргенгә сөрелгәнче газап чиккән урыны менә шушы Кирлемар тавындагы «кулак поселогы» булып чыкты.

Сүз хәзерге Аксубай районының Иске Ибрай авылыннан сөрелгән Ногман карт гаиләсе турында бара. 1931 елның мартында аларны оялары белән сөргенгә сөрәләр. Кулак дип сөрелүче Габдрахманның этисе – Ногман карт Саматов була, исемлектә аның 80 яшьлек хатыны Гамирә, улы Габдрахман, икенче балага авырлы килене Маһруй, оныклары 2 яшьлек Сания бар... Ногман картның икенче улы Хәсәнгата да хатыны Фатыйма белән сөргенгә сөрелә. Димәк, алар да, казах далаларына сөрелгәнче, башта Кирлемарда үлем көтеп яткан була. Болар хакында сөйләүче-белүче юк, әмма документлардагы «кулак поселогы» дигән тамга бу ишле гаиләнең дә Кирлемар корбаны булуын күрсәтә. Аллаһ рәхмәте белән, алар бу Кирлемар чокырыннан исән чыга, Урта Азиядәге сөрген газапларын да кулга Коръән тотып үтәләр, кайда яшәсәләр дә, иманга тугры калалар.

Бәлки, мондый тау башындагы төрмә-лагерьлар Татарстанда тагын булгандыр, бәлки, кемнәрнеңдер әби-бабалары, якын туганнары анда газап чиккәндер? Мондый хәлләр онытылырга һәм кабатланырга да тиеш түгел! Кирлемар тау астындагы Әшәлче авылыннан чыккан төбәк тарихчылары Д.Таҗиев һәм З.Шәрәпова-Ханова бу теманы шактый өйрәнде. Алар Кирлемар сөргенендә булганнарның нәсел дәвамчылары белән аралашу һәм шул мәгълүматларга таянып, Татарстан милли архивында эзләнүләр үткәрде. Шуңа нигезләп, Д.Таҗиев архивта 13 «Эш» (»Дело») белән танышкан, алар ФР-2757 фондының 3 тасвирламасында тупланган, автор Әшәлче китабында аларны биргән. Әмма бу китапта иң тетрәндергәне – Кирлемар сөргене турында җан өшеткеч хәтирәләр, истәлекләр.

«...Әле аннан да куркынычы була бу төбәкләрдә. Әшәлче авылы янындагы тауга куа торган булганнар сөргенгә озатыр алдыннан сәяси тоткыннарны. 30-35 градуслы эсседә бер тамчы суга тилмереп, янып үлә кайбер бәхетсезләре. Тау астыннан чишмә ага, ә монда тәмуг. Бу газапларга чыдый алмый акылдан язучылар да була. Тугызынчы дистәне тутырып килгән Саҗидә апа сөйли. Югары Кәминкәдән Миңнеәхмәт дигән сукыр карт кереп йөргән аларга. Кияве белән кызын, улларын да уяттырмыйча, җәһәннәм тавына алып киткәннәр. Шул китүдән ник бер хәбәр булсын...»

Бу – Мөхлисә Нәгыймованың 1998 елның 9 июлендә «Әлмәт таңнары» газетасында чыккан язмасы. Китаптагы искәрмәдән күренгәнчә, Югары Кәминкә мәчете азанчысы Гыйләҗ хәзрәт Мөхетдиновны һәм хатыны Закирә абыстайны, авыл советы рәисенең йортын яндыруда гаепләп, кулга алалар. Аларны башта Кирлемар тавында тоталар, аннан хәзрәткә - 10, абыстайга 5 ел төрмә бирәләр. Хәзрәт 1934 елны азат ителгән, әмма 1937 елда аларның икесен дә дингә өндиләр, колхозга каршы эшлиләр, дип тагын кулга алалар һәм Бөгелмә шәһәрендә атып үтерәләр...

Менә Иске Кади авылы мулласы Сәрвәретдин хәзрәт Хәйретдиновның кызы Мәүфәкә апа истәлекләре, ул 11-12 яшендә Кирлемар сөргенендә була. Әтисен 1931 елда, Коръән укып утырган җиреннән кулга алалар, хатыны Җүвәйрә абыстайны, биш баласы белән, гыйнварның чатнама суык көнендә, атларга төяп, сак астында Кирлемар тавына китереп ташлыйлар. Монда сөрелгән Чәтрән мулласына авылдашлары мунча кебек кенә куыш салып бирә, алар киткәч, Сәрвәр мулла балалары шул куышка керә, шулай итеп, катып үлүдән сакланып калалар.

«Шунда ике еллап яшәдек, – дип яза Мәүфәкә апа. – Ир туганнарым бу вәхшилектән Кытай янындагы Чита якларына качып китте. Бөтен булган нәрсәләребезне ризыкка алыштырып бетердек. Әнием соңгы истәлеген, ире хаҗдан алып кайткан муенсасын, икмәккә алыштырды... Күрше авыллардагы татарлар булышмаса, без монда үлгән булыр идек». (Күрсәтелгән хезмәт, 194 б.)

Мәүфәкә апаның истәлекләреннән күренгәнчә, ул әле этен ияртеп, Кармыш авылына укырга да йөргән, димәк, үлемгә хөкем ителгән балаларга белем алырга рөхсәт ителгән? Ул Кирлемарда бүреләрнең күп булуын, әмма аларның кешеләргә тимәүләрен яза, бу бәхетсезләргә ерткыч хайваннар да кагылмаган... Ә Мәүфикәнең атасы Сәрвәретдин мулланы, төрмәдән кайткач, 1937 елда тагын кулга алалар һәм Мәләкәс шәһәрендә атып үтерәләр...

Менә тагын бер хәтирә, монысы инде сөргенгә сөрелгәннәрнеке түгел, ә аларга ярдәм итүчеләрнеке. «Таҗиев Әбелкасыйм бабайның хатыны Мәгъбүлә әби сөйләгәннәрдән (оныгы Фирдәвес Мөхәррәм кызы хатыныннан өзек): «Репрессия елларында халыктан бар булган байлыкларын талап, Яшәүче (Әшәлче) поселогына Кирлемар тау башына төрле авыллардан сөрелгән муллаларны, хәллерәк кешеләрне «кулак» дип китерделәр. Ачлар, тау өстендә җил, салкын. Балалар елый. Шушы «лишуннар» янына төнлә бара идем. Итәк астында ипи, сөт. Кулдан килгән кадәр бөтен авыл халкы ярдәм иттек», – дип тәмамлаган ул хатын.» (З.Шәрәпова-Ханова. Авылым йортлары – тарихым капкалары. – Казан, 2020, 26 б.)

Бу бичара мәхбүсләрне туган авылларыннан талый-талый куучылары да татарлар була, үз гомерләрен куркыныч астына куеп, аларны ач үлемнән саклап калучылар да – үз халкыбыз. Әшәлче-Кармыш халкы, төннәрен Кирлемарга кача-поса менеп, тоткыннар өчен землянкалар казый, аларга яшәр өчен келәт-мунчаларын күчереп сала, төннәрен хәтта кайбер кешеләрне, карт муллаларны, чанага салып урлау очраклары да булган. Болар хакында безгә Кармыш авылында яшәүче 87 яшьлек Хәтимә апа Шәйдуллина һәм 83 яшьлек Өммегөлсем апа Вафина да сөйләде, аларга исә ата-аналары, әби-бабалары сөйләп калдырган. Әле моннан 10-15 ел элек Кирлемарга сөрелгәннәрнең балалары исән булган, алар бу каһәрле урынга килеп, елый-елый догалар кылып киткән...

«Мин 2007 елда Кирлемар тавы белән тагын бер кат очраштым, - дип яза ул чагында инде 87 яшьтә булган Мәүфәкә апа, Сәрвәретдин мулла кызы. – Монысы инде соңгы тапкыр. Ярты гасыр вакыт узса да, хәтердән бер нәрсә дә сызылмаган, йөрәк яралары да төзәлмәгән. Бер кат авылларыннан куылып, Кирлемар тавында мунча-өйләр ясап урнашкан кешеләрне, икенче тапкыр таш казаннары буйлап яңадан сөргеннәргә алып киттеләр. Барысы да күз алдында. Монда хәзер ул вакыйгаларның эзе дә калмаган. Бирегә Истәлек билгесе куйсагыз иде. (2009 ел.)»

Ул вакытлардан соң, Кирлемар тавы да, Әшәлче үзе дә нык үзгәргән инде. Мин бирегә шау чәчәкле болынлыктагы Әшәлчене эзләп килгән идем, әмма тирә-юне актарылып ташланган, болын-әрәмәләрне телеп, юан-юан торбалар сузылган ятим, бәхетсез җирләрне генә күрдем. Авылның бер башыннан кытай юлы үтә, монда бөтен җир казылган, чокыр-чакыр, икенче урында «Әшәлче битум заводы» эшләп ята, кырларда скважиналар көне-төне җирнең җелеген суыра... Юк инде ул элеккеге матурлык, элеккеге Әшәлче, алыплар аяк баскан, таш казаннар аскан серле җир юк инде ул... Аны башта төрмәгә әйләндергәннәр, аннан малын талаганнар, авылның, табигатьнең хәзергә чыкмаган җаны гына калган. Үз башыбызга ашыга-ашыга салган юллардан чин-мачин килеп утырса, анысы да калмаска мөмкин...

Без бик борынгы тарихи җирләрдә яшибез, әмма аңа хуҗа түгел, без тарихның өстеннән таптап, изеп йөрибез, әмма аның кадерен белмибез. Без гыйбрәт тә ала белмибез, нәтиҗә дә ясамыйбыз, җәннәттәй җирләребезне, карап торып, җәһәннәмгә әйләндерергә юл куябыз. Без алыплардан – алыпсатарларга әйләнгән, халыктан сарыкка әверелгән кавемме соң әллә? Нигә безнең бөек тарихыбыз өстенә концлагерьлар төзиләр, авылларыбызның җелеген суыралар?!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

ТЕЛӘКӘЙ ЧИШМӘСЕ

(Дәвамы. Башы 42, 43 нче саннарда).

Югыйсә, әле кичә генә патша булып торган Федорны мәңгелек дөньяга да озатмаганнар, атакайлар олы соборларда аның белән хушлашу мәрәсиме дә уздырмаган бит. Федорның җәсәде, әнә, Архангел соборында хушлашу һәм данлау сүзләрен көтеп ята. Аны җирләүне үткәргәч, боярлар думасын җыеп киңәшсәләр һәм шуннан соң гына кайсы энекәшенең тәхеткә менәчәге турында игълан итсәләр дә ярар иде әле. Юк шул, дилбегә кулдан ычкына, дип ашыкканнар, ахры...

Билгеле ки, моны Федорның анасы Мария ягыннан туганнары – бояр Милославскийлар да белеп алган. Араларында иң елгыры – Софья. Шул кичтә үк сөяркәсе Василий Голицынның приказ йортына барып җиткән бит бу. Ә наз күрмичә интеккән сазаган кыз җырны матур суза.

– Энекәшем Иванга уналты яшь тулды, собор кануннары буенча тәхеткә, иң беренче чиратта, тик ул гына дәгъва итә ала. Ләкин, әнә, Иоаким атакай хәерче Нарышкиннар кубызына тотып биегән бит. Нәселе затсыз Наталия шәпле котырткандыр, әле тау кадәрле алтын-көмеш белән күмәргә вәгъдә итеп, Иоакимны үз ягына аударган булуы да мөмкин. Иоаким чиркәүдә тәхеткә тәне туктаусыз тартыша торган тилемсә Петрны утыртып куячагы турында вәгъдә биргән. Атаем Алексей утыз өч ел элек булдырган Собор уложениесен аяк астына салып таптаганнар. Чиркәү кануннарын оятсыз рәвештә бозу бара. Тәхеткә иң беренче чиратта хокуклы Иван энекәшне якларга, хәерче Нарышкиннар нәселен Кремльдән куып чыгарырга кирәк, йә нишлибез, Василий бәгырькәем?

Василий Голицын – җиһанга фәкать җилбәзәк хатын-кызларның башын әйләндерү, аларны үз кубызына биетү өчен генә яратылган чибәрләрдән-чибәр ир үрнәге. Түшәктә бик кыю һәм чамасыз назлы булса да, үзбаш гамәлләр кылудан качып кала белә. Бу юлы да патша кызы Софья сазаганга җаваплары урап кына дәште.

– Сиңа да, миңа да яшен төсле ялтырап йөрүдән качып кала белү, ә утлы күмерне чит-ят куллар белән тоту отышлырак. Ходайныкын ахыргача алдан белеп булмый, аның исә синең үзеңә дә тәхеткә юлны ачып куюы бар. Алай-болай булып, Иван энекәшең белән Петр шалапут та дөньядан китеп барса, шәхсән синең үзеңә дә патшабикә камыты насыйп булмагае.

Софья читән өстенә сикереп менгән этәч шикелле бер кагынып алды.

– Авызыңа бал да май, Василий бәгырькәем. Андый бәхет миңа килеп җитсә, син дә патша тәхетенә менеп утырачаксың. Әмма аңа чаклы, колга Петрны әйләндереп ату өчен, ни генә уйлап табыйк?

Василий да Софья сүзләреннән соң бер карышка үскән иде инде, тәрәзә яктысына борылып ысылдады.

– Чит-ят куллар кирәк, дидем, чит-ят куллар. Мин приказ сараена стрелецларның баш полк командиры кенәз Хованскийны чакыртып китертә алам. Чуртан сыман үтә шома һәм туймас тамак булса да, аның стрелецлар каршында абруе зур. Чөнки стрелецларга үз утарында казынырга, яңа йорт салырга яки базарда сату итәргә кирәкме, һәммәсе дә Иван Андреевич каршына килеп тезләнә, аннан рөхсәт ала. Яу походына кузгалсак та шулай. Баш бирмәгән, бил бөкмәгән ирләрне дошман белән бәрелешкә кергәч, үлем белән йөзгә-йөз киләчәк алгы сафка билгели, үзенә баш игәннәрне обозда яшереп калдыра. Аңлашыла инде, тегеләр Хованскийның үзенә дә рәхмәт сүзләрен капчык-капчык яки мичкә тулы байлык белән кайтара. Дошманнан талап алган ганимәт (трофей) турында инде әйткән дә юк.

Софья иләмсез зур күкрәкләрен кашыйкашый кыбырсый башлады, моны шәйләп, Василий да дилбегәне тизрәк тарткалады.

– Мин Хованскийны приказ йортына чакыртып китертәм, ә син япа-ялгыз калгач, аны нык игәүлә. Дөрес аңла, бәгърем, икебезнең бер сүздә булганны хәтта Хованскийга да сиздермәскә кирәк, шуңа мин күренмим. Ә син аңа нәкъ миңа әйткән шикелле үк аңлат. Петр тәхеткә абыйсы Иванны узып утырырга тырыша, ә канун буенча Иван тиеш, диген. Егерме стрелец полк командирларының егермесен дә үгетләү һич мәҗбүри түгел. Үгез айкап ташлаган салам кибәне шикелле генә әйләндереп атты. Шылт иткән аваз да чыкмаган иде кебек, менә шул чагында бояр Милославский белән аның туганы, яшүсмер Толстой укчылар бистәсе буенча ат өстеннән сөрән салып узды.

– Нарышкиннар тәхеткә утырырга тиешле кануни патша Иванны буып үтергәннәр!

– Нарышкиннар патша улы Иванны юк иткән!

Җиһанда әле май уртасы гына бит, беркемнең дә беркая да ашыкмаган чагы. Патша сараендагыларны да йокыдан менә шушы сөрән салган шашкын аваз уятты. Яшүсмер Иванның кайсы бүлмәгә кереп йоклавына игътибар итүче дә булмаганга

Вахит ИМАМОВ

● Патшабикә Софья һәм Василий Голицын.

Хованскийга биш-алты полковникны чакыртып сындырса да җитә. Ә ике мең биш йөз яисә өч мең укчы бер йодрык булып тупланса, бу инде Кремльнең астын-өскә әйләндереп атарлык куәт. Әүвәл шул биш полковникны җыеп табада биетсен, аннары тегеләре иплән кенә, чылбыр буенча, астагы йөзбашларга да төгәл җиткерсеннәр. Кремльгә бәреп керә алсак, хәчтерүш Нарышкиннарны аяп йә кызганып маташу – ул хыянәт. Ә тәхет юлыннан Петр хөрәсәнне алып атсак, полковникларның һәркайсын алтын һәм бүләкләр көтә. Менә шулай итеп үгетли белсәң иде, минем тиздән тәхеттә күрәчәк, кадерле патшабикәм!

Бетте, эреде, җебеп акты, Софья инде Голицын кайда күрсәтсә, шул тарафта чишенеп ятарга да әзер иде. Патша кызы укчылар гаскәре бригадирын бармак очларына кадәр үбеп тәкъбарлады:

– Тәхеткә менүгә ирешсәм, Ходаем да, падишаһым да син!

* * *

Фетнә Софья белән Голицын ниятләгәннән дә яман булып купты. Ачыкавыз Нарышкиннар сакны көчәйтү турында уйлап та карамаган, һавадагы бәхет кошын тулысынча үз кулыбызга эләктердек, хәзер аны ничек кирәк, шулай биетәбез, дип җиде болытлар өстенә очып менгән, ахры. Ә укчыларның өч меңлек нөгәре Кремль капкаларын җимереп яки диварларына үрмәләп тә көч әрәм итмәде, саны белән бер йөзгә дә тулмаган сакчы ирләрне ярсу күрә, Нарышкиннар нәселе дә зур хафага төште. Иң беренче булып, аны эзләп, Кремль баскычына чал сакаллы бояр Артамон Матвеев атылып чыккан иде, аны Бутыр полкы укчылары эләктереп алды да, дивар өстеннән урам якка атты. Ә анда сөңгеләрен урман урынына өскә каратып баскан укчыларның сафы көтеп тора. Күк йөзенә сыңар гына аваз яңгырады:

– Ы-ы-ың!

Теткәләнеп беткән Артамон картның гәүдәсен кирмән алдындагы тирән чокырга болгап ыргыттылар. Ә кан исеннән исергән укчы ирләр, котырган кондыз урынына, яңа корбан эзләп, Кремль эчендәге сарайлар эченә атылды. Әллә каян гына баскычка тагын бер карт кенәз – Михаил Долгоруков атылып чыкты. Үзе туктаусыз кычкыра:

– Сез – җинаятьчеләр, сез – җәлладлар! Алексей Михайлычның улы Иванга сыңар гына кеше дә тырнак очы белән дә кагылмады, ул Петр олан янәшәсендәге бүлмәдә гырлап ята!

Ләкин кан түгүдән котырган укчыларны туктатмалы түгел иде инде. Михаил картны да кул-аякларыннан эләктереп алдылар да, дивар артындагы сөңгеләр өстенә очырып төшерделәр.

Шулчагында Кремль баскычында инде Наталия Кирилловна үзе пәйда булды. Бер кулы белән – Иванны, икенчесе белән Петрны җитәкләгән. Күзләрендә тоташ яшь кенә.

– Нинди Иванга кул сузу, ниткән үтерү турында шәрран ярасыз сез? Менә бит, патша улы Иван да, аның энекәше Петр да бер дәрәҗәдә исән! Нигә нахак бәла ягасыз да, ни хакына мондый канлы фетнә белән үзегезне тапка батырдыгыз?

Көтмәгәндә, кинәт укчыларның йөзбашы Никита чәчрәп чыкты.

– Безгә синең абыең Афанасий Кириллыч белән энекәшең Иван хәбәр җибәрде бит. Димәк, безне кан белән таплау ниятен синең туганнарың корып куйган. Стрелецларны куып тараттыру, үзләре кубызына биюче яңа солдатларга алыштыру өчен түгелме икән? Әйдә, туганнар, шул мәкерле гайбәт иярен эзләп табыйк та, үзләреннән сорыйк...

Котырган укчылар сарай бүлмәләренә кереп тулды. Наталиянең энекәше Иванны патшабикәнең йокы бүлмәсендәге карават астыннан тартып чыгардылар. Аңа да, бер-ике минуттан эзләп табылган Афанасий картка да авыз ачып сүз әйтергә ирек бирмәделәр. Афанасий картны дивар артындагы сөңгеләр өстенә болгап ыргыттылар, бичара Иванны кылычлар белән тураклап үтерделәр. Укчыларның икенче төркемнәре Нарышкиннарга туган тиеш булган бояр Языковны, кенәз Григорий Ромадановскийны, элек стрелецлар приказында башлык булып йөргән Юрий Долгоруковны да эзләп тапты. Бичараларның һәммәсе дә янә сөңгеләр урманы өстенә очып төште.

Патшабикә Наталиянең этисе Кирилл Полуэктович та исән икән әле, ул да иң түрдәге чоланнарның берсендә качып яткан. Бичараның айлар буена кайчы күрмәгән чәчләре пумаланы хәтерләтә, ләкин акшар яккан шикелле чап-чал. Гәүдәсе дә бакчаларга карга кутүен куркытырга куйган карачкы кебек, шыр-сөяктән тора. Аның сыңар чиләк күтәрерлек, үзе белеп тун киярлек егәре дә калмагандыр инде, аз гына төртсәң дә, авып китәр төсле. «Моңа сөяге очы да, кылыч йөзе дә әрәм», дип бөтенләй тимәделәр. Укчыларның гына кайсыдыр сарык йонын кырка торган олы кайчы белән чәч һәм сакалларын кискәләп бетерде. Соңыннан йөзбашы Никита актык сүзен әйтте:

– Белоозерск монастырена озатыгыз моны...

Укчыларның елгыр бер төркеме сарайда лекарь булып йөргән килмешәк немец фон Гаденны да эзләп тапкан. Укчыларны тотып тыешлы түгел, бәйләнер сәбәбен дә уйлап чыгарганнар:

– Федор патша егерме яшендә гүргә кереп ятты, аны менә шушы нимес агулап үтерде бит.

Бу юлы да йөзбашы Никита сүзсез кул селтәде. Немец лекаренең башын кыеп төшерделәр...

Башкалар арасында посып кына йөргән Федор әле патшабикә Наталиянең энекәше Иванны йокы бүлмәсеннән сөйрәп чыгарганда һәм аны кылычлар белән тураклаган чагында ук игътибар иткән иде. Анасының биленә чытырдап ябышкан Петр агарынып каткан. Күзләрендә яшь тамчыларының эзе дә юк. Ләкин ун яшьлек малайның тәне генә түгел, берьяк яңагы да өянәк ябышкан шикелле туктаусыз тартыша, ә ул үзе кулын күтәреп тә шул яңагын ышкып куя йә тынычландыра алмый. Кан күрүдән мондый мескен хәлгә төшкәнме ул, әллә туган агасының һәлакәтен авыр кичерәме? – бәяләрлек түгел. Әле ярый, Ромадановский, Долгоруковларның, шушы ук немец фон Гаденның соңгы минутларын күреп өлгермәде. Кем белә, әгәр шаһит булса, бөтенләй һушын югалтып егылуы, йә тартыша-тартыша үзенең дә китеп баруы бар бит...

(Ахыры киләсе санда)

ГАРИПОВ РАВИЛ ЗАКИР УЛЫ

Гарипов Равил Закир улы 1926 елда Арча районының Кышкар (Наласа) авылында туа һәм шул ук район комиссариматы аша 1942 елның 10 декабрендә сугышка озатыла. 1944 елның 15 февраленнан соң Көнбатыш һәм 2 нче Белоруссия фронтларында, 40 нчы армиянең 238 нче укчы дивизиясендәге 837 нче полк составында пулемет расчеты командиры булып яу йөри, бер тапкыр яралана, Кызыл Йолдыз һәм 3 нче дәрәҗә Дан орденнарына лаек була.

1945 елның 6-10 март көннәрендә Шварцвассер елгасын кичү һәм Кархауз каласын штурмлау барышында ул дошманның 2 пулемет ноктасын һәм 63 солдатын юк итә. 25 мартта Гданьск каласын азат иткәндә янә гитлерчыларның 4 пулеметын һәм 19 сугышчысын сафтан чыгара. 27-28 март көннәрендә Висла елгасын кичкәндә үз расчеты белән беренче булып каршы як ярга кичеп берегә һәм анда тагын дошманның 4 ут ноктасын һәм 4 немец мәргәнен юк итә.

30 мартта гитлерчыларның контрһөҗүмнәренә каршы торган чакта Гарипов расчетындагы барча сугышчылар да сафтан чыга. Ул үзе контузияләр алган булса да гитлерчыларның 2 фауст-патрончысын, 3 мәргәнен һәм 13 солдатын юк итүгә ирешә. Икенче көнне 4 фашист солдатын һәм бер зениткаsuccessfully кулга төшерә, Балтыйк диңгезенә кадәр юл арчуда катнаша.

1945 елның 7 апрелендә Р.Гарипов Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә һәм, гадәттәгечә, татар каһарманы “Кызыл Байрак” ордены гына тотып кала.







Даннан мәхрүм татарлар

ГАЛӘМИЕВ БИКМӘТ

Галәмиев Бикмәт 1915 елда Питрәч районының Татар Кодашы авылында туган, шул ук район комиссариаты тарафыннан 1939 елда Кызыл Армия сафларына чакырылган. Ул совет-фин сугышында катнаша, ике мәртәбә яралана. Баш командование резервындагы 18 нче инженер-саперларның штурм бригадасының 86 нчы батальонында отделение командиры, сержант булып хезмәт итә.

1943 елның октябрендә Днепр елгасын кичкәндә үз отделениесе белән дошманның тоташ утка тотуына карамастан өч тәүлек эчендә күпер төзеп куеп танылa. Ике сугышчысы авыр яраланып суга бата башлагач, аларны коткарырга ташлана һәм үзе үк беренче медицина ярдәмен дә күрсәтә. 15 октябрьдә гитлерчылар туктаусыз бомбага тотып күперне өлешчә җимерүгә ирешсә дә, Галәмиев янә беренчеләрдән булып күперне сафка бастыру өчен көрәшә. Бомба кыйпылчыгы тиеп яраланса да, күперне төзәтү эшләрен ташлап китми, яңадан-яңа бүрәнәләр өстәп, аны сафка бастырырга өлгерә. Шул күперне көтеп, совет гаскәрләре ягында яр буена дистәләгән сугыш кирәк-ярагы төягән машина һәм җигүле атлар тезелә, аларны немец самолетлары бомбага тоту куркынычы ук совет сугышчыларын бертуктамый эшләргә мәҗбүр итә. Чираттагы бер дошман бомбасы бүрәнәләр бәйләнгән салны җимереп ташласа да, яралы Галәмиев тагын елга суына ташлана һәм бүрәнәләрне күпер төзүдә файдаланырга ярдәм итә.

1943 елның 22 октябрендә Галәмиев әле бу яңа күперне дошман үз кулына эләктерү хәвефеннән саклау өчен аның субайлары астына миналар куеп чыгуда да катнаша, шушы бурычны да үтәгәннән соң гына үзен госпитальгә озатырга ризалыгын бирә. 1943 елның 1 ноябрендә аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп документларын югарыга озаталар. Татар егетенең фидаи каһарманлыгы өстәге түрәләр тарафыннан Кызыл Байрак ордены белән генә бәяләнә.





(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» чeлтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.



Иң талантлы татар рәссамнарыбызның берсе – Радик Вакыйф улы Минһаҗев 1963 елның 4 июнендә Әлки районының Карамалы авылында туган. Сигез сыйныф укыгач ул Казан сынлы сәнгать училищесына имтиханнар тоткан һәм шушы уку йортын 1982 елны уңышлы тәмамлаган.

ТАЛАНТЫ

Армия хезмәтен үткәч, ике елдан соң, белем алуын дәвам итеп, Харьков сынлы сәнгать-сәнәгать институтына укырга керүгән. Әлеге югары уку йортын да 1990 елда бик уңышлы тәмамлаган. Оста 1990 елда – Россия, 2001 елда Татарстан Рәссамнар берлегенә кабул ителгән. Ул 1990 елдан алып Чистайда яши. Бу кала инде аның күңеленә бик якын һәм аның күп киндерләрендә дә тасвирланган.

«Сез ни өчендер башкалар кебек Ленинградтагы яисә Мәскәүдәге югары уку йортын сайламыйча, Харьковка киткәнсез. Бу карарыгыз ничек кабул ителде?» – дим рәссамга. «Очраклы рәвештә генә. Кулыма бер журнал алып, укый башлаган идем һәм анда Харьков сынлы сәнгать-сәнәгать институты хакында язылган иде...» – дип җавап бирде әңгәмәдәшем. Укуны тәмамлагач, ул «Восток» Чистай сәгать заводында сәгатьләрнең тышкы бизәлеше өчен җаваплы рәссам-конструктор булып хезмәт куйган, аннары инде шәһәрнең архитектура бүлегендә эшләгән. Һәм шулай ук житди иҗатта булган.

Ул бар төр жанрларны да үз итә. Аның чиксез куәтле таланты, реализм мәктәбенә нигезләнгән белемнәре пейзажлар, сюжетлы тематик картиналар, натюрмортлар, портретлар, интерьер белән бәйле иҗат эшләрен иҗат итүгә юнәлдерелгән. Аның һәр хезмәте хакында шедевр дип әйтү – арттырылган бәяләмә бирү түгел. Чөнки рәссамыбызның шәхси күргәзмәләрен оештыручылар кайчак яңа күргәзмә өчен аның кайсы әсәрләрен генә сайлап алырга да белмиләр, чөнки һәммәсе дә искиткеч матурлар, зәвыклылар! Әсәрләренең һәрберсе өчен төрле материаллар сайланган, майлы буяулар, пастель, каләм яисә акварель буяулар – барысы да кулланылган, шунлыктан да әлеге күргәзмәләр сәнгать сөярләр өчен гаять дәрәҗәдә кызыклы булып килеп чыгалар.

Оста 1991 елдан алып республика күләм, илкүләм күмәк күргәзмәләрдә катнаша, аның әсәрләре – «Зур Идел» төбәкара күргәзмәләр күрке дә. Аның үз шәхси күргәзмәләре дә һәрчак зур уңыш белән үтә. Ә иң беренче шәхси күргәзмәсен сәләт иясе 1991 елда Чистайның Өяз шәһәре музеенда ачкан һәм ул бик зур уңыш белән узган.

Р.Минһаҗев – бик күп иҗат бәйгеләрендә, шул исәптән «Арт-Сабантуй» бәйгесендә дә җиңеп чыккан шәхесебез. Һәм Радик Вакыйф улы – Татарстанның гына түгел, Россиянең танылган графика сәнгате осталарының берсе. Кайчандыр Татарстан Рәссамнар берлеге тарафыннан әзерләнгән рәсми кәгазьгә күз төшерсәк, аның хакында шушы юлларны да укый алабыз: «Радик Минһаҗев – ул дөньяви сәнгатьтәге гуманитар традицияләрнең һәм Татарстан Республикасы халыклары сынлы сәнгатендәге милли үзенчәлекләрнең талантлы мирасчысы. Аның иҗаты җәмгыятебезне эстетик һәм рухи яктан баета бара, җәмгыятьтәге инсаннарны мәдәни һәм әхлакый яктан тәрбияләргә булышлык итә...» Бу – бары рәсми җөмләләр, әлбәттә, әмма алар да шушы өлкәдәге иҗатташларының талант иясенең ихлас иҗатын бик югары бәяләүләренә бер раслама.

Аның бар сәнгать сөючеләрне, сәнгать белгечләрен шатландыручы график әсәрләре каләм, күмер, сангина, соус, сепия кулланып башкарыла. Без аларга ис китеп карыйбыз! «Аллаһы Тәгалә бирсә дә бирә икән кешегә сәләт!» – диючеләр күп, әмма, мәгълүм, бу Радик Вакыйф улының үтә тырышлыгын раслаучы әсәрләр дә. Аның портретларында әдәбият, сәнгать әһелләре дә тасвирланган, күпләр рәссамның «Пастернак портреты»на мөкиббән. Бу шәхеснең язмышы Чистай белән бәйле, Б.Пастернак Чистайга 1941 ел көзендә эвакуацияләнә, биредә тәрҗемәләр белән мәшгуль була һәм республикабыздан Мәскәүгә 1943 елны гына әйләнеп кайта. Аның: «Мин Чистайга бик бурычлы. Мин һәрвакыт безнең тын урыннарны, кече калаларны һәм авыл җирләрен башкалаларга караганда күбрәк ярата идем», – дигән фикере китапларга да теркәлгән. Рәссам, әлбәттә, татар әдипләрен дә теләп ясаган, аның тарафыннан Габдулла Тукай, Нәби Дәүли һ.б.ның портретлары да иҗат ителгән.

Болардан кала аның үз дуслары, якын туганнары, таныш-белешләре сурәтләре дә бихисап. Арада татар милли киемле хатын-кыз сурәтләре дә җитешле. Аларга карап, без милләт рухын барлыйбыз.

Радик Вакыйф улы портретлардагы һәркемнең күңел халәтен тирәнтен итеп ачып биргән. График портретларындагы образлар кирәгеннән артык матур итеп ясалмаган һәм алар шушы үзенчәлекләре буенча гына да тамашачылар күңелен яулыйлар. Рәссам модельләрне идеальләштерү белән мавыкмый. Гомумән, идеальләштереп ясауның ни хаҗәте бар, кешеләр

ЧИКСЕЗ

үз буй-сыннарыннан, йөз-кыяфәтләреннән риза булырга тиешләр. Коръәннең «Әт-Тин» сүрәсендәге 4 нче аятенә күз салсак, анда: «Без кешене иң яхшы кыяфәттә яраттык» дип аңлатылган. Әйе, гадәттә, кайбер осталар тамашачыларны кирәгеннән артык купшылык кушып ясалган портретларын күрсәтеп кенә дә чикли. Ә менә бу, индивидуаль ясау манерасына ия булган рәссамыбыз исә кешеләрнең гадәти тормыштагы төгәл кыяфәтләрен чагылдырыруга йөз тота. «Мин, – диде әңгәмәдәшем, – әтием кебек чын хезмәттә булып, йөзләре кояшта кызарган, кичерешләре битләренә җыерчыклар булып таралган яки җөй эзләре (шрамнар) үк калган инсаннарны ясауга өстенлек бирәм. Мондый образларны иҗат итү җиңел. Ә менә безгә ялтыравык матбугат битләреннән пропагандаланучы стандарт матурлык артыннан чабучы шома йөзлеләрне ясау – авыр. Минем, әлбәттә, андый эшләрем юк».

Аның киндерләрендә без төрле һөнәрдәге хезмәтсөярләрне дә, Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарманнарны, дөньяны кабул итә генә башлаган кечкенә балаларны да, берникадәр уйчан яшүсмерләрне дә барлыйбыз. Радик Вакыйф улы иҗат иткән хатын-кыз образлары да күңелләребезне яулый. Ул татар хатын-кызларына хас булган мөләемлек, тыйнаклык, рухи матурлык сыйфатлары балкышын искиткеч осталык белән тасвирлый һәм бу биниһая соклануларга лаек! Рәссам зирәк үтә күрүчәнлеккә ия. Ул шулай ук авыл җирлегендә яшәп, гади тормыш алып баручы, авыр физик хезмәттән курыкмыйча, үз тырышлыклары белән аерылып торучы, ару-талу белмәс татар ир-атларын да шулкадәр дәрәҗәдә яхшы итеп сурәтли килә.

Әйе, төгәл портретларны һәркем ошата, рәхмәт урынына инде тәмамланган сурәт белән килешмичә, зарланып, шыңшып торучылар бер рәссамга да кирәкми. Әйтик, хәтта мәшһүр И.Левитан да бервакыт ни өчендер: «Минем салам өемен ясыйсым килә, аның сөякләре дә, анатомиясе дә юк», – дигән бит... Портретлар ясау, билгеле, классик сынлы сәнгатьтәге күп белемгә ия булу, үз профессияңне яхшы белү, күп энергия сарыф итү белән бәйле.

Моннан кала Радик Вакыйф улы иҗатына караучы балалар портретларындагы образлар да үз нәфисләкләре, эмоциональлекләре, йөз балкышлары һәм рухи чисталыклары белән күңелләрне җәлеп итә, истә кала. Һәм без әлеге әсәрләрдә балаларның тышкы кыяфәтләрендәге һәм холыкларындагы бар нюанс-нечкәлекләрнең исәпкә алынуын күрәбез. Балалар һәр гасырда да сөйкемлеләр, әмма аларны һәр рәссам үзенчә тасвирлый, Радик Минһаҗев әсәрләрендәге бала сурәтләре күңелләрне эретә. Алар искиткеч ясау техникасы аша, колористика белән бәйле гаҗәеп осталык аша ясалган!

Аның киндерләрендәге Казан, Әлки, Әлмәт, Чистай, Кырым табигатьләре һәм шушы якларга гына хас борынгы архитектура өлгеләре дә озакка истә калырлык итеп язылган.

Виртуоз рәссамның киңкырлы иҗатындагы акварель буяулар белән ясалган натюрмортларын, абстракция юнәлешендәге үзенчәлекле хезмәтләрен дә игътибардан читтә калдырып булмый. Татар җирлегендә абстракция жанрындагы әсәрләрне шулкадәр дә оста итеп ясаучылар күп түгел.

2015 елда әлеге мөхтәрәм затка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде. Билгеле, Радик Минһаҗев әсәрләре дәүләт музейларында, кайбер калаларның картина галереяларында, шәхси тупланмаларда кадерләп саклана. Әлбәттә, мин талант иясенә аның иҗаты белән чын күңелдән соклануымны белдердем. Ә Радик Вакыйф улы болай да диде: «Минем картиналарым, графика юнәлешендәге хезмәтләрем бик күп. Шуңа да карамастан мин, иҗатчы буларак, һәр көн рәсем ясауда. Кайчак башыма «мин аз иҗат иттем» дигән уйлар да килә.

Мин тырышам. Һәм алдагы елларда да, Аллаһы Тәгалә насыйп итеп, һәр көн әсәрләр язачагымны күзаллыйм, билгеле. Бу шундый сәнгать инде, фани дөньядагы рәссам аны елдан-ел камилләштерә барырга гына тиеш...»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Габдулла көрәштәш

Габдулла әфәнде 80 нче еллар азагында Чаллы шәһәрендә Татар иҗтимагый үзәген (хәзер РФ территориясендә тыелган оешма) оештыручыларның берсе иде һәм күп еллар аның идарә әгъзасы булып торды. Хатыны Ләлә ханым безгә Габдулла әфәнде белән бергә узган тормыш юлын сөйләде.

– Ләлә ханым, сез Әлки ягыннан, Габдулла әфәнде – Елховойдан. Габдулла абыйлар гаиләсенең тормыш юлы ничек булган?

– Габдулла Елховойда туган гына. Ул озак еллар, 3 яшьтән 22 яшькә кадәр, Себердәге Новый Бор поселогында яшәгән. Аларның гаиләсендә 3 бала туган. Кайнатам бик сәләтле балта остасы булган, агач эшен яхшы белгән. Акча эшләү нияте белән, гаиләсен калдырып, төрле якларга эшкә барып йөргән.

Тормыш иптәшемнең әнисе дә гади кеше, укый-яза белмәсә дә, бик акыллы хатын-кыз иде. Шахмат та уйнады, бәйләргә яратты, үзе бик тәмле пешерә иде, гөлчәчәкләр үстерде, сәүдә эшләре белән дә шөгыльләнде, кыскасы, бик уңган, актив әни булды. Гарәпчәне өйрәнергә алынды, әмма, кызганыч, җитешә алмады, дөнья куйды.

Әтиләре сугышка киткәч, әнисе 3 бала белән берүзе кала. Авылда аларны Себергә эшкә китәргә кодалап йөргәннәр. Әнисе бер таныш хатын-кыз һәм 3 баласы – Әгъләм, Зәйнәп, Габдулла белән Себергә чыгып киткән. Алар анда баракта яши башлаганнар.

Әтисе әсирлектә булу сәбәпле, сугыштан соң Украинадан кайта алмый. Аның янына, 3 баласын ияртеп, хатыны килә. Тик Габдулланың әтисе белән әнисе бергә озак яши алмаган. Тормышлары барып чыкмагач, әнисе Габдулла белән Зәйнәпне алып, кире Себергә кайтып киткән, ә олы улы Әгъләмне әтисе янында – Украинада калдырган, шуның өчен Әгъләм абый гомеренең соңгы көннәренә кадәр әнисенә үпкә саклап яшәде... Әтисе исә, туган ягына ялга кайткач, озак уйлап тормаган, башка хатынга өйләнгән дә кабаттан Украинага киткән. Аларның тагын 2 балалары туган.

Габдулла Себердә үсә, Ленинградта кораблар төзү институтын тәмамлый. Укыган вакытта ук кичләрен вагоннар бушатып акча эшли. Сеңлесе Зәйнәп 16 яшьтә үпкә ялкынсынуыннан вафат була. Әнисе бу хәлне авыр кичерә, каты авырып китә, озак дәвалана. Әгъләм абый армиядән соң Себергә – әнисе янына яшәргә килә, аннары эшкә урнаша. Әмма монда ул озак тоткарланмый, кире Украинага китеп, украин кызы белән гаилә кора. Аның әнисе Себердә немец кешесенә кияүгә чыгып, аларның бер уллары Валера туа. Ул 1948 елгы, Петербургта яши. Соңыннан кайнанам Себердән кайтып, Елховой авылында өй алып яши башлый.

– Ә сез Габдулла абый белән кайда очраштыгыз?

– Казан педагогия институтының физика-математика бүлеген тәмамлагач, үземнең туган авылым Чуаш Кичүендә 1 ел математика укыттым. Әтием – укытучы, мәктәп директоры, әнием татар теле укытучысы булып эшләде.

Бервакыт, җәйге печән өсте тәмамланып, печән кибәннәрен өеп бетергәч, Чаллыдагы Роза апамнарга кунакка киттем. 1973 ел иде бу. Апага эш эзлибез. «Камгэсэнергострой»ның мәгълүмат-хисап үзәге коридорында апамны көтеп торам. Ишектән бөдрә чәчле бер яшь егет килеп чыкты. Мине күреп: «Сез эш эзлисезме?» – дип сорады. «Юк, апамны көтәм, отпуска мин, ялга килдем», – дим. Шундук мине очрашуга чакырды. Беренче очрашуыбыз шул кичне булды.

Башта Габдулла белән очрашасым килмәде. Ник дигәндә, Габдулланың буе озын түгел, ә мин озын буйлы егетләрне ошата идем. Шулай булуга да карамастан, аралашып киттек. Бик тыйнак, йомшак тавышлы, акыл иясе икәнен күрдем. Ул да мине сынап, төрле логик сораулар бирде, минем аларны бик тиз һәм җиңел генә чишүемә аптырап та куйды. Аннары, авылга кайтып киткәндә, озатырга килде. Соңрак яныма авылга да кайтып китте.

Август ахырында яңадан Чаллыга килдем, үзем мәгълүмат-хисап үзәгенә барып, программист булып эшкә урнаштым. Габдулла анда баш инженер булып эшли иде. Күбрәк аралашкан саен мин Габдулланың күпкырлы, талантлы, бик тә укымышлы, зыялы, зирәк акыллы кеше икәненә төшендем. Ул юмартлыгы, кешеләргә карата миһербанлылыгы, башка бик күп матур сыйфатлары белән аерылып торды. Инде Габдулланың буена бөтенләй игътибар итми башладым, чөнки аңа гашыйк булган идем. Ул минем өчен дөньяда иң яхшы кешегә әйләнде. Габдуллага кияүгә чыктым һәм беркайчан моның өчен үкенгәнем булмады.

Габдулланың мәгълүмат-хисап үзәгендә баш инженер булып китүенең үз тарихы бар. Вазыйфасына җавапсыз караганга, баш инженерны эшеннән азат итәләр. Шулчак Габдулла торып баса да бу вазыйфага үзен тәкъдим итә. Араларындагы бер ханым Габдулла турында мондыйрак сүз әйткән: «Гомеремдә беренче тапкыр үзе әйткәнен үтәгән кешене күрәм», – дигән. Шулай итеп, ул баш инженер булып китте.

Оешманың җитәкчесе булып Сергей Павлов исемле кеше торды. Ул Мәскәүдән 3 елга килгән иде. Ул киткәч, Габдулланы мәгълүмат-хисап үзәге башлыгы итеп билгелиләр. Ирем төпле, акыллы булганга, эшендә һәрвакыт канәгать булдылар. Аны бик хөрмәт итәләр иде. Үз вазифасын бик яхшы башкара иде ул. Аннары «КамГЭС»ка баш инженер урынбасары итеп алдылар, 1981 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләделәр. Соңрак аңа Сириягә, Табка шәһәрендә Евфрат елгасына плотина төзү эшенә барырга тәкъдим иттеләр. Балабызга ул вакытта 1 яшь тә 3 ай гына иде әле.

Беренче тапкыр «Боинг» самолётында Сирия башкаласы Дамаскка очтык. Анда 1 кич кундык. Март ае булуга карамастан, бик җылы иде. Кызымның өстендәге комбинезонын салдырып, җәйге күлмәк кигезергә туры килде. Иртә белән безне азан тавышы уятты. Бераздан безне алырга килгән микроавтобуска утырып, Табка шәһәренә киттек. Кая карама чүл дә чүл. Бер агач та күренми, ичмаса. Авыл урамнарында яланаяк гарәп балалары уйнап йөри. Елап утырам шулай, «кая эләктек» дип. Бер мәскәүле миңа: «Елама, ник елыйсың, син бит әле анда нәрсә икәнен белмисең. Китәсең килмичә еларсың әле», – диде. Чынлап та шулай булды да.

Евфрат елгасында плотинаны СССР төзүчеләре салды бит. Ә без «Перерегулирующая» дигән плотинаны төзедек.

– Аннан ничәнче елны кайттыгыз?

– Анда без 1983 елда бардык һәм 1986 елда кайттык. Ул заманда Сириядә халык бик бай яши иде. Алар бик тату, тыныч, дингә бирелгән, эшчән, кешелекле, ярдәмчел булды. Бүген дә аларны иң җылы хисләр белән искә алам.

– Горбачев чоры, кооперативлар эшли башлаган вакытта кече предприятиегезгә «Йорт» исемен кем сайлады?

– Без аны бергәләшеп эзләдек. «Подворье» да түгел, нәкъ менә «Йорт». Башта Габдулла Зәйдә такта белән эш итү предприятиесе ачты. Аннары Чаллының Үзәк урамында ташландык җирдән 1 бүлмә алды. Ул иске генә бинаның ишекле, ләкин йозакка бикләнми торган бердәнбер бүлмәсе Габдулланың беренче эш кабинеты булды. Бинаны тулысынча төзекләндерде. «Йорт» фирмасы шул нигездә үсте. Бу 1 көндә генә эшләнмәде, әлбәттә, барысын да әкренләп торгызды. Бик авыр иде, бөтен җыелган акча шунда китеп барды. Әлеге фирма агач эшләнмәләре, ишек-тәрәзәләр ясау белән шөгыльләнде. Соңыннан Габдулла үзе бина төзеде, проектларын ясап, көне-төне хезмәт куйды. Батыр йөрәкле, эшчән, түзем, бик акыллы һәм зирәк булганга күрә авырлыкларны җиңеп чыкты.

Әтисе Елховой авылында башка хатын белән тора иде. Габдулла аларның 2 баласына да техникумга керергә булышты, имтиханнарын бирергә дә ярдәм итте. Аннары икесен дә эшкә алды, сеңлесенә квартира алышты, энесенә дә, абыйсына да йортлар салышты. Әгъләм абыйга гомер буе ярдәме тиде. Шулай бөтен туганнарына, әтисенә дә ярдәм итеп яшәде, үзен бурычлы итеп хис итә иде. Соңыннан ярдәменең рәхмәтсез икәнен аңласа да, ул, барыбер, ярдәм иткәненә үкенмәде.

Минем әти-әнигә һәр атнаны азык-төлек алып бара идек. Әтием үлгәч, әнием инде менә 11 елдан артык бездә яши. Габдулла, чит илгә барса, әнине хөрмәтләп, бүләкләр алып кайта, тәмле ризык булса, әнине чакырып, беренче аңардан авыз иттерә иде. Әнигә быел, Аллаһы боерса, 100 яшь тула. Намаз укыган саен Габдулланы искә алып, рәхмәтләр әйтеп, аңа дога кыла.

– Яшьтән үк чит җирләрдә яшәгәч, Габдулла әфәндегә ана телебездә сөйләшү авыр булгандыр?

– Себергә сөрелгән кешеләр бик укымышлы, акыллы, уңган булганнар. Габдулла шулар белән аралашып яши, һәм аннары гомере буе үзенең лаеклы татар икәнен яхшы белде. Ул бит – тырышлыгы белән барысына да үзе ирешкән кеше. Аны берәү дә этеп-тартып йөрмәде. Мәктәпне бетергәч үк институтка укырга керми әле ул. Башта Казанга бара. Элемтә техникумына укырга керә, тулай торакта яши башлый. Анда беркемнең дә татарча сөйләшмәүләре турында әйтә. «Бу дөрес түгел, гадел түгел», – дип кабатлый. Бу сүз хакимияткә каршы сөйләгән кебегрәк килеп чыга. Ул елларда тәнкыйть белән караган кешеләрне яратмыйлар иде бит. Габдулла техникумны тәмамлый алмый. Үз юлын монда тапмаячагын аңлый. Гаделсезлеккә дә ачына. Аннары кире Себергә, әнисе янына китә.

ядкәре

Шул вакытта 18-19 яшьлек Габдулланы йортлар сала торган агач осталары төркемнең бригадиры итеп сайлыйлар. Төрле җирдә эшләп, әнисенә булышып, институтта укып, көн күрер өчен акча туплый...

Габдулла шигырь, мәкаләләрен рус телендә яза иде, митингларда русча чыгыш ясады. Бөтен күңеле, җаны белән татар милләте, татар теленең юкка чыгып баруы өчен борчылды. Ул бит 38 яшендә генә татар телен өйрәнә башлады. Шулай соң тотынганы өчен үкенә иде. Һәр татар кешесе үз телен белергә тиеш, дип санады, шуны таләп итте. Кызы белән оныгының татарча өйрәнүенә һәм татарча сөйләшүенә бик сөенде.

Габдулла дөнья һәм татар тарихы белән тирәнтен кызыксынды. Аның турында, авыз тутырып, бу өлкәдә зур белгеч, дип әйтергә була. География фәнен бик яхшы белә иде. Сәяхәт итәргә яратты. Ленинградта кораблар төзү институтына да сәяхәт итү теләге белән укырга керә ул. Аннары Ленинградта инженер булып эшли һәм, соңрак, Әлмәттә техникумда укыта. Шуннан соң перевод белән Чаллы шәһәрендәге «Камгэсэнергострой»ның мәгълүмат-хисап үзәгенә инженер булып урнаша.

Габдулладагы татарлык хисен Себердә яшәүче татарларга карата булган тискәре мөнәсәбәт уяткандыр, дип уйлыйм. Ләкин милли тойгы аның канында да булган, әлбәттә. Себердә кичергән авыр тормышлары турында Габдулла беркайчан да ачылып сөйләмәде. Кызыбыз Алия, әтисе вафатыннан соң, 2022 елның июль аенда Новый Бор поселогына барып, әтисен белгән кешеләр белән аралашып кайтты. Ул йөргән сукмаклардан йөреп, ул балык тоткан елгадан балык тотып, әтисе ауга йөргән урманнарга барып кайтты (гаиләбездә Габдулланың мылтык асып ауга барган фотосы да бар). Алия үзе белән алып кайткан туфракны әтисенең каберенә салдык.

Тагын бер истәлек. Әнисе, 3 баланы ашатыр өчен, көне-төне фермада эшләгән. Габдулла кечкенәдән ярдәмчел бала булган. Үзенә ашарга дип бирелгән ризыкны әнисенә, туганнарына алып кайта торган булган. Әниләре фермада яңа туган бозауларны караган, балаларына сөт аерткычтан чыккан сөтне алып кайтып эчергән, аларга ачтан үләргә бирмәгән. Күп вакыт туйганчы ашарлык ризыклары булмаган.

Әйткәнемчә, Габдуллаларның Себердәге тормышлары бик авыр барган. Башта 1 баракта 2 гаилә бергә яшәгән. Чаршау белән бүленгән бүлмәнең бер ягында, салам түшәлгән агач сәкедә йоклаганнар. Бераздан аларга аерым бүлмә биргәннәр. Апасы Зәйнәп үлгәч, әнисе бик каты авырып киткән, Габдуллага кечкенә энесе Валераны да карарга туры килгән. Аны ашату-эчертү, киендерү һ.б. эшләр Габдулла җилкәсенә төшкән.

Ленинградта укыганда Габдуллага әнисе акчалата ярдәм итә алмаган. Шуңа күрә аңа көндезен укырга, ә кичләрен эшләргә туры килгән. Шулай 6 ел вакыты узган.

Габдулла үзенең татар булуы белән горурланды. Әле кечкенә чакларында, Себердә балалар өчәү бергә торганда, үзләрен бик кыерсытулары турында искә төшерә иде. Әтисез үскәнгә, аларны яклаучылар табылмаган, әниләре гел эштә булган. Берсендә Әгъләм абый түзмәгән дә, чыбыркы алып, малайлар белән сугышкан. Шулай итеп сеңлесен яклап калган.

Габдулла әнисен бик хөрмәтләде. Эштән кайтканда күчтәнәчләр, азык-төлек алып, янына керә иде. Әнисе исә пешеренеп улын көтеп торды. Тәрәзә төпләренең шау чәчәктә утырганы да хәтеремдә калган. Әнисе бик яхшы итеп шәлләр бәйләде. Кызыма бик күп кием-салым бәйләп кигезде, рәхмәт инде аңа, урыны җәннәттә булсын. Бик хәрәкәтчән булды, 92 яшенә кадәр, ә кайнатам Сәхәп бабай 96 га кадәр яшәделәр.

Габдуллага да: «Шул яшькә кадәр яшисең әле син», – дия идем. Аңа стентирование ясадылар. «Миңа 5 ел яшәргә калды», – дип әйтә иде. Үзен шуңа инандырып куйган, күрәсең. Һәм 5 ел яшәде дә...

– Тоемлаган микән?

– Вафат булган елның язында ук Габдулла хәлсезләнде. Шул вакытта хастаханәгә ятмады, «эшем бетмәде әле» дип әйтә иде. «Майда ял итәргә барам әле», – дип тә әйтте. Ютубтан караган микән, әллә кемнәндер ишеткәнме, белмим, ләкин Габдулла дөрес булмаган сүзне үзенә юраган бит. Ул, шунтированиедән соң озак яшәмиләр икән, дип ишеткән, ә аның бит стентирование иде...

Соңгы вакытта өйгә кайта да ята иде. Габдуллага авырлык килмәсен дип, бакчада да барысын үзем эшләдем. 15 еллап бәрәңге утыртканыбыз юк иде, шул елны бәрәңге утырттык. Кыяр, помидор, җиләк, кавын – барысын үстердем, балалар булышты, Аллага шөкер. Габдулла – Елховой авылыннан, ул якларда мишәр халкы яши, алар уңган-булган халык бит.

– Гаиләгез ишлеме?

– Кызыбыз Алия. Оныкларыбыз: берсе Әминә исемле, икенчесе быел мартта туды. Мулла чакыртып, Аишә дип исем куштык.

Габдулла Әминәгә бик тә үз фамилиясен бирергә теләде. Әминә 18 яшьтә бабасының фамилиясен алырга җыена, «Сәрвәретдинова булам» ди. Ничек килеп чыгар инде. Оныгыбыз бик акыллы. Кызыбыз Алия дә математик. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Казан дәүләт университетында укып чыкты.

– Габдулла әфәнде нинди әти, бабай иде?

– Баласын, оныгын шашып диярлек ярата торган әти һәм бабай иде ул. Татарча сөйләшүләренә нык куанды. Мин үзем татарча сөйләшеп үскән бала. Безнең нәсел – 9 буын муллалардан тора. Өйдә гел татарча сөйләшә идек. Оныгыбыз Әминәне кечкенәдән татарчага өйрәттек, 3 яшендә балалар бакчасының татар төркеменә биргәндә, ул татарча гына сөйләшә иде. Мәктәптә башлангычта татар сыйныфында укыды. Хәзер татарча белә һәм сөйләшә. Бабасы оныгының бөтен теләкләрен үти торган иде. Буш вакытын аның белән уздырырга яратты: машинасына утыртып уен бүлмәсенә алып бара, тәмле әйберләр белән сыйлый иде. Әминә кечкенә чагында һәр шимбә, якшәмбене бабасы белән уздырды. Оныгы хәзер шуларны исенә төшерә дә җылый.

Кызганыч, Габдулла икенче оныгыбызның туганын белмичә, арабыздан китеп барды. Шатлыкны безнең белән бергә уртаклаша алмады.

Алияне бик яратты, ул бит холкы һәм акылы белән дә әтисенә охшаган. Әтисенең фикеренә, уйларына һәрвакыт колак салды.

Безнең арабыздан китәсе елны Габдулла хастаханәдә ятып чыкты. Анда аны шулхәтле игътибарсыз караганнар икән. Бары тик йөрәген генә тикшереп, дәвалау курсы язып биргәннәр. Мин даруларны яхшы беләм, шуңа: «Менә моны эчәргә ярамый сиңа, Габдулла», – дим. Габдулла: «Син бит табиб түгел, миңа табиб язды», – ди. Ә менә кызын – Алияне тыңлады. Алия белән киңәшләшеп эшли иде. Ул бик акыллы һәм сүзен өзеп әйтә белә торган бала шул.

– Габдулла әфәнде нинди ир иде?

– Бик кайгыртучан. Яратуын үзенең гамәлләре белән исбатлады. Миңа соклanып карап тора иде. Бигрәк тә, мин кая да булса җыена башласам, аның бу соклану һәм ярату тулы карашын тоя идем. Хәзер шул карашы җитми...

«Әти сиңа гомере буе тугры булды. Хастаханәдә ятканда да гел синең исемеңне кабатлады. Аны син карый дип белде, сине уйлады», – диде кызым.

Әйе, гомер буе аның кадерлесе булып яшәдем. Акча янчыгында йөрткән минем кечкенә генә фотографиям дә шул хакта сөйли. Ул сурәт тәмам таушалып беткән булса да, Габдуллам аны бер дә үзеннән калдырмаган. Фотоны күргәч, ничәмә еллар буе үзендә саклап йөрткәненә исем китте.

Беренче тапкыр Гарәп Әмирлекләренә бардык. Кибеткә керә дә минем кием киеп караганны көтә. Берсеннән 16 әйбер алып чыктык. «Алабыз, бу сиңа килешә, матур», – дия иде. Кыйммәтле бүләкләрен дә кызганмады. Шул ук вакытта ул үзенә дә, башкаларга да бик таләпчән була белде. «Бу җире алай түгел, болай», – дип җайлап кына төзәтә дә, «Шуны эшләгәнсең, молодец!» – дип мактый да белә иде.

Үзенең хатасын таныганын сүз белән әйтмәс иде. Килеп кочаклап ала яки кызыклы сюрпризлар, бүләкләр ясый. Һәр 8 март бәйрәмендә искиткеч матур чәчәк бәйләмнәре алып кайта, иртәнге аш әзерли иде минем Габдуллам. «Син ничек шулай тәмле итеп кызыл балык белән бәрәңге куырасың?» – дип сорагач, елмаеп: «Аның сере бар, әйтмим әле», – дия иде. Еш кына, духовка мичендә бәрәңге пешереп, барыбызны өстәл артына җыя иде. Тук булсаң да, бергә утырып ашыйсың... Үзе дә коймак, кыстыбый яратты. Пешергән ризыкларымны яратып ашый иде. Хәзер инде: «Пешердем, тик син генә юк, Габдулла», – дим. Йөрәгем тынычлана шулай үзе белән сөйләшеп алгач. Кызым: «Әни, әгәр беренче син китеп барсаң, әти синсез яши алмас иде», – ди... Миңа да бик авыр аннан башка.

Аның башта мине иркендә яшәтерлек акчасы булмады. Бөтен кеше кебек үк яшәдек. Соңгы елларда инде: «Күпме кирәк, ал, акчаны санап тотма», – дия иде. Мин үзем мул тормышта яшәгән кеше түгел. Акчаның кадерен беләм. Институтта укыганда югары стипендия алып укыдым. Гади стипендия 28 сум булса, минеке 33 сум иде. Апа белән икәү укыдык. Апа укып бетергәч, энем килде. Әниләргә авыр булмасын дип, алардан акча алмый идем. Стипендиянең 2 сум 80 тиенен тулай торакка түләдем. Калганына көненә бер сум хисабыннан яши идем. Бер көн күбрәк алсам, калган көнгә җитми иде инде. Санап, тарта-суза, шул акчаны җиткердем.

Сүз ахырында шуны әйтәсем килә: акыллы кеше генә алган белемен дөрес куллана белә. Габдулла барлык нәрсәне үзе анализлый торган кеше иде. Митингларда да кызыклы һәм эчтәлекле чыгышлар ясар иде. Чыгышларын алдан язмый, күңелдән сөйли, фикерен дөрес итеп җиткерә белә иде. Ул китап күп укыды. Мин аның чыгышларын горурланып, сокланып тыңладым. Митингларга без гаилә белән бергәләп йөрдек. Республикабыз мөстәкыйльлек алган чагында Алиябезне ияртеп Казанга хәтле бардык.

Гомеренең соңгы елында Габдулла фирманың документларын тәртипкә китерүгә бик күп көч сарыф итте. Ул, фирма кызыма күчкәндә бернинди проблема да чыкмасын, дип тырышты. Үзенең санаулы көннәре калганын сизгәндер, бәгырь.

Тәлгать ӘХМӘДИШИН.

Сәнгатькә багышланган

(Әзһәр Хәниф улы Абдуллинның тууына 100 ел)

Ә.Абдуллин 1923 елның 20 октябрендә Минзәлә районының Тауасты Байлары авылында мөгаллим гаиләсендә туа. Атасы Хәниф Теләнче Тамак мәдрәсәсендә укыган, Дәвек, Күзкәй мәдрәсәләрендә мөгаллимлек иткән, гарәпчә яхшы белгән. «30 ел бергә яшәү дәверендә, – дип искә ала Асия ханым Абдуллина – Әзһәр аганың хәләл җефете, – аларның нәсел-нәсебенең табигый рәвештә музыкага һәвәс булганлыгына инандым. Бервакыт, Әзһәрнең әнисе безгә беренче тапкыр кунакка килгәч, радиодан бик матур яңа көй тапшырдылар. Ул шул көйгә мөкиббән китеп, тавышы белән көйләп торды да, беренче тапкыр пианино күрүенә дә карамастан, шул көйне пианинода җыеп бирде. Әтисе дә скрипкада уйный иде. Боларны искә алуым шуңа, Әзһәрнең таланты нәселдән килә».

1937 елда 13 яшьлек Әзһәр Казан музыка училищесына укырга керә. Виолончель классы укытучысы В.П.Варшавский классында музыка серләренә төшенә башлый һәм уңышлар казана. 1939 елда, музыка училищесының 35 еллык юбилеен үткәргәндә, Татарстан хөкүмәте училищеның иң талантлы берничә укучысына махсус стипендия бирү турында карар чыгара. Шулар арасында Әзһәр дә була.

1947 елда Казан консерваториясенә укырга керә һәм 1952 елда аны кызыл диплом белән тәмамлап, Мәскәү консерваториясе аспирантурасының хор-дирижерлык бүлегендә укуын дәвам итә. Шунда профессор Анисимов классында укып, татар халык көйләре темасына багышланган диссертация яза башлый. Аспирантураны уңышлы тәмамлап кайткач, ул консерваториядә хор–дирижерлык кафедрасында укытудан тыш, музыка училищесының симфоник оркестры белән дә җитәкчелек итә. 1956 елдан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында оркестр җитәкчесе булып эшли.

Шушы чорда Әзһәр Абдуллин С.Сәйдәшев иҗатын өйрәнүгә, аны яңадан торгызуга күп көч куя. Сәйдәшнең язып бетерелмәгән «Гөлнара» балетының партитурасын архивтан табып алып, берничә ел аның буенча эшли. Композиторның кайбер башка әсәрләренә дә яңа оркестровка булдыра. «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе», «Наемщик», «Сүнгән йолдызлар» кебек спектакльләргә язылган гүзәл әсәрләрнең музыкасын торгызып, яңадан халыкка кайтара. Ул әсәрләрнең кайберләре 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Ә.Абдуллин дирижерлыгында башкарыла һәм хуплап кабул ителә.

Күп тә үтми, Ә.Абдуллин Казан консерваториясенең өлкән укытучысы буларак, киңкырлы педагогик эшчәнлеген башлый; сирәк очрый торган табигый музыкальлеге, халык иҗатын һәм дөнья музыка культурасының тарихын һәм тәгълиматын тирәнтен белүе аңа төрле өлкәләрдә эшләргә булышлык итә. Әзһәр ага опера һәм балет театрында бик күп музыкаль спектакльләргә, мәсәлән, Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым»ына үзе аранжировка ясап, үзе үк дирижерлык та итә. Венгр композиторы Золтан Кодайдан үрнәк алып, татар халык җырларының көйләрен системалаштыра, аларны хор белән башкару өчен эшкәртә. Шушы ук әсәрләрен балалар хоры белән башкару өчен дә яраклаштыра. Кызганыч ки, бу әсәрләрне ул аерым җыентык итеп бастырып чыгарырга өлгермичә кала.

Татар музыка сәнгатен үстерүдә бар күңелен биреп эшләгән күренекле сәнгать эшлеклесе, дирижер, фольклорчы-галим, профессор, Ватан сугышы ветераны Әзһәр Хәниф улы Абдуллин 40 елга якын гомерен Казан консерваториясенең хор-дирижерлык кафедрасына багышлаган шәхес.

● **Мәскәү консерваториясе аспирантурасында укыган еллары. 1955 ел.**

● **Әзһәр Абдуллин портреты. Рәссам Эрот Зарипов эше, 2002 ел.**

Консерваториядә аның тарафыннан бик күп талантлы хор дирижерлары әзерләнде. Алар Идел буе регионы республикаларында гына түгел, хәтта Россиянең бик күп шәһәрләрендә, чит илләрдә дә хор культурасы үсешенә зур өлеш кертә. Бу уңайдан Россиянең һәм Удмуртиянең халык артисты, Удмуртия Дәүләт премиясе лауреаты, «Италмас» Удмурт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе, композитор А.В.Мамонтов исемен атау да урынлы булыр.

Консерваториядә укыту елларында укучыларда сәнгатькә мәхәббәт һәм ышаныч уята алуы, кеше психологиясен аңлый белүе, тыйнаклыгы, һәркемгә ихтирамлы, игътибарлы булуы белән үзенә җәлеп итә, яраттыра иде. Ул дан-шөһрәт яратучан түгел. Гаҗәеп киң талантын, үзенең артык тыйнаклыгы аркасында, вакытында дөньяга танытырга омтылмады. Хор белән эшләгәндә кисәтү–күрсәтмәләре төгәл, кыска булып, эшенең асылын күрә, үтемле итеп әйтә белә, шәкертләренә комачауламас, аларның башлангычын кысмас, шул ук вакытта бик таләпчән дә була белде. Консерваториядәге укытучыларның музыка өлкәсендәге эшләренә тирән анализлы тәнкыйть–рецензияләрне ул яза иде. Шул вакытларда аның ярдәмендә консерватория хоры, опера һәм балет театрының хор һәм оркестры белән Татарстан радиосында бик күп язмалар дөнья күрә. «Мәрфуга», «Таң атканда», «Хуш авылым», «Фазыл чишмәсе» һ.б. әнә шундыйлардан.

1965–1968 елларда Ә.Абдуллин Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе булып эшли. Әзһәр әфәндедән тирән белем һәм иҗади мәктәп алган, аның талантлы шәкерте, Татарстанның халык артисты, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хормейстеры, мөгаллимә Венера Гәрәева, аның бик күп эшкәртмәләрен һәм композитор буларак язган әсәрләрен башкарып, дөньяга күрсәтте. Ансамбльдә бергә эшләгән, аңарда белем алган елларны В.Гәрәева болай искә ала: «Әзһәр ага белән мин бала чактан бирле таныш. Минзәлә театрының баянчысы булып эшләгән әтием белән дуслар, театрга еш килә иде. Профессиональ сәнгать дөньясында аның белән беренче очрашуы 60 елларда ул ансамбльдә эшләгән вакытта булды. Музыкант-башкаручы осталыгы аңа тагын бер яңа талантын ачарга ярдәм итте. Бу – татар халкының төрле жанрдагы җырларын һәм композиторлар әсәрләрен хор белән башкару өчен эшкәртү осталыгы».

Әйе, халкыңа хас аһәңнәрне югалтмыйча, үз кануннарын саклап гармония белән бизәү – бик зур сәнгать. Әзһәр ага хор өчен эшкәрткән әсәрләрдән: «Фазыл чишмәсе», «Әрбет», «Туган тел», Р.Яхинның «Сорнай моңы», «Агыйдел сюитасы» һ.б. бик күп җырларны атап була. Мәсәлән, «Фазыл чишмәсе» көй ягыннан гади, чылтырап аккан чишмәдәй саф, кояш кебек якты. Әзһәр ага җырның кушымтасын төрле тавышларда яңгыратып, искиткеч гармоник һәм математик төгәллек белән эшкәрткән. Ә нинди симфоник яңгыраш! Моны исбатлау өчен «Туган тел» әсәрен алып карыйк. Бу көй – безнең бишек җырыбыз да, гимныбыз да, динебезне, телебезне сакларга өндәүче дога да. Әзһәр ага «Туган тел»дә мөмкин булган бөтен ысулларны файдаланган. Әсәрнең буеннан–буена полифоник тема «Тәфтиләү», «Туган тел», «Бишек җыры» – кеше тавышы симфониясе булып яңгырый. Әзһәр аганың иң затлы эшкәртмәләренең берсе – «Сорнай моңы» (Р.Яхин, Ш.Хөсәен). Ул көй Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов өчен махсус эшләнеп, халык күңеленә дә аның башкаруында кереп калды. Бу бөек әсәрне японнар, алманнар, чехлар, Африка илләрендәге халыклар да аяк өсте алкышлады. Бу алкышларның төп сәбәпчесе Әзһәр ага иде. Аның соңгы эшкәртмәләреннән «Картуф» җыры әле дә ансамбльнең репертуарыннан төшми яши. «Болын» һәм «Әзифә» җырларын ул Ания Туишева тавышы өчен, «Сандугачкай» белән «Зәңгәр чиләк»не Лена Бичарина өчен эшкәртеп, аларга бүләк иткән иде. Әзһәр ага җырларны бервакытта да бер кушымтаны да гел кабатлый торган вариант белән эшкәртмәде, музыкаль фантазиягә бай, ул һәр кушымтаны төрлечә бизәкләп, җырны тулы сюжетлы күренешкә әйләндерә иде.

Ә.Абдуллин хор эшлеклесе генә түгел, олы талант – зур симфоник оркестрлар белән дирижерлык итү сәләте аңа тумыштан бирелгәндер. Ул эшкәрткән хор әсәрләре симфония булып ишетелә. Мондый талант татар хор музыкасында сирәк очрый.

1989 елда консерваториядә татар музыкасы кафедрасы ачыла һәм Ә.Абдуллинның зур методик, теоретик, гамәли иҗат тәҗрибәсе кафедраның башлангычына нигез ташларын ныгытуга терәк була. Ул кафедрага татар музыка фольклоры белгече буларак күчерелә һәм аңа профессор вазыйфасын тапшыралар.

Ә.Абдуллинда табигатьне бөтен матурлыгы белән ишетү сәләте була. Мәшһүр дирижер Натан Рахлин да аңа карата: «Мөкәммәл ишетүле беренче татарны очраттым», – дигән иде. Рахлин нининдер сәбәпләр аркасында үзе симфоник оркестр белән дирижерлык итә алмаган очракларда, оркестрын бары тик Әзһәр агага гына ышанып тапшыра торган була. «Ул танылган, тәҗрибәле мастер, киң масштаблы талант кына түгел, тирә–ягына җылы яктылык сибеп, үзенә тартып торган тирән фикерле һәм юморлы акыл иясе, сокланырлык кешелек сыйфатлары балкып торган олуг шәхес булып исемдә калды, – ди консерваториянең ректоры Рубин Абдуллин. – Консерваториянең композиция һәм фортепиано факультетында белем алган кызы Алсуга зур өметләр баглыйбыз, башкаручы буларак та, композитор буларак та әтисенең иҗат эшен дәвам итәр дип ышанабыз», – дигән иде.

гомер

● Әзһәр Абдуллин консерваториядә укыткан Бөек Ватан сугышы ветераннары белән. 1990 ел.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт университетының хор капелласы җитәкчесе, профессор В.П.Леванов: «Ә.Абдуллин, беренчеләрдән булып, татар халык җырларының жанр төрлелеген һәм халык җырларын башкару үзенчәлекләрен өйрәнде. Аның бар иҗаты татар музыкасы тарихында, М.Мозаффаров, А.Ключаревлардан соң, аерым тулы бер чор булып тора», – дип искә ала.

Ә.Абдуллин иҗат иткән чорда татар хор культурасының югары биеклектә булуы күзәтелә. Хор җәмгыятенең рәисе буларак та ул бу өлкәгә бәһаләп бетергесез гамәли өлеш кертте.

Габәши, Мозаффаров, Ключаревлардан соң, заман миссиясен берүзе күтәреп, тормышка ашыра алган ул. Аның иҗаты шәхси мөнәсәбәтләр каршылыгыннан югары булды. Нинди генә тармакка тотынса да, һәр эшне югары профессиональ дәрәҗәдә башкарды. Кайсы гына жанрны алсак та, аның үзенә генә хас фикерләү культурасы булганлыгы ярылып ята. Әзһәр Абдуллин – хор белән башкаруда академик һәм халыкчанлыкны берләштерә алган әлеге бергәлекне синтезлау юлында алтын уртаклыкны тапкан һәм аны укучыларында да тәрбияләгән шәхес. Аның сыйфатларын укучылары В.Гәрәева һәм А.Мамонтов эш ысулларында да ачык күреп була.

Татар җырының бер тавышлы табигатен тоемлап эш итүе, аерым җырчы тавышы белән хорны куша алуы, табигать күренешләре төсмерләрен, башкару манераларын хор «келәмендә» берләштереп сокланырлык итеп чагылдыра алуы, киң фактуралылык, симфониялелек, гомумән, күп тавышлылыкның үз кылын табуы – аның әсәрләренә хас сыйфат.

Ә.Абдуллин кеше тавышының мөмкинлекләрен, симфоник һәм халык уен кораллары оркестрларының яңгыраш үзенчәлекләрен яхшы белеп эш итте. Сәйдәшев, Мозаффаров, Ключарев традицияләрен камилләштереп, заманының эстетик таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә дәвам итте. Галим буларак, татар халык җырларын жанрларга бүлеп, халык җырларының кайбер башкарылу үзенчәлекләрен ачыклады, фән өлкәсендә нигезле өлеш кертте. Бу өлкәдә ул музыкаль иҗат белән башкаручылыкның бер-берсенә йогынтысы, халык җырчыларының башкару манералары һәм көйнең структурасы белән башкару үзенчәлекләрен ачыклады. Орнаментлы озын көйләрне иркен–импровизацион манерада һәм кызу тизлектәге җырларда, киресенчә, бер тавыштан икенчесенә күчкәндә зур төгәллек белән башкару ысулларын исбатлап күрсәтте.

Идел буе халыкларының хор сәнгате энҗе-җәүһәрләрен җыю белән беррәттән, ул бу халыкларның композиторлары әсәрләренә дә эшкәртмәләр ясап, хрестоматия әзерләде. Әмма дөньяга чыгарырга өлгерә алмады. Бу эшне булдырган очракта, мондый уникаль хрестоматия студентлар өчен бик кирәкле кулланма булыр иде.

1963 елны Ә.Абдуллинның Лебединский редакциялавендә матбугатта күп кенә фәнни эшләре һәм «Баянда уйнарга өйрән» китабы татар телендә бастырылып чыга. Бу җыентыкта ул баян өчен үз эшкәртүендә 32 татар халык көен һәм үзе иҗат иткән берничә пьесаны да кертә. Өстәвенә, Әзһәр ага күп кенә авторларның фәнни эшләрен рецензияли һәм редакцияли. Аның 80 гә якын музыкаль язмасы Бөтенсоюз радио фондында саклана. Ул – күп кенә әсәрләрнең авторы да. Аларның күпчелеге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен язылган һәм эшкәртелгән: «Бәхет юлы», «Шат үтә безнең көннәр», тынлы оркестр өчен «Бәйрәм маршы», «Сарман яшьләре» сюитасы, шулай ук, «Каз өмәсе» дип аталган вокаль хореографик күренешне дә ансамбль өчен ул иҗат итте. С.Сәйдәшевнең 90 еллык юбилеена «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасы аның тарафыннан концерт програмасы вариантында эшкәртелде.

Ә.Абдуллинның хор өчен татар фольклоры әсәрләренең эшкәртелү ысуллары, үзешчән һәм профессиональ хорлар белән эшләү алымнары хезмәтләре бар. Татар музыка бүлекләре өчен дә укыту методикасы бөтенләй юк дәрәҗәсендә икәнен, соңгы вакытларда татар халык әсәрләрен башкару манерасы турында да күп бәхәсләр баруын истә тотсак, болар – милли сәнгать бүлекләре өчен уку әсбабы булырлык хезмәтләр. Әзһәр аганың татар сәнгатенә, хор музыкасына керткән өлеше бәһаләп бетергесез икәнен белгән хәлдә, аның барлык хезмәтләрен бер китапка туплап, 2013 елны «Ихлас» нәшриятендә Ф.Җәүһәрова һәм Ф.Арсланова тарафыннан җыентык дөнья күрде. Әмма, тиражы бик аз (100 данә) булу сәбәпле, мәдәният өлкәсендәге тиешле укучыларына барып җитмәде.

Филүсә АРСЛАН.



● Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Әзһәр Абдуллин хор өчен эшкәрткән «Туган тел»не башкара, солист Татарстанның атказанган артисты Таһир Якупов. 1969 ел.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

11 ноябрь (шимбә). ***Рабигул ахир аенның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 5.13 сәгатьтә калка, 15.40 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.36 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр куңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Кара җиләк сихәте

Канны чистарту, андагы холестерин һәм шикәрне киметү өчен, кара җиләкнең яшь яфрак һәм үрентеләрен җыеп, шуны ваклап, 1 аш кашыгын 1 стакан суда кайнатып чыгаралар да, 2 сәгать төнәтеп, сөзәләр, көненә 3 тапкыр 1әр стакан эчәләр.

12 ноябрь (якшәмбе). ***Рабигул ахир аенның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 6.36 сәгатьтә калка, 15.47 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.32 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Безләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне упкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Томаудан дәва

Томау башланып кына килгәндә, болай дәвалану булыша. 1 баш суганны иттарткычтан чыгарып яки кыргычта кырып, кечкенә фарфор чәйнеккә салалар, капкачын ябалар һәм борыныннан авыз белән сулыйлар, сулышны исә борын аша чыгаралар. Процедураны көненә берничә тапкыр 10ар минут кабатлыйлар. Яки 3 бүлем сарымсакны 1 стакан сөткә кырып салып, кайнатып чыгара язалар, бераз суыталар. 1 әр чәй кашыгы каба-каба көн буена эчеп бетерәләр.

13 ноябрь (дүшәмбе). ***Рабигул ахир аенның 29нчы көне. 30нчы, 1нче Ай тәүлекләре. Ай Чаян йолдызлыгында, 8.02 сәгатьтә калка, 15.57 сәгатьтә бата. 12 сәгать 27 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 8.28 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Баллы сөт

1 стакан җылы сөткә 1 аш кашыгы бал кушып, чәнечке белән 5 минут күпертәләр, иртәнге һәм кичке ашка 1 сәгать кала эчәләр. Мондый сөт ашказаны җәрәхәтенәнән саклый: бал ялкынсынуга каршы тора, сөт исә агрессив әчелекне баса. Болай дәвалану кислоталылыгы югары булган гастрит вакытында да файдалы.

14 ноябрь (сишәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аенның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 9.32 сәгатьтә калка, 16.14 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.24 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Герпестан – сарымсак

Ирен чабыртканда, болай дәвалананалар: сарымсакны изеп, төнгелеккә шул урынга ягалар. Шулай ук иренгә һәр 2 сәгать саен ак чыршы (пихта) мае сөртү дә булыша.

15 ноябрь (чәршәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,11.01 сәгатьтә калка, 16.43 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.20 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

16 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 12.18 сәгатьтә калка, 17.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.16 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Диареядән дәва

Эч киткәндә, мондый үлән төнәтмәләре белән дәвалану нәтиҗәле. 20 шәр грамм ат кузгалагы һәм уралмалы кырлачны (горец змеиный) кушып, шуның 2 чәй кашыгын 1 стакан кайнар суда 30 минут төнәтәләр дә, сөзеп, көненә 3-4 тапкыр чирегешәр стакан эчәләр. Яисә 15 әр грамм чагыр (монгол чәе – бадан толстолистный) һәм кызылбаш (кровохлебка) тамырын ваклап кушып, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суда 10 минут пешерәләр дә, 30 минут төнәтеп, сөзәләр, көненә 3-4 тапкыр чирегешәр стакан эчәләр.

17 ноябрь (җомга). ***Җөмәдел әүвәл аеның 4нче көне. 5нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 13.13 сәгатьтә калка, 18.46 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.13 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Әфлисунлы-лимонлы кабак джемы

1,5 кг кабак, 1 әр кг әфлисун һәм лимон, 3-4 кг шикәр кирәк. Кабакны кабыгыннан һәм төшләреннән чистартып, цитрусларны исә кабыгы белән иттарткычтан чыгаралар. Шикәр кушып, яхшылап болгаталар да, бераз тоталар. Аннары сүрән утта шикәр бөтенләй эреп беткәнче пешерәләр. Кайнар килеш банкаларга тутыралар. Мондый джем чәй эчәргә дә бик тәмле, бөккән һәм печеньелар пешерү өчен менә дигән эчлек тә.

Нурихан ФӘТТАХ

Борынгы җәмгыять һәм хатын-кыз

XIX гасырда Америка тарихчысы һәм этнографы Льюис Морган Америка индеецларының туганлык терминнарын һәм алардагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне өйрәнеп, борынгы җәмгыятьне аңлатуда үзенчә зур ачыш ясый. Морган фикеренчә, сыйнфый җәмгыять барлыкка килгәнче, борынгы заманнарда ыручылык җәмгыяте хөкем сөргән. Ыручылык җәмгыятендә хатын-кызлар хакимлек иткән, ягъни хатын-кыз, ана кеше җитәкче һәм юлбашчы ролен үтәгән. Ыручылык җәмгыяте таркалып, дәүләт барлыкка килгәндә, хатын-кыз хакимлеге юкка чыккан һәм җәмгыятьтә ир кеше, ата кеше баш булып калган. Шул рәвешчә патриархат чоры башланган.

Матриархат-патриархат терминнары бүгенге фәнни әдәбиятта киң кулланыла. Этнографлар кешелек җәмгыятенең борынгы чорына, өйләнүгә, мираска, гомумән хатын-кызга кагылышлы күп кенә мәсьәләләрне тикшергәндә үз фикерләрен еш кына менә шушы ике терминга бәйле рәвештә аңлатырга тырыша. Ләкин чынлыкта җәмгыять үсешендә беркайчан һәм беркайда хатын-кыз хакимлеге чоры булмаган. Җирнең, Ананың, хатын-кызның борынгы карашлар буенча өстен һәм беренче була алмаганлыгын без инде күп күрдек. Мифология һәм тел фактлары гына түгел, конкрет этнографик фактлар да нәкъ шул турыда сөйли. Мәсәлән, иҗтимагый үсеш ягыннан башка барлык халыкларга караганда бик нык артта калган Тасмания кабиләләрендә ыруда ана, хатын-кыз түгел, бәлки ата һәм ир кеше баш булган. «Тасмания җәмгыяте иҗтимагый үсешнең әүвәлге стадияләрен күз алдында тоткан матриархатка берничек туры килмәгән» («было совершенно чудо») дип яза Владимир Кабо. Мадагаскарда мальгаш кабиләләрендә: «Җир бөтен кабиләнеке исәпләнелә, гаиләдә ата иң өлкән кеше санала». Көньяк Американың Шингу елгасы буенда яшәүче караха кабиләсендә: «Бары тик алар гына (ирләр) гаиләдәге мал-мөлкәтнең хуҗалары исәпләнә, бары тик аларга гына дин серләре билгеле». Камайура кабиләсендә: «Изге әйберләрне ирләр бик нык саклап тота. Изге әйберләр (табыну нәрсәләре) махсус өйләрдә саклана, анда керү хатын-кызга тыела». Яңа Гвинеядагы 1958 елны гына дөньяга билгеле булган эйпо кабиләсендә авылларда халык кечкенә патриархаль кланнарга бүленгән. Тогодагы тамберма кабиләсендә авылларда кешеләр «кубвоти» дип аталган кланнарга бүленә. Кубвотига бер атадан туган күп санлы ир туганнар берләшә. Мондый мисалларны җир шарының теләсә кайсы төбәгеннән табарга һәм аларны күпләп китерергә була.

Шул ук вакытта, матриархатны яклый сыман тоелган мисаллар да күп. Мәсәлән, кайбер халыкларда борынгы чорларда хатын-кызлар бик зур дәрәҗәгә ирешкән, ыру, кабилә, халык юлбашчылары, хәтта атаклы сугышчылар була алган. Сакларда Зарина, сарматларда Амага, массагетларда Томирис шундый атаклы хатын-кызлар исәпләнелә. Марко Поло монгол ханы Хайдуның үзара көрәштә дә, сугышта да беркемнән җиңдермәгән батыр кызы турында яза. Византиянең Валентин дигән илчесе 575 елда Арал буе далаларында була. Бу җирләрдә Аккагас дигән биләмәнең башлыгы хатын-кыз була. Аккагас – скифларның шушы өлеше белән идарә итүче хатын-кыз исеме.

Күчмә халыкларда хатын-кызлар ирләр кебек үк сугышта катнашканнар. Хатын-кыз сугышчылар савроматларда, сакларда, сарматларда, кыпчакларда, хуннуларда, савирларда була. Төркиядәге йөрүкләрнең, тунгусларның (эвенкиләрнең) хатын-кызлары ирләр кебек үк атта йөри, корал тотып сугыша ала. XIV гасырда Конгода яга дигән сугышчан кабиләдә хатын-кызлар корал тотып сугышта катнашкан. Геродот сугышчан амазаннар – хатын-кыз кабиләсе булуы турында яза. Алай гына да түгел, тарихи язмаларда хәтта бары тик хатын-кызлардан гына торган патшалыклар булуы турында әйтелә.

Татар әкиятләрендә хатын-кызлар, гомумән, ирләрдән акыллырак, зирәгрәк итеп тасвирлана. Мәсәлән, «Йөз куйга сатып алынган төш» әкиятендә ирен – көтүче егетне авыр хәлләрдән хатыны коткара. «Ятим бала» әкиятендә дә, патша ир кешегә үтәп булмаслык эш кушкач, ир кеше елап хатыны янына кайта. Хатыны ирен: «Кайгырма, ятып йокла, барысы да җайланыр», – дип тынычландыра. Үзе тышка чыгып бер әфсен укый да, үтәп булмастай эшне сихер һәм тылсым ярдәмендә башкарып куя. «Патша малае һәм аның фәкыйрь күршесе», «Патша белән солдат», «Аучы белән асрау» һ.б. әкиятләрдә дә хатын-кыз ирләрдән акыллырак, көчлерәк, белемлерәк итеп сурәтләнә. Дөрес, мондый кызлар гади кешеләр түгел. Алар дию пәриенең яисә җир асты патшалыгының кызлары, шуңа күрә алар тылсым, сихер көченә ия һәм алар төрле кыяфәтләргә керә алалар.

Мондый нәрсәләргә без бүген «әкият» итеп кенә карыйбыз. Ләкин әкиятне кеше уйлап чыгарган, шуңа күрә анда аның карашлары чагылган дип әйтми мөмкин түгел.

Шулай итеп, без бер үк вакытта «матриархатны» да, «патриархатны» да яклый торган мисалларны күпләп таба алабыз. Әгәр дә мәгәр, Морган теориясенә нигезләнеп, барлык халыклар башта матриархат чорын, аннан патриархат чорын үткәннәр яисә үтәргә тиеш дип исәпләсәк, бүгенге көндә дә әле таш гасырында яшәүче, ләкин ирләр тарафыннан идарә ителүче кабиләләрне җир шары исемлегеннән сызып ташларга туры килер иде. Бит Яңа Гвинеядагы эйпо яки Америкадагы камай ура кабиләләре күптән инде матриархат чорын үткән булырга тиеш иде, чөнки аларда «патриархат» чоры дәвам итә.

Шул ук вакытта, иҗтимагый үсеше бик нык алга китсә дә, кайбер гадәтләре, йолалары буенча «матриархат» чорында яшәргә тиешле кебек халыклар булуы да мәгълүм. Мәсәлән, Геродот Кече Азиядәге ликиләр турында: «Алар үзләрен ата исеме белән түгел, ана исеме белән атый», – ди. Без моны ликиләр үзләрен Ата улы дип түгел, Ана улы дип атаганнар мәгънәсендә аңлыйбыз. Геродотның әйтүенә караганда, ликиләр Кече Азиягә Крит утравыннан күченгән. Крит утравында Геродот чорыннан 1-2 мең еллар элек үк инде югары культуралы халыклар яшәгән. Крит утравы кабиләләре кимендә моннан 3-4 мең еллар элек үк инде, таш гасыры чорын үтеп, метал чорына аяк баса. Һәм кайчандыр шунда яшәгән Геродот заманында «матриархат» формациясендә булган ликиләр бүгенге көннең таш гасырында яшәүче эйполардан яисә XIX гасырның беренче яртысында үлеп беткән Тасмания кабиләләреннән чагыштырмас дәрәҗәдә алдынгырак булганнар.

Шунысы игътибарга лаек, «матриархат» яисә «ана нәселе», «ана ыруы» тәртипләре сакланган кайбер кабиләләрнең иҗтимагый тормышында хатын-кызлар түгел, бәлки ирләр өстенлек итә. Мәсәлән, Непалдагы тхару кабиләсендә өйдә (хуҗалыкта, семьяда) кайбер хатын-кызның роле зур, ләкин, шуңа да карамастан, ир кеше гаилә башлыгы санала; тхарулар исә еш кына зур семья булып яши. Һәрбер гаро ана нәселендәге («матрилинейный») зур төркемнең – иң әүвәлге ыру яисә фратриянең бер әгъзасы исәпләнелә. Ләкин гароларда гаиләнең реаль башлыгы – ир кеше: барлык хуҗалык эшләрен ул хәл итә.

Шәфкать ГАНИЕВ кытыклары

Башыңа төшсә, пешекче дә булырсың

Әйбәт кенә хезмәт итеп яткан чаклар. Армия тормышына күнегеп беттем бит тәмам. Шулай тыныч кына яшәгәндә поварыбызны комиссовать иттеләр. Бик озак эзләделәр, тәки таба алмадылар повар. Кеше ышанмаслык сүзне, дөрес булса да, сөйләмә диләрме әле? Ничек итеп мине пешекче итеп сайлаганнарын сөйләп тормыйм. Бу язмам армиядә биш ай буе пешекче вазыйфасын башкаруым турында.

Минем беркайчан да, үзем өчен генә булса да, берни пешереп караганым булмады. Өйдә әни белән ике сеңелкәш тә булгач, мондый уй башка да кереп чыкмады.

Поварыбыз безне кич белән ашатты да, хушлашып, машинага утыргач, миңа әйтте: «Мотри, монда начар пешерсәң, кыйнаулары бар!» Уйга калдым. Әйтүе генә җиңел бит, 33 кешене ашатып кара әле син…

Безнең нокта белән рәттән бистә бар иде. Киттем шунда повар эзләп. 60 яшьләр тирәсе бер апаны таптым бит, Ходайның рәхмәте! Ул гомере буенча балалар бакчасында пешекче булып эшләгән. Сөйләдем моңа, көчкә риза булды миңа булышырга.

Иртән, сәгать 4ләр тирәсе. Апаны каршыладым, коймаңы әзерләп куйган идем. Ярый әле, бик түземле апа булып чыкты. Мин аның һәр хәрәкәтен, кайчан нәрсә күпме салырга икәнен төгәл язып бардым. Солдатлар уянганчы, апаны койманың икенче ягына озатып та куйдым. Обедка аш куярга да өлгердек. «Обед алдыннан килермен», – дип ышандырды апа.

Бераздан режим буенча солдатлар тезелеп килделәр. Алар белән ике офицер. Шуларның берсе: «Ул беренче тапкыр пешерә, кемгә ошамый, үзегез пешерерсез!» – дип кисәтте.

Солдатлар ботканы ашап караганнар иде, чүт телләрен йотмадылар. «Болай пешерсә, без риза, бик риза», – дигән булалар.

Пешекче апа ике атна килеп йөрде минем янга, күп нәрсәгә өйрәндем аннан. Мин дә буш калдырмадым аны… Ярмасы, тушенкасы, мае, чәе…

Әле әйтергә онытканмын. Безнең ноктада симертергә ике чучка да бар иде. Солдатлардан калган ашау белән сыйлыйлар иде аларны. Шул җитә иде, поварыбызны комиссовать иткәнче.

Ә миңа чучкаларга махсус әзерләргә туры килде.

Үземнекен иттем

Сиксәненче елларда армиядә хәрби частьта гына солдат формасын бирә иделәр. Без дә мунча кергәннән соң өр–яңа форма алдык. Прапорщик миңа нигәдер бар киемне дә ике үлчәмгә зурракны бирде. Аптырап калдым мин, «Алыштырыгыз әле!» – дигәч, «Дембельдән соң әниең яраклысын алыр», – диде. Миннән гәүдәгә шактый гына зур егет бар иде, аңа үземнең форманы бирдем, киеп карарга куштым. Искиткеч килеште аңа, әйтерсең, парадка әзерләгәннәр. Мин: «Синә килешә икән, салма, үзеңә калдыр», – дип, аның формасын киеп куйдым! Күрсәгез иде сез мине, әтисе киемен кигән кечкенә малайга охшап калдым! Комбатны күрдем дә, аның янына таба атладым…

– Это что за пугала огородная! – ди комбат.

– Вот такую форму дали, не дома же нахожусь, – дидем.

Ул, старшинаны чакырып, бер сәгать эчендә солдатка охшаган булсын дип, әмерен бирде. Шулай итеп, мин үз үлчәмемдәге форма кидем.

Елак малай

Иртән автобуста кеше күп була. Инде күнектем, тик кичә уңайсызлыкны тагын да арттырып, ике яшь тирәсендәге малай кычкырып елады. Әнисе ниләр генә әйтеп үгетләмәде, сабый туктарга уйламый. Бу чаралар файдасыз булгач, иң куркынычын уйлап тапты: «Будешь реветь, бабай придёт и заберёт!» Ә малайның исе дә китмәде, елый да елый! Түзмәдем, әйттем: «Нам, бабаям, такой плакса малай не нужен!» Теге малай шундук туктады, әллә бабай алмас дип курыкты инде? Әни кеше кызарып гафу үтенде. Мин аны тынычландырып: «Главное – результат!» – дидем.

Болай да «бабник»

Автобуста әбисе белән якынча биш яшьлек бик сөйкемле малай сөйләшеп баралар. Тукталышта бер ир-ат керде дә бу малайга: «Какой ты красивый мальчик, наверно бабник будешь!» – диде. Сабый югалып калмады: «Я и так бабник, бабушку люблю. Правда, бабушка?»

Шаян кыз

Минем танышыма якынча 45 яшь тирәсе. Ул интернетта бер татар кызы белән танышкан. Шулай ике ел көнә–төнә сөйләшә торгач, Казанда очрашырга булганнар. Егет кунак йортында ике урынлы бүлмә дә алып куйган. Күрешеп бик озак сөйләшкәннәр болар, көн төнгә алышынган. Кыз юыну бүлмәсенә кереп киткән. Танышым тумбочкага караса, анда парик, ясалма тешләр, керфекләр, ди… Хәзер ваннадан нинди әби чыгар дип коты качкан танышымның. Кыз чыккан да: «Әәә, курыктыңмы? Мин шаярттым бит!» – дип көлгән.

Тәрбияче булдым

Отпуск вакытын авылда абый белән уздырырга булдым. Күптән күрешеп сөйләшкән юк иде. Ләкин аңа ике көннән хатыны белән еракка китәргә туры килде. Китәр алдыннан миңа сыерны, сарыкларны көтүгә озатырга, малаен бакчага илтергә, тагын әллә ниләр куштылар. Бар да яхшы, үз вакытында эшләнә, тик биш яшьлек Илдар исемле малайны бакчага дип уятыр өчен шактый чиләнергә туры килде. Ашатам дисәң дә: «Моны ашамыйм, тәмсез пешерәсең», – дигән була. Аптырагач, күп еллар балалар бакчасында эшләп, лаеклы ялга чыккан апама шалтыраттым. «Кайгырма, пүчтәк хәл минем өчен!» – дип, мине тынычландырды ул. «Иң беренчедән, аш пешергәндә аны да җик, булышсын», – диде. Чыннан да, малай үзе катнашкач, «тәмле», – дип ашады. Инде иртә тору мәсьәләсе генә калды. Анысын кич ашап утырганда сөйләштек. Мин будильникны иштеммим, көтүгә җитешмәбез, шуның өчен Илдар мине уята, имеш. Әле кисәтеп тә куйдым: «Бик каты йоклыйм, уянмасам, бер кружка су сип!» – дип әйттем…

Икенче көнне мин бик иртә уяндым. Вакыт җитте дип, сәгать тә шалтырый башлады.Тик мин йоклыйм, имеш. Илдар уянды да: «Тор тизрәк, көтүгә соңга калабыз», – дип әй мине тирги. Ә мин хәзер я су сибәр дип куркып, тизрәк тордым.

Күп еллар узды, Илдар үзе әти кеше. Хәзер биш яшьлек малаен шулай ук тәрбияли икән…

Минем машина!

Күршеләрем юллама алып, Төркиягә китте. Күмердәй кап–кара кечкенә этләрен миңа калдырдылар. Вакытында ашатам, кичләрен урамда йөрибез. Бервакыт бу «Нива» машинасы астына кереп китте.

Мин аңа:

– А ну, выйди, паразит, – дип сукрануым булды, машинаның хуҗасы:

– Ваще–то моя машина, документы вот, – дип машинасының ишеген ачты.

– Кирәге бар иде синең машинаң, – дип этне тартып чыгардым…

Шофер:

– Уф, куркыттың! – дип көлде.

Әйбәт укыганмын

Татар теле һәм әдәбияты укыткан апама шалтыраттым бит! Тиздән туксан яшен тутыра ул. Бик шатланды: «Чыккан язмаларыңны укып барам, горурланам, онытмыйм. Барыгызны да хәтерлим», – диде. «И, улым, рәхмәт сиңа онытмаганың өчен. Гел «бишле»гә укыдың бит!» – дип әйтмәсенме. Ә мин гел «өчле»гә диярлек укыдым бит аның фәненнән…

Иҗау каласы.

Дубай алтыны

Бакыр, җиз, рандоль (бериллий бронзасы) һәм бераз гына саф алтыннан торган Дубай алтынының ватаны саналган Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле металл эшләнмәләр бихисап күләмдә җитештерелә торган дәүләт. Шулай ук бакыр, цинк, бериллий һәм кургаш коелмасы да кулланыла. Мондый ясалма алтын экологик чиста, аллергия китереп чыгармый, кояш нурлары, диңгез суы тәэсиренә чыдам. Ел саен БГӘ зәркән остаханәләрендә 250 тонна алтын эшкәртелә. Кайбер мәгълүматлар буенча, Дубайда һәркемнең өендә уртача 14 килограмм алтын бизәнү әйбере саклана. Андагы дөньяда иң зур алтын базарындагы 300 кибет көн саен 10 тонна балдак, йөзек, беләзек, алка тәкъдим итә. Эшләнмәләрнең авырлыгы берничә миллиграммнан берничә килограммга җитәргә мөмкин – хәтта алтын күлмәкләргә кадәр бар. Алтын коелмаларны гарәпләр Швейцариядән сатып ала, анда исә Перудан кайтарталар.

(“Goldengod”).

Чыпчык каргаган

1958 елның 12 февралендә Кытай җитәкчесе Мао Цзэдун илдәге барлык күсе, чебен-черки һәм чыпчыкларны юк итү турында фәрман имзалаган. Бар халык әлеге җан иияләрен ауларга керешкән. Әмма күселәр һәм чебен-черки, никадәр генә юк итәргә тырышмасыннар, кимергә уйламаган да. Ә менә мескен чыпчыкларга каршы көрәш көннән-көн көчәйгән. Ил халкы иртәдән кичкә кадәр чүпрәк селкеп, кәстрүл төбенә кагып, кычкырып, сызгырып, кошкайларга җиргә кунарга комачаулаган. 15 минуттан артыграк һавада бәргәләнгән чыпчыклар, хәлсезләнеп, җиргә егылып төшкән, аларны шундук үтерә барганнар. Кампаниянең беренче өч көнендә генә дә Пекин һәм Шанхайда миллионга якын кош юк ителгән. Бер елда исә ике миллиардка якын чыпчык һәм башка кечкенә кошларның башына җиткәннәр. Кытайлар кошкайларны җиңүләренә сөенеп туя алмаган. Күсе, чебен-черки турында искә дә төшермәгәннәр, алар белән көрәшү катлаулы булгач, барысы да кул селтәгән. 1959 елда “канатсыз” Кытайда моңарчы күрелмәгәнчә мул уңыш җыелган. Хәтта скептиклар да чыпчыкка каршы чараларның уңай нәтиҗәсен таныырга мәҗбүр булган. Әлбәттә, төрле үлән бете, күбәләк корты, саранча кебек корткычларның да ишәюе күзәтелә, әмма бу мул уңыш фонында хафаланырлык сәбәптәй тоелмый. Ә менә инде 1960 елда авыл хуҗалыгы корткычлары шулкадәр үрчи ки, алардан берничек тә котылып булмый. Тиз арада бөтен уңышны ашап бетереп, алар урманнарга ябырыла, илдә ачлык һәм паника башлана. Партия әгъзалары да куркуга кала. Ниһаять, 30 миллионга якын кеше ачтан үлгәч, әлеге бәланың чыпчыкларны юк итүдән соң башлануын аңлыйлар. Советлар Берлеге һәм Канадага ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр: Кытайга вагон-вагон чыпчык җибәрелә. Хәзер инде кошкайлар рәхәткә тиенә – мондагы кадәр бөҗәк дөньяда башка бер җирдә дә булмый. Шул вакыттан бирле Кытайда чыпчыкларның кадере арта.

(“Интересно.cc”).

Төш түгел, чынбарлык

Кытайда әле генә бәби тапкан хатыннар өчен махсус кунакханәләр бар. Клиникадан ана белән баланы туры шунда алып китәләр. Анда аларны кайгыртучан медперсонал каршы ала: бөтен уңайлыклары булган бик җайлы аерым бүлмәгә урнаштыра, имезүне җайга салырга өйрәтә, массаж ясый, битенә сихәтле битлекләр яба, йога күнегүләре үткәрә, искиткеч тәмле ризыклар белән сыйлый, сабыйны тулысынча үзләре карый. Мондый кунакханәдә бер ай чамасы яшиләр. Күп гасырлык кытай традициясе буенча, бәби табучы, сәламәтлеген торгызу өчен, бер ай ял итәргә, хроник чирләрдән сакланырга һәм әкренләп әни роленә керергә тиеш. Гадәттә бәби табучыны әнисе, каенанасы яки ире тәрбияли, әмма әбиләр еракта яки сәламәтлекләре начар булса, ир эштән бушамаса, мондый отельләр ярдәмгә килә. Анда бер ай тору якынча 300 мең сумга төшә, әмма шундый кыйммәт тоелса да, яхшы кунакханәгә ярты ел алдан язылып куярга кирәк – алайса берничек тә эләгә алмыйсың.

(“Синьхуа”).

Сугышчан халык

Чукчалар Ерак Төньякның иң сугышчан халкы була, Аляскадан Камчаткага кадәр бар¬лык күрше кабиләләрне үзенә буйсындыра. Чукча сугышчылары үлемнән курыкмый, әсирлеккә төшсә, үтерүне үтенә. Үзләренә әсирлеккә төшү куркынычы янаганда, алар хатыннарын һәм балаларын юк итә торган була, ә кулларына эләккән башка кавемнәрне баш сөяген тишеп җәзалый. XVIII гасырда чукчаларга каршы сугышкан капитан Дмитрий Павлуцкий дошманнарын болай сурәтләгән: “Чукчалар – алып гәүдәле, кыю, көчле халык, гадел, төпле, акыллы, бәйсез, ялганлый белми”, – дип язып калдырган. Урыслар чукчалар белән 150 елга якын сугыша һәм сугыш Россия файдасына тәгәлләнми. Чукотка формаль рәвештә Россия империясенә керсә дә, чукчалар эчке эшләрендә тулы бәйсезлек саклый. Алар күрше кабиләләрне XX гасыр уртасына кадәр диярлек куркытып тора. Соңгы тапкыр чукчалар 1947 елда эскимослар белән сугыша һәм аларны җиңә.

(“Мир новостей”).





Җәй озыная, кыш кыскара

Эйфель манарасы җәен 15 сантиметрга озынрак була. Эш шунда ки, әлеге гаять зур корылма температураны җайлый торган компенсаторлар белән төзелгән, шуңа күрә коры манарага зыян китермичә киңәя һәм кысыла ала. Коры җылынганда, киңәя һәм зуррак күләм били башлый. Һәм киресенчә, көннәр суытканда, кысыла, күләм кечерәя. Нәкъ менә шуңа күрә зур корылмалар, мәсәлән, күперләр, компенсаторлар белән төзелә, бу аларга төрле ел фасылларында үзләренә зыян китермичә үзгәрү мөмкинлеген бирә.

(“Интересности.ру”).

Сәер корылмалар

Дөньяның төрле почмакларындагы архитектура могҗизалары белән танышуны дәвам итик. Гайре табигый һәм җиһанда иң күп фотога төшерелә торган биналардан берсен Канаданың Орландо шәһәрендә Роберт Рипли 1812 елгы 8 баллы җир тетрәү хатирәсе итеп төзегән. Ул чакта кала бөтенләй диярлек җимерелгән, һәм йорт әлеге табигать стихиясендә зыян күргән бинаны хәтерләтә. Кытайның Хуайнань шәһәрендәге музыкаль йорт Piano House исә Хефей технология университетының архитектура факультеты студентлары проекты буенча салынган. Үтә күренмәле скрипкасында эскалатор, пианинода күргәзмәләр комплексы урнашкан.

(“Novate.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

13 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шаян пластилин».
16.00 «Ватандашлар». 16+
17.30 «Заман көзгесе». 6+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

3.15, 15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
3.40 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
4.35 «Гаилә учагы». 16+
5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Резеда Шәрәфиева турында телеочерк. 16+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25, 0.40 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КРИК СОВЫ». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НЕСЛУЧАЙНАЯ ВСТРЕЧА». 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Страна советов. Забытые вожди-2». 12+
16.30 «БЕРЕГА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
22.55 «Большая игра». 16+
23.55 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 Невский ковчег. Теория невозможного. Яков Гаккель.
8.45 «ТРИ НЕНАСТНЫХ ДНЯ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Мастера искусств. Игорь Владимиров».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 Спектакль «Фредерик, или Бульвар преступлений». 16+
15.55 «Агора».
17.15 Шедевры камерной музыки. Ф. Шуберт. Струнный квартет №14. Владимир Спиваков и «Виртуозы Москвы».
18.05 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
18.35 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Мужское и женское. Биология пола».
21.35 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «БЕЛАЯ ПЕРЧАТКА».
23.15 «Магистр игры». «Иосиф Прекрасный, или Изъятие земли».
23.45 «ПОРУС».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Сишәмбе

14 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15, 0.25 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Мин татарча өйрәнәм».
17.15 «Казаннан - казанга». 16+
17.45, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
18.45 Хоккей. «Ак Барс» - СКА. 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «КРИК СОВЫ». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НЕСЛУЧАЙНАЯ ВСТРЕЧА». 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Страна советов. Забытые вожди-2». 12+
16.30 «БЕРЕГА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05, 18.15 «Русские в океане. Адмирал Лазарев».
7.55 «Почерк эпохи». «Евгений Шварц. Сказка со счастливым концом...»
8.20 «Жизнь и судьба».
8.45, 22.20 «БЕЛАЯ ПЕРЧАТКА».
9.45 Цвет времени. Эль Греко.
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Рассказывает Эдита Пьеха... Посвящается Александру Броневицкому».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.00 Спектакль «Укрощение строптивой».
16.30 «Передвижники. Илларион Прянишников».
17.15 Шедевры камерной музыки. И. Брамс. Трио №3 и №2. Николай Луганский, Сергей Крылов, Александр Князев.
19.00 «Почерк эпохи». «Александр Грин. Нина и Ассоль».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 Искусственный отбор.
21.15 «Белая студия».
23.25 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Чәршәмбе

15 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45, 21.00 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Шома бас».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 Телефильм. 12+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Әнгам Атнабаев турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «КРИК СОВЫ». 16+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НЕСЛУЧАЙНАЯ ВСТРЕЧА». 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Страна советов. Забытые вожди-2». 12+
16.30 «БЕРЕГА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «СПУТНИКИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05, 18.15 «Ангелы с моря».
7.55 «Почерк эпохи». «Александр Грин. Нина и Ассоль».
8.20 «Жизнь и судьба».
8.45 «БЕЛАЯ ПЕРЧАТКА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Встреча с кинорежиссером Эльдаром Рязановым».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.00 Спектакль «Оскар и Розовая Дама».
16.30 «Библейский сюжет».
17.15 Шедевры камерной музыки. Л. Бетховен. Сонаты для скрипки и фортепиано. Сергей Догадин, Филипп Копачевский.
19.00 «Почерк эпохи». «Фёдор Тютчев. Хронометр Любви...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Екатерина II: разворот на юг».
22.15 «СОУЧАСТИЕ В УБИЙСТВЕ».
23.30 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

16 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.15 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕПАРТАМЕНТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Учимся вместе» һәм «Музыкаль тәнәфес».
17.15 «Точка опоры». 16+
18.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Динамо» (М). 6+ По окончании - «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ТРЮКАЧ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.15 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Гаилә учагы». 16+
10.00 «Туган авылым». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Равил Шәрәфиев турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СПУТНИКИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «НЕСЛУЧАЙНАЯ ВСТРЕЧА». 12+
15.00 «Наука Шерлока Холмса». 12+
15.30 «Страна советов. Забытые вожди-2». 12+
16.30 «ЛЮБОВЬ В РОЗЫСКЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05, 18.15 «Наедине с мечтой. Фёдор Конюхов».
7.50 «Почерк эпохи». «Фёдор Тютчев. Хронометр Любви...»
8.20 «Жизнь и судьба».
8.45, 22.15 «СОУЧАСТИЕ В УБИЙСТВЕ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Асаф Мессерер».
12.15 «Первые в мире».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00, 13.20, 13.40, 23.55 «ПОРУС».
14.00 Спектакль «Трамвай «Желание».
16.00 «Настоящее-прошедшее. Поиски и находки».
16.30 Пряничный домик. «Мастера земли Омской».
17.15 Шедевры камерной музыки. Ф. Шуберт. Симфония №5. Salve Regina для сопрано и струнного оркестра. Владимир Спиваков, Анна Аглатова и «Виртуозы Москвы».
19.00 «Почерк эпохи». «Антон Чехов. Как бы чего не вышло...»
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Александр Нилин. «Переделкино. Поверх заборов».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Константин Ушинский. Приготовлять к труду жизни».
21.30 «Энигма. Екатерина Губанова».
23.25 «Запечатленное время».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Җомга

17 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45, 0.20 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе» һәм «Төймә».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Наши герои». Телеочерк. 16+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
22.40 «КОМАНДА МЕЧТЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.30, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.00, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Бату Мулюков турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Родная земля». 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СПУТНИКИ». 12+
11.30 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ФИЛОМЕНА». 16+
14.35 «Заповедники РФ». 12+
15.00 «Наука Шерлока Холмса». 12+
15.30 «Больше, чем любовь». 12+
16.30 «ЛЮБОВЬ В РОЗЫСКЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Фантастика». 12+
23.45 «Матадор». «Венеция. Зимняя вода». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.05 «Туман для ёжика».
8.00 «Почерк эпохи». «Антон Чехов. Как бы чего не вышло...»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «СОУЧАСТИЕ В УБИЙСТВЕ».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ИДИОТ».
12.45 Открытая книга. Александр Нилин. «Переделкино. Поверх заборов».
13.15, 13.35, 13.55 «ПОРУС».
14.15 Власть факта. «Екатерина II: разворот на юг».
14.55 «Донна Татьяна».
15.45 «Энигма. Екатерина Губанова».
16.30 Письма из провинции.
17.15 Шедевры камерной музыки. С.Рахманинов. Элегическое трио №2. Борис Березовский, Дмитрий Махтин, Александр Князев.
18.00 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
18.15 «Билет в Большой».
19.00 «Почерк эпохи». «Велимир Хлебников. Я для вас Звезда...»
19.45 Искатели. «Меч-кладенец. Между былью и вымыслом».
20.30 Линия жизни. Сергей Мигицко.
21.35 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ».
22.50 «2 Верник 2».
23.35 «Гленн Гульд. Жизнь после смерти».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
22.15 «БАЛАБОЛ». 16+

Шимбә

18 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 Спектакль «Ак калфагым төшердем кулдан...» 16+
16.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.45 Хоккей. «Ак Барс» - «Салават Юлаев». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «АВАНТЮРИСТЫ». 16+
23.35 «ДНЕВНИК ГОРНИЧНОЙ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Болытларда пәрдә ачкан күңел». Наилә Гәрәева турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
17.15 «Калеб». 6+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 16+
23.10 «Ялт-йолт». «Мунча ташы» спектакле. 16+

«ЭФИР»
5.00, 14.35 «Заповедники РФ». 12+
5.30 «Наша марка». 12+
5.45 «Ковер-самолет». 6+
7.00 «Лекс и Плу: Космические таксисты. Сезон 2». 6+
7.30 «Фиксики».
8.00 «А дома лучше». 12+
8.50 «ПЯТЫЙ ЭТАЖ БЕЗ ЛИФТА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ НА ДВА ПОЛЮСА». 16+
15.00 «Прошу Вашей руки и генов». 12+
15.50 «ОКНА ДОМА ТВОЕГО». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПОСЫЛКА». 16+
23.00 «ТЕРЕЗА Д.». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «ШИРЛИ-МЫРЛИ». 16+
16.00 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+
16.40 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Я люблю мою страну».
19.20 «Эксклюзив». 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.20 «ВСЕ ПРОШЛО ХОРОШО». 18+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «С ЧИСТОГО ЛИСТА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Загадочная планета».
7.20, 7.40, 8.00, 8.20, 8.40, 9.00 «ПОРУС».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Святитель».
11.00 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ».
12.15 Человеческий фактор. «Дом для зайца».
12.50 Черные дыры. Белые пятна.
13.30 «Все краски мира».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.10 «Нобелевские победы российской науки». Лев Ландау.
15.50 «РЕСПУБЛИКА ШКИД».
17.35 Большая опера.
19.45 «Первые в мире».
20.00 «ИДИОТ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.30 «Наше поколение-2023». Международный конкурс детской авторской песни.
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Суперстар!» 16+
23.50 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

19 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Сөенеч».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Дуслык илендә». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.45, 0.45 Ришат Төхвәтуллин концерты. 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «АРТУР НЬЮМАН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кто мы татары?» 12+
8.00 «Моң-җырларым - ак җилкән». Ганс Сәйфуллинның юбилей кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Илгиз Зәйниев турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары». 12+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 16+
14.20 «Кайда сез, яшьлек елларым». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Җаным җырда». Фердинанд Сәлахов концерты. 16+

«ЭФИР»
5.00, 14.35 «Заповедники РФ». 12+
5.30 «Наша марка». 12+
5.40 «Заячья школа». 6+
7.00 «Лекс и Плу: Космические таксисты. Сезон 2». 6+
7.30 «Фиксики».
8.00 «А дома лучше». 12+
8.50 «ОКНА ДОМА ТВОЕГО». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЖЕНА МОЕГО МУЖА». 12+
15.00 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.50 «ПЯТЫЙ ЭТАЖ БЕЗ ЛИФТА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СЕНСАЦИЯ». 16+
22.35 «ЛЮБОВЬ НА ДВА ПОЛЮСА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Мелодии моей жизни». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
12.15 «Повара на колесах». 12+
13.10 «Видели видео?»
15.05 «Горячий лед». Фигурное катание.
16.50 «Огневое превосходство Аркадия Шипунова». 12+
19.00 «Перепой звезду». 12+
21.00 «Время».
23.00 «Институт Склифосовского. Век милосердия». 16+

«РОССИЯ»
6.10 «ПРОВЕРКА НА ЛЮБОВЬ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.50 «БЕЗ ТЕБЯ». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.25, 7.45, 8.05, 8.25, 8.45, 9.05 «ПОРУС».
9.25 Диалоги о животных.
10.05 «Родное лицо. Татьяна Пельтцер».
10.45 «СВАДЬБА».
11.50 Неизвестные маршруты России.
12.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Борис Смелов.
13.05 «Игра в бисер» «Поэзия Франсуа Вийона».
13.45 «Коллекция».
14.15 «План генерала Ватутина».
15.00 «Живые и мертвые. «Солдатами не рождаются». Музыкально-драматический спектакль по роману Константина Симонова.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 «Романтика романса».
18.45 К 95-летию со дня рождения Алексея Баталова. Острова.
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «ЗВЕЗДА ПЛЕНИТЕЛЬНОГО СЧАСТЬЯ».
23.05 Борис Эйфман. Золотая коллекция. «Прозрение».
23.40 «Кинескоп».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Исемсез утрауда җан алу

Түбән Кама гидроэлектростанциясе төзегәннән соң барлыкка килгән сусаклагычта утраулар күп. Минзәлә якларында, мәсәлән, Өч Ык, Алтын дип йөртелүчеләр, алар янәшәсендә бер исемсез утрау да бар. Шуларның өченчесендә нәкъ 20 ел элек булган кеше үтерү очрагының шаукымы әле дә тынмаган.

Җинаятьчене эзләү дистә елларга сузылу була торган хәл. Хикмәт шунда ки, бу юлы 30 яшьлек балыкчыны һәлак иткән кешенең 1950 елгы Акмалетдин Әсәдуллин икәнен күргән-белгән гади кешеләр генә түгел, ул чакларда Минзәлә милициясендә эшләгән хезмәткәрләр дә шикләнми. Ләкин 2003 елның 15 июнендә кеше үтерү очрагы буенча Минзәлә прокуратурасы кузгаткан һәм берничә айдан тикшерү эшләрен туктаткан җинаять эше узган ел Тикшерү комитетының Татарстан идарәсе фәрманы чыкканчы киштәдә ята. Димәк, Хуҗәмәт кешесе Акмал да иректә йөри.

Ошбу галәмәтнең сәбәпләрен ачыклау өчен сүзне 20 ел элек булган хәлләрдән башларга кирәк. 2003 елның 14 июнендә А.Әсәдуллинны үз улы УАЗ машинасында Минзәләдәге 1953 елгы дусты Александр Попов янына китерә. Алар белән балык тотарга шактый яшь Ю.Чигвинцев та барырга тиеш була. Ул иртәдә Юрий бала тудыру йортыннан хатынын һәм нарасыен алып кайту белән мәшгуль булганга, сәфәр кичектерелә. Аны көткән арада Акмалетдин балыкчылар кибетеннән ятьмәләр, резина итекләр ала һәм аракыны да онытмый. Шул рәвешле, төш вакытында өч ир-ат А.Поповның моторлы көймәсенә төялеп исемсез утрауга барып төшә.

Анда А.Попов ясаган сәндерә, өстәл кебек кайбер корылма тора. Ирләр эшне тамак чылатудан башлый, аннан соң алданрак салынган ятьмәләр тирәсенә яңаларын өстәлә, кичкә таба алардан 15-20 кило чамасы балык алына. Шуннан соң көймә Минзәләгә таба йөзә, анда табыш акчага, аннары аракы вә сырага әверелә. Димәк ки, утрауга кайткач аяк терәп эчәргә була. Нәтиҗәдә озак көттерми, иртәнге 7ләр тирәсендә А.Попов белән А.Әсәдуллин Минзәлә эчке эшләр бүлегенә килеп Ю.Чигвинцевның җансыз килеш табылуы турында хәбәр итәләр. Шулай итеп Юрийның икенче баласы дөньяга килгән көннәрдә үлеп китүе мәгълүм була.

Утраудагы үлән-куаклар арасында табылган ир-атның балта белән чабып үтерелүе, кем әйтмешли, сукыр күзгә дә күренә. Эксперт аның башында һәм күкрәгендә биш җәрәхәт булуын, 15 июнь иртәсендә сәгать өч белән биш арасында җан биргәнен белдерә. Попов белән Әсәдуллин утрауда башка кеше булмавын раслый, ләкин икесе дә җинаятьне үз өстенә алмый.

А.Әсәдуллин беренче күрсәтмәсендә кич һәм төнлә белән тыныч булды, арып-талып будкада йокларга яттым, иртә белән Поповның Чигвинцевны эзләп йөргән ишетеп тышка чыктым, көймәдән 20-25 метр читтәрәк Юрийны үле килеш таптык, дип сүзне кыска тота. Попов исә кичтән Акмал белән Юра арасында ызгыш булуын әйтә, иртән Чигвинцев көймәдә булмагач Әсәдуллинны уятып алып чыктым, ул шунда ук яңа тапталган сукмак буйлап китте, канлы гәүдә янына барып җиткәнче үк туктап, аның үле икәнен әйтте, дип, чынлыкта, Акмалның алдан ук барысын да белүен раслап сөйли.

Дүрт көннән соң А.Әсәдуллин белән үткәрелгән полиграф детекторы тикшеренүе дә шулай күрсәтә. Татарстан эчке эшләр министрлыгы белгече биргән белешмәдә А.Әсәдуллин үтерүдә катнашкан, Чигвинцевны бер кеше үтергән, үтерү иртәнге сәгать өчтә булган, җинаять коралын сазлыкка яшергән, диелә. Мәгълүм ки, полиграф нәтиҗәләре фашиткеч дәлил була алмый. Биш көннән прокуратура тикшерүчесе шикләнелүче А.Поповка карата җинаять эзәрлекләве туктатыла дигән карар чыгара. Әмма Әсәдуллин өстендә болытлар куера бара.

Бу җәһәттән, 2003 елның 17 июнендә үткәрелгән бер оператив чараны искә алыйк. Ул көнне А.Попов һәм А.Әсәдуллин кара-каршы сорау алу өчен Минзәлә эчке эшләр бүлегендәге бер бүлмәгә кертелә һәм икесе генә калдырыла. Чынлыкта, кабинетка алдан ук тавыш яздыру җайланмасы куелган, өстәвенә, почмактагы өстәл астында оперативник А.Сәлахов посып утырган була. Әсәдуллин аулакта калудан файдаланырга була, А.Поповны җинаятьне үзенә алырга үгетли, 4-6 елга утыртачаклар, ләкин Татарстан күләмендәге хокук саклау органындагы белгән кешесе аркылы бер-ике елдан ireккә чыгарырга вәгъдә итә. А.Попов ошбу тәкъдимнән баш тарта. Сорау алу вакытында әлеге сөйләшүне кире кага ул, бары тик аудиоязманы тыңлаткач кына таный. Аудиоязма кәгазьгә күчерелеп җинаять эшенә тегелә, диск исә тиешле тәртиптә дәлил итеп теркәлә.

2003 елгы җинаять эше белән танышкач, Поповның да алдан барысын да сөйләп бетермәве күренә. Фаҗигадән соң биш ай узганнан соң милициягә үзе килә ул, әйтүенчә, урамда мәрхүм дустының ятим калган балалары белән тол хатынын күргәч түземлеге төкәнә һәм Әсәдуллинның өркетүләре, шул исәптән, Казандагы хокук саклау органнарындагы зур кешеләр белән куркытуларына карамастан, моңарчы әйтеп бетермәгәннәрне ачып салырга була. Шунысын да өстик, фаҗигадән соң утрауга йөрүдән туктый, андагы корылманы да юк итә ул.

Аның өстәмә кертелгән күрсәтмәләренә караганда, ике исерек балыкчы арасындагы бәрелешкә печән мәсьәләсе этәргеч бирә. Әсәдуллин андагы үләнне чабып сатарга җыенуын әйткәч, Юрий да әлеге керемле кәсепкә дәгъва белдерә. Әсәдуллин аны сугып ега, ә Юрий сикереп торып Акмал агайның эченә тибә.

А.Поповның әйтүенчә, яктыра башлаганда Александр су чыпырдаган тавышны ишетеп тәрәзәдән карагач, Акмалның яр буенда нәрсәдер юуын күрә, тиздән кереп ул юеш балтаны сәке астына шудыра, турыдан-туры әйтмәсә дә хуҗага Чичивинцевны үтергүен сиздерә, әгәр шауласаң, сиңа да шулай булачак, дип яный. Шурли калган А.Попов шактый вакыт узгач кына дустын эзләргә чыга. Әсәдуллинның туп-туры мәет яткан җиргә алып китүен аның үле икәнен белү нәтиҗәсе дип саный ул.

2003 елда әлеге ике ир-ат белән күп кенә оператив чаралар үткәргән милиция хезмәткәрләре дә А.Поповны гаепләрлек сәбәп күрми, ә Әсәдуллинның үз-үзен тотышы, аңлатмаларына шикләнеп карыйлар. 2003 елда шикләнелүче зат ачыкланмау сәбәпле дигән билгеләмә белән җинаять эшенең киштәгә куелуына А.Әсәдуллинның якасыннан алырлык дәлилләр җитмәүнең йогынтысы да булгандыр. Шулай ук Акмалетдинның Казандагы зур кешеләр турында әйтеп йөрүләре буш шапырыну гына түгел, аңа ярдәм итүчеләр булган, дигән шик тә туа. Игътибар итик, Әсәдуллин мәет табылган, җинаять эше кузгатылган көнне үк тоткарлана, Минзәлә район суды аны ике айга сак астына алырга дигән карар чыгара, ләкин биш көннән үк азат ителә ул. Һәм 19 ел буе иректә йөри. Узган ел тикшерү эшләре яңартылгач, Чаллы суды авыр җинаять кылуда гаепләнгән затка сак астына ябу түгел, ә «домашний арест» дигән ирекне чикләү чарасы билгеләли, ошбу карарны Татарстан Югары суды юкка чыгаргач кына инде 72 яшендәге кеше Минзәлә төрмәсе дип йөртелүче изоляторга утыртыла.

Җәзасыз калдырылуына шөкерана кылып тыныч кына яшәгән дип булмый аны. Яңартылган җинаять эшендә теркәлгән 46 шаһит һәм зарар күрүче арасында аның турында уңай сөйләүче юк. Ошбу бәяләмәләрне кыскача гына әйтеп узыйк. Күршеләренең су суыртучы насосының электр чыбыкларын өзеп яңа сууткәргеч ясарга мәҗбүр итә, бакчасы артында көтү йөртүчеләргә тынгылык бирми, атам дип җикеренеп йөргән өчен Росгвардия мылтыгын алып китә, еш кына 2003 елда да утырта алмадылар дип күкрәк кагып йөри, кыскасы, Хуҗәмәттә бик күпләргә мәшәкать чыгара ул. Хәләл җефете исән чакта азрак тыя иде, ул үлгәч тагын да холыксызланды, күбрәк эчә башлады, туктаусыз исерек килеш машинасында йөри, дип әйтүчеләр, хәтта күршеләре Зариповлар йорты януны да аңа сылтаучылар бар авылда.

Акмал картның холык-фигыле, үзүзен тотышы җинаять эшендә бик ачык чагылыш таба. Узган ел җәй көннәрендә кылган явызлыклары өчен полиция тикшерүчеләре дүрт җинаять эше кузгаткан була. Октябрь ае башында утраудагы үтереш тикшерелә башлагач, алар тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Е.Сәйфетдиновка тапшырыла. Биш эпизодлы җинаять эше барлыкка килә.

А.Әсәдуллинның соңгы хилафлыкларына тукталыйк. Күршедәге Р.Зарипов гаиләсе белән күптәннән тынышмый ул, мылтыгын да Равил әйтүе буенча алалар, Зариповлар өйләре янгач шул авылдагы туганнары йортына күченәләр. 2022 елның 4 августында Акмалетдин абзый сәбәп табып «разборка»га килә. Равил белән низаг чыккач, аның йөзенә баллоннан газ бөрки, хуҗалар әйтүенчә, пычак тотып янаулы сүзләр кычкыра, борычлы газ эләккәч күрми башлаган ир-атны олы кызы ишегалдына тартып кертеп капканы ябып куя. Шуннан соң бу чакта урамда булган хуҗабикәгә дә яный ул һәм машинасына утырып китеп бара.

Р.Зарипов иртән моны участок инспекторына хәбәр итә, ләкин анысы ошбу мөрәҗәгатьне игътибарсыз калдыра. Р.Зарипов бу хакта Хуҗәмәттә яшәүче район эчке эшләр бүлегенең элекке җитәкчесе Наил Гариповка сөйли. Шуннан соң тикшерү эшләре башлана, үтерү белән куркыту дигән ике җинаять эше ачыла.

Шул арада тагын бер җинаять кылып өлгергән була ул. Бер ел элек шул авылда яшәүче Риф Хафизов үзе хезмәт иткән хәрби һава көчләре көнен билгеләп утырга була. Алдан дусты А.Колотов белән салып утыралар, аннан А.Әсәдуллин машинасына утырып кайта һәм шоферны да сыйланырга чакыра. Ә Александр ошбу бәйдә белән эчмәячәген белдерә, аның юньсезлекләрен санап китә. «Текә» агайның ачуын чыгармый калмый бу хәл. Ул өстәлдәге пычакны алып болганырга, «суям хәзер» дип кычкырырга керешә, А.Колотовның бармагы да киселә хәтта. Машинасы белән таптатам дип янаган хәтәр кешедән кача-поса өенә кайткач, А.Колотов участок инспекторына аңлатма язып бирә. Үтерү белән янау турында тагын бер эш барлыкка килә. Сентябрь аенда Әсәдуллин тагын Равил Зариповка бәйләнә, теге дөньяга озатам, дип яный. Җинаять эшенә тагын бер эпизод өстәлә.

Бу елның башында тикшерү комитеты Әсәдуллинга Ю.Чичвинцевны үтерүдә рәсми гаепләү белдерә. Зариповлар капка төбендә булган бәрелеш үтерү белән янау түгел, ә бәлки ике кешене, ягъни Р.Зарипов һәм аның кызын үтерергә омтылыш ясау дип бик хәтәр бәяләнә. Әлеге эпизодларның хикмәтле яклары бар. А.Әсәдуллин, 2003 елдагы үтерүдә гаепле дип табылса да, җәзасыз калырга мөмкин. Чөнки мондый җинаятьләр өчен җавапка тарту срогы 15 елдан чыга.

Август азагында Минзәлә судында А.Әсәдуллинны 4 ел да бер айга ирегеннән мәхрүм итәргә дигән хөкем игълан ителде, ниһаять. Бу инде 20 еллык җинаять өчен, срогы чыгу сәбәпле, җәза билгеләнмәүне белдерә. Кыскасы, А.Әсәдуллинга бары тиз узган елгы җинаятьләре өчен генә җәза бирелә.

Наил ВАХИТОВ.

Егетләрнең асылы Илдар «Гади»

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләр. Дөрес икән. Азнакай районы Татар Шуганы авылы егете Илдар Һадиев белән күрешкәч, бу сүзнең дөреслегенә тагын бер кат инандык. Тат.Шуган егете, дигәч тә, һаман да шул авылда гомер кичерә икән, дип уйламагыз. Төрекөмеш кебек тере Илдар, гомумән, бер җирдә генә тупланеп яши торганнардан түгел.

Яшьлегендә Казанны «алырга» килгән. Бизәүче рәссам белгечлеген үзләштергән. Аннары Казан мәдәният һәм сәнгать университетында режиссерлыкка укыган. Үзе кебек тиктормаслар, талантлылар, әйдаманнар – җырчы Салават Фәтхетдинов, җырчы, юмор остасы һәм телевидение тапшыруларын алып баручы Җәфит Шакиров, Чаллы драма театрының карап туйгысыз артисты Булат Сәлахов, Түбән Кама театрының йөзек кашы Альберт Ибраһимовлар белән бер чорда белем алган. Чордашларыннан бер дә кимен куймаган Илдар Һадиев тә.

Чаллыда яшәүчеләр аны «Кыйбла» татар яшьләр үзәге җитәкчесе буларак хәтерли. 1990 елларда Чаллыны татар концертлары белән гөрләткән «Гади»не онытырга мөмкинме соң? Җырчы-музыкантларны бер йодрыкка туплап, кечкенә залларны да, «Энергетик» мәдәният сарае кебек зур сәхнәләрне дә татар моңына күмгән «Гади» бит ул! Күп артистлар белән бергә иҗат итәргә туры килсә дә, И.Һадиев барыннан да бигрәк ирле-хатынлы Гөлдания һәм Рөстәм Хәйруллиннарга рәхмәтле. «Алар минем сөйләү куәсемә игътибар итеп, беренчеләрдән булып сәхнәгә алып чыкты», – ди. Чаллылар гына түгел, Казан тамашачысы да Илдар Һадиевне беләдер. Ленин мәдәният сараенда Булат Сәлахов белән бергә концерт алып барганнарын бик сагынып сөйли ул үзе. Мәһабәт гәүдәле Булат Сәлахетдин Курсави-Арчинский (Арча егетенең ул еллардагы сәхнә тәхәллүсе) һәм җыйнак кына буй-сынлы Илдар «Гади» алып барган бу концертны халыкта да хәтерләүчеләр, һичшиксез, бар. «Буең да миннән бәләкәй, репликаларың да күп түгел, Һадиев дип әйтүе дә безнеңчә түгел, әйдә, Гади генә булып кал», – ди икән Булат Сәлах шаяртып. Шулай Азнакай егете халык теленә «Гади» дип кереп кала.

«Гади» булса да гади генә түгел. Сөйләп җибәрсә, сәгатьләр буе авызына каратып тота. Мәзәкләрен тыңлаганда халык егыла-егыла көлә. Әллә каян чәлдергән анекдотлар түгел, барысы да тормыштан алынган кызыклар. Илдар Мөхтәр улы тормышны күрә-күзәтә, иң әһәмиятлесен сайлый белә.

Әйттек бит, гади генә егет түгел ул. Һаман терекөмеш кебек хәрәкәтчән. Хәзер Чаллы белән Азнакай арасында үтә гомере, чөнки Баланлы-Бүләк авылында клуб мөдире булып эшли. Авыл зур түгел, кешесе туксаннан чак кына артык. Ләкин Илдарыбыз Чаллы каласын шаулатырга күнеккән. Шуңа күрә клуб эше алып барудан калган көчен, илһамын ул тагын бер һөнәргә юнәлткән – Илдар «Гади» агач уеп, сандыклар, бишекләр, сәгатьләр, тәрәзә йөзлекләре ясый. Аларның матурлыгын күрсәгез, егылып китәсез. Милли һөнәрләребез югалып барган заманда, татар авылларында тәрәзәләрне челтәрләп бизәү онытылган вакытта, агач капкаларны тимерләргә алмаштырганда, егетнең традицияне кайтару эшенә керешүе үзе генә дә ни тора! Сандыкларны да, бишекләрне дә сораучылар шактый икән. Килен сандыгы йоласы әле дә халыкта яши, онытылып бетмәгән. Анны, «Бирнә сандыгы» һ.б. шуның ише бәйгеләр район күләмендә дә, республика буенча да һаман үткәрелә тора. Илдар «Гади»нең сандыгын хәтта телевидениедән күрергә мөмкин. Остакул иң матур сандыгын сайлап яшьлек дусты, иҗатташы Җәвит Шакировның «Кәмит-Җәвит» тапшыруына бүләк иткән. Һөнәргә керешкәч, үзе өчен кызыклы ачышлар да ясаган. Мәсәлән, сандыкны да, бишекне дә нарат-чыршыдан ясарга ярамый, чөнки киемнәргә агачның исе сеңә, бала да ул бишектә йоклап китә алмыйча интегә. Шуңа күрә сандыгын да, бишеген дә юкәдән ясый. Бизәкләп-сырлап ясалган агач таяк игътибарны аеруча җәлеп итте. Картларга таянып йөрер өчен ясалган кул таягы түгел бу, элек ханнар-бәкләр кебек дәрәҗәләрен күрсәтер өчен кулга тотып йөрү өчен ясалган. Гади булса да, Илдар «Гади»дә затлы кан ага, күзләренең төсе дә уңмаган, очкыны да сүрелмәгән, иҗат куәсе дә һаман ярларыннан ташып аккан елга кебек. Менә шул иҗатының яңа бер чагылышын күрсәтергә ул кайчандыр гөрләтеп концерт биргән Казанның Ленин мәдәният сараена әйләнеп кайтты. Биредә без аны Азнакай районы мәдәният әһелләренең смотр-концертында очраттык. Элек ничек сәхнә түрендә булса, Илдар «Гади» бүген дә үзәктә кайный. Экспозициягә бизәргә сандыклары, бишекләре белән бергә зур таган ясап килгән. Аны уеп бизәгән. Бу таган Азнакай районы үзешчәннәре кичәсенең йөзек кашына әйләнде. Бөтен килгән халык анда атынып истәлеккә фотога төште. Шундый матурлык янынннан тыныч кына үтеп китеп буламыни?!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 10.11.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2643

16+